АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

## *Татары Башкортостана. Стерлибаш*

Вторая часть

КАЗАНЬ · 2021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

## *Башкортстан татарлары. Стәрлебаш*

Икенче кисәк

КАЗАН · 2021

УДК 398+811.512.145
ББК 81.2=632.3+82.3(2=632.3)+85.12
М 48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

**Редколлегия:**
***К.М. Миңнуллин** (рәис), **М.Р. Булатова, Ф.З. Яхин***

**Фәнни мөхәррир**
*филология фәннәре кандидаты **И.И. Ямалтдинов***

**Төзүче**
*филология фәннәре кандидаты **Н.Ш. Насыйбуллина***

**М48 Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш.** 2 нче кисәк. – 2 нче басма. – Казан, 2021. – 448 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).
ISBN 978-5-93091-334-7

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән ике кисәктән торган чираттагы китаплар Башкортстан Республикасы Стәрлебаш районында яшәүче милләттәшләребез, аларның гореф-гадәтләре, тел-авыз иҗаты, сөйләш үзенчәлекләре, җыр-моңнары, җирле осталарның кул эшләре, шәҗәрәләр, археографик мирас турында бай мәгълүмат бирә.

Икенче кисәк Стәрлебаш авылы һәм мәдрәсәсе тарихына караган хезмәтләр белән ачыла. Биредә Стәрлебашның затлы китапларыннан булган «Дөррел-Кәлам», Стәрлебаш шагыйрьләре әсәрләре, Стәрлебаш татарларының традицион музыка мәдәниятен, халык сәнгатен, бу төбәктә табылган гарәп телле кульъязманың үзенчәлекләрен, элегрәк тупланган халык авыз иҗаты материалларын анализлаган мәкаләләр, кульъязмаларның тасвирламасы, кульъязма мирасны саклаучылар турында һәм авыл тарихына кагылышлы мәгълүматлар бар.

Китап туган як тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-93091-334-7**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2019, 2021

## БЕР-ИКЕ СҮЗ...

Стәрлебаш районына төрле елларда оештырылган экспедицияләр нәтиҗәсендә табылган материалларга анализ ясалган фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр һәм башка материаллар ике кисәктән торган «Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш» китабында урын алды. Беренче кисәк татар халкының тарихына, теленә һәм мәдәни мирасына караган гомуми характердагы кереш сүз белән ачыла. Анда Стәрлебаш мәдрәсәсе тарихын, урта диалектның минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгына һәм көнбатыш диалектның стәрлетамак сөйләшенә караган тел үзенчәлекләрен, төбәк фольклорының бүгенге торышын тикшергән мәкаләләр урнаштырылды. Икенче кисәк дәүләт, дин һәм җәмәгать эшлеклесе М. Тукаевның Стәрлебаш авылы һәм мәдрәсәсе тарихына караган хезмәтләре белән ачыла. Биредә Стәрлебашның затлы китапларыннан булган «Дөррел-Кәлам», Стәрлебаш шагыйрьләре әсәрләре, Стәрлебаш татарларының традицион музыка мәдәниятен, халык сәнгатен, бу төбәктә табылган гарәп телле кулъязманың үзенчәлекләрен, элегрәк тупланган халык авыз иҗаты материалларын анализлаган мәкаләләр, кулъязмаларның тасвирламасы, кулъязма мирасны саклаучылар турында һәм Хәлекәй авылы тарихына кагылышлы мәгълүматлар кертелде. Кушымта рәвешендә академик В. Бартольдның Стәрлебашта тукталуы турында хәбәр бирелде.

Ике кисәктән торган «Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш» китабында урын алган мәкаләләрнең барысы да – халык теленең, тел-авыз иҗатының, милли сәнгатьнең һәм гомумән традицион мәдәниятнең тере яшәешен үзе күргән белгеч күзлегеннән бәя биреп язылган хезмәтләр. Тәкъдим ителә торган китапларда төрле елларда Стәрлебаш төбәгендә табып алып кайтылган фольклор үрнәкләре беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелә.

Бирегә тупланган ядкярләр татар халкы тарихын, аның мәдәни дөньясын өр-яңа мәгълүматлар белән баета, халкыбыз турында тагын да киңрәк күзаллау булдырырга ярдәм итә. Китаплар укучы күңеленә хуш килер дигән өметтә калабыз.

# ТАРИХЫ ЭСТӘРЛЕБАШ[1]

*Мөхәммәтшакир Тукаев*

Эстәрлебаш авылы – губернасы булган Өфе шәһәреннән йөз илле чакрым җирдә, өяздә булган Эстәрлетамак шәһәреннән илле чакрым кыйбла тарафында, Олуг Себер тимер юлында барлыкка килгән Шәфран станциясеннән җитмеш биш чакрым җирдә, якынча 73° озынлык 52° киңлек арасында Эстәрлебаш суының башланган җиреннән биш чакрымда барлыкка килгән бер мәшһүр авылдыр. Әүвәл заманнарда ошбу башкорт җиренә Казан якларыннан һәм Каргалы шәһәреннән кайбер кешеләр солых һәм мәслихәтләре белән килеп сәүдә һәм кәсепләр белән шөгыльләнер өчен, ошбу Эстәрлебаш урынында утар ясап яшәгәннәр. Акрынлап кәсеп һәм сәүдәләре алга барганлыктан, кешеләр күбәеп,

[1] Дәүләт, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәтшакир Тукаевның «Тарихы Эстәрлебаш» хезмәте 1899 елда Казанда басыла. Стәрлебаш музеена нигез салучы тарих укытучысы Мәхмүд Гобәйдулла улы Мәхмүдов тырышлыгы белән М. Тукаевның «Тарихы Эстәрлебаш» китабы өлешчә М.А. Морзабеков тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, 1996 елда дөнья күрә. 2010 елда М. Тукаевның хезмәте галим Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан хәзерге татар теленә күчерелеп, 1000 данә тираж белән Казанда басыла. Шулай ук язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Зәки ага Зәйнуллинның «Эстәрлебаш мәдрәсәсе» исемле китабында да әлеге текст укучылар игътибарына тәкъдим ителә. Аны иске татар теленнән гамәлдәге язуга Р. Үтәбай-Кәрими һәм В. Усманов күчерә. Әлеге җыентыкта «Тарихе Эстәрлебаш» тексты М. Әхмәтҗанов тарафыннан бүгенге телгә якынайтып текстологик эшкәртелгән вариантта укучыларга тәкъдим ителә. Чыганак: Мөхәммәтшакир Тукаев. Эсәрлебаш тарихы. М.: ООО «Алтын Мирас», 2010. 32 б.

авыл булып киткән. Бу вакыйга кайсы заманнарда һәм ничәнче елларда булганы мәгълүм булмаса да, Эстәрлебаш авылы Пугач вакыйгасыннан йөз еллар элек булган имеш, диләр. Пугач вакыйгалары безнең бу якларда 1773 елларда булган. Эстәрлебаштан өч чакрым җирдә Бускун дигән урын Пугач вакыйгасында качып һәм яшеренеп калганнан исемләндерелгән дип сөйләнелә. Кайбер кешеләрнең әйтүенә күрә, Эстәрлебашта элек яшәгән кешеләр бераз заман торгач, җирне башкортлардан иҗарәгә[1] алганнар. Иҗарәләре илле елга булган имеш. 1809 елның 25 апрелендә язышкан кәгазьләре Әбүн-нәгыйм Мөхәммәдлатыйф улы дигән кешенең кулында булган. Аның бабасының бабасы Иосыф-купец дигән кеше Каргалыдан килеп, сәүдә итеп, поташ заводы тоткан. Мәгълүм кәгазьне 1809 елда башкортлар белән ул язышкан; ошбу кәгазьне өченче мәртәбә алу имеш; һәр мәртәбәдә иллешәр елга язышканнар, дип әйтәләр. Шуңарга таянып башкортлардан алынган кәгазь белән 1809 елдан йөз ел элек ала башлап, кәгазьсез утыз еллар торган булсалар, Эстәрлебаш 1680 еллар чамасында нигезләнгән булырга тиеш. Әмма ки, кайсы кешеләр ошбу вакыттагы кешеләрнең нәселе һәм бабалары булганнары күрелми һәм беленми. Пугач вакыйгаларыннан соңрак булган эшләрне белүче әби-бабайлар бер егерме биш ел элек заманнарда бар иде, һәм кайбер кешеләрдә электән сакланган язулар арасында 1774 һәм 1797 еллардагы кайбер мөгамәләт кәгазьләре (документлар) бар.

Эстәрлебаш авылы – төн яктан биек тау буенда, Эстәрле елгасының ике ягында җирләшкән авылдыр. Кыйбла һәм шәрекъ тарафында ачык һәм аз-аз урманнары бар: урыны биек җирдә һәм төньяктан тау белән әйләндереп алынганы өчен, Эстәрлебашта хуш һава булып, җимеш бакчалары бардыр. Бакчаларда алма, груша кебек җимешләр пешеп өлгерәләр. Мәшһүр хәзрәтләр бакчасы белән мәгълүм олуг бакчалардан башка тагын да дүрт-биш җирдә алма үсә торган бакчалар бар. Уртача кышларда суыклык унике градуска туры килеп, җәй көннәре җылы вакытларда уртача унҗиде градуска туры киләдер.

[1] *Иҗарә* – аренда.

Эстәрлебашның халкы – татар халкыдыр. Авыл халкының күбесе ашлык чәчеп кәсеп итәләр, һәм кайбер сәүдә итүчеләр дә бар. Кайбер кешеләр җәй көннәрендә урак һәм печән кәсепләре өчен, ялан-якынга бару кәсебе дип, Оренбург һәм Самара тарафына барып, бер-ике ай кәсеп итеп, кеше башына уртача хисап ителгәндә ун һәм унбиш сум акча кәсеп итеп кайталар. Халык арасында кайбер сәнгать һәм һөнәр ияләре дә бардыр, унга якын ташчы һәм миччеләр, һәм шулай ук унга якын читек-кәвеш тегүчеләр һәм унлап балта осталары, һәм унбишкә якын пычкычылар бардыр; Эстәрлебашта хатын-кызлардан да кайбер чигүтегү һәм палас сугуга осталары бардыр. Эстәрлебаш авылында 1897 елдагы гомуми санау буенча 1072 ир, 1052 хатын, һәммәсе 2124 кеше күренде. Иншаллаһ, хәзер дә шулкадәр, бәлки дә күбрәк кеше бардыр. Эстәрлебашта һәр дүшәнбе көн атнада бер мәртәбә базар үткәрелеп, сәүдәгәрләр арасында уртача җиде йөз тәңкәлек кадәр нәрсә сату тәҗрибә кылынадыр.

Эстәрлебаш авылы мәшһүр авыллардан булып санала; шөһрәте олуг мәдрәсәләрендә бер елда ничәшәр йөз шәкертләр заһири гыйлемнәр өйрәнеп һәм ничәмә йөзләр батыйни гыйлемдә үзенең өлешен алып, йөз елдан күбрәк бәлки ике йөз елга якын Эстәрлебаштан күп галим һәм голяма һәр якка таралып, мөселманнар арасында гыйлем һәм әхлак тараталар. Эстәрлебаш авылына беренче мәртәбә имам булып Монасыйп мулла исемле кеше килгән имеш дип әйтәләр; ул кеше хакында мәгълүм булган хәбәрләр һәм нәселендән кемнәр калганыннан белеп хәбәр бирер кеше булмады. Мәзкүр Монасыйп мулла 1710 ел белән 1720 еллар арасында имам булып торган булырга тиеш. 1720 еллардан соң Эстәрлебашта мәчет салынып, әүвәл мәдрәсә төзеп дәрес башлаган кеше – Хөсәен мулла Габдуррахман улыдыр. Мәрхүм беренче мәртәбә Эстәрлебашта мәчет төзетеп җомга укый башлап, бүгенге көндә Эстәрлебаштагы минбәр таягы – ошбу Хөсәен хәзрәттән калган таяктыр. Шул минбәр таягында язган язуы бар: «Хөсәен бин Габдуррахман» дип язган; 1870 елларда бу таякка йөз илле ел бар дип әйтәләр иде. Бик белеп сөйләгән бер кешенең әйтүенчә, мәзкүр Хөсәен мулла беренче мәртәбә мөфти булып килгән,

Мөхәммәдҗан мөфти Хөсәеновның атасыдыр. Мөхәммәдҗан мөфти олуг Екатерина Икенченең әмере белән 1789 елда мөфти булып килгән. Ошбу югарыда әйтелгәннәргә таянып, Хөсәен мулла якынча 1720 елларда Эстәрлебашта дәрес укытырга башлаган, шул вакытларда мәчет һәм мәдрәсәләр төзелгән. Шулай булгач Эстәрлебаш мәдрәсәсенең тарихын 1720 еллардан хисап кылырга ярый. Ошбу Хөсәен мулла хәзрәтләре кайсы елларда вафат булганы турында белгән кешеләр булмады, һәм ничә ел дәрес биргәне беленмәде; әмма ки салих һәм галим амири билмәгъруф (Аллаһы Тәгалә кушканнарын үтәүче) кеше булган дип әйтәләр (рәхмәтуллаһи галәйһи). Эстәрлебашта икенче мәртәбә мөдәррис булып дәрес бирүче кеше Гаделшаһ хәзрәт бине Габдуллаһ Богданов[1] булган. Ошбу Гаделшаһ хәзрәт – мәшһүр Чебенледәге Ниязколый әт-Төркмәнинең хәлифәсе булган Дәүләтшаһ хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) атасыдыр. Гаделшаһ хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) хакында мәгълүм булган хәбәрләрдән Чакмакта Габдуллаһ хәзрәт мәрхүм (рәхмәтуллаһи галәйһи) шулай дип әйтә иде: Минзәлә өязендә Урыш-Мөслим авылында Шәмгун мулла дигән кеше, Эстәрлебашта Гаделшаһ хәзрәтнең мәдрәсәсендә укып кайтып указный имам булып торып, сиксән биш яки туксан яшьләр чамасында 1860 елда вафат булган. Мәрхүм Шәмгун мулланың Эстәрлебашта торган заманлары 1795 еллар чамасында булырга тиеш. Һәм Балыклы авылында мәшһүр булган Хөснетдин ахунд[2] хәзрәт мәрхүмнең Гаделшаһ хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) мәдрәсәсендә 1799 елда язган китабы бар. Ошбу әйтелгәннәргә күрә, Гаделшаһ хәзрәт 1785 елларда, бәлки тагын да элегрәк яшәгән булса кирәк. Хөсәен мулладан соң Эстәрлебашта Гаделшаһ хәзрәткә кадәр, ягъни аларның икесе арасында мөдәррис булдымы-юкмы, яки Хөсәен мулла бик карт булып, Гаделшаһ хәзрәт аңардан соң мәчет һәм мәдрәсәләргә

---

[1] Гаделшаһ хәзрәт бине Богданов (1732–1812) – Эстәрлебашта имам һәм шәйх булган кеше, чыгышы белән Бөре ягыннан.

[2] Хөснетдин ахунд Жданов (1767–1869) – Нигъмәтуллаһ Тукаевның кияве, Эстәрлебаш мәдрәсәсендә белем алган, Балыклыкүл авылында мәдрәсә тоткан.

хәлифә булып калганмы икәнен белгән кеше булмады. Гаделшаһ хәзрәт заманында Эстәрлебаштан төрле фәннәрне белүче галимнәр чыгып, араларыннан игътибар ияләре чит җирләрдә дәрес бирә башлаганнар, шул заманнан, ягъни якынча 1700 еллардан башлап, Эстәрлебаштан галим кешеләр чыга башлаган, бәлки аннан элегрәк дип тә хисап кылырга мөмкин. Гаделшаһ хәзрәт 80 яшендә, 1812 елда вафат булган. Гаделшаһ хәзрәт ахунд булган имеш, диләр. Мәрхүм галим гамил һәм дәрескә гаять дә оста һәм тәкъва адәм иде дип әйтәләр (рәхмәтуллаһи галәйһи). Гаделшаһ хәзрәт заманында һәм бераз Нигъмәтуллаһ хәзрәт заманында улы Дәүләтшаһ хәзрәт Эстәрлебашта бик тырышлык белән дәрес укыткан һәм аннан соң Бохараи шәрифкә киткән, диләр. Гаделшаһ хәзрәттән соң Эстәрлебашта шәйх Нигъмәтуллаһ хәзрәт вәләде Биктимер вәләде Тукай (Бәктә хәзрәт исеме белән мәшһүр рәхмәтуллаһи галәйһи) булгандыр. Мәрхүм хәзрәт 1773 елларда туып, 1801 елларда Бохараи шәриф якларына заһир һәм батыйн гыйлемнәр өйрәнер өчен киткән. Шул 1801 елда Нигъмәтуллаһ хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) Эстәрлебаштан март аенда чыгып киткәне кайбер иске кәгазьләрдә язылганы күренәдер. Мәрхүм Нигъмәтуллаһ хәзрәт Бохараи шәрифкэ барыр алдыннан Мәчкәрәдә Мөхәммәдрәхим ахунд хәзрәттә укыган. Гаделшаһ хәзрәт вафатыннан соң, 1812 елдан башлап, 1813 елның 22 августында указ алып, Эстәрлебаш мәдрәсәсендә мөдәррис һәм мәчетендә имам булып, заһир гыйлемнән дәрес биреп, гыйлеме тарикать вәл-хакыйкатьтә (тарикать гыйлемендә) мөршиде камил һәм шәйхе фазыйл булып, кешеләрне туры юлга өндәү белән шөгыльләнеп, заманында көче җиткәнче бидгатьне егуда һәм һәртөрле җәмгыять катлавындагы кешеләрне рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте буенча яшәүгә өндәүдә бик күп тырышлык сарыф итте. Тирә-якта җыеннар, нәүрүз көннәрендә туй үткәрүдән тыелулар, мәеттән соң өченче, җиденче һәм кырыгынчы көннәрдә аш үткәрүләр кебек нәрсәләрне бетерүләр, ишрак халкалар[1] һәм игътикәфләрнең халык арасында

[1] *Ишрак халкалар* – кояш чыгып 45 минут үткәннән соң түгәрәк саф рәвешендә утырып зекер итү.

таралуы Нигъмәтуллаһ хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) тырышлыгы белән башланган иде диләр. Бу тырышлык исә «...Мән сәннә сүннәтән хәсәнатән фәләһу әҗрүһә вә әҗрү мән гамилә биһә...» хәдиси шәрифенең растлавы буладыр. Нигъмәтуллаһ мәрхүм хәзрәт заманында Эстәрлебаштан күп галимләр заһири һәм батыйни гыйлемне өйрәнеп, төрле якларга таралдылар. Заманында укыган, укымаган, галим һәм надан, фәкыйрь һәм җитәкчеләрнең күбесе мөселман иде. Эстәрлебашка килгән олуг кешеләрдән берсе мәрхүм Җиһангир хан һәм Ширгази хан[1] иде дип әйтәләр. Җиһангир ханның улларыннан берсе 1840 еллар чамасында Эстәрлебашта мәдрәсәдә гыйлем алган. Мәрхүм Нигъмәтуллаһ хәзрәт заманында Эстәрлебашта гыйлем күтәрелеп, шәкерт күбәя башлаганлыктан, мәчет һәм мәдрәсәләрне зурайтырга хаҗәт төшеп, мәчет һәм мәдрәсәләр өчен күп акча, ярдәм һәм тырышлык сарыф ителгән. Мәчет әүвәлге урыннан йөз таяк кадәр түбәнрәк, авылның уртасына күчереп салынган. 1814 елда, мәрхүм Нигъмәтуллаһ хәзрәт заманында, Эстәрлебашта бакчаларда агачлар утыртыла башлаган. Шул заман утырткан карагайларның барысы хәзер дә үсә. Агач гыйлемен белүчеләр карагайларны 80 яки 90 еллык диләр. Мәрхүм Нигъмәтуллаһ хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) заманында Эстәрлебашка 1836 елда фонтан китертелгән, шул фонтан хәзер дә бардыр. Китерелгәннән бирле өч мәртәбә тәгъмир (ремонт) кылынды; суыннан шул көннән бу көнгә кадәр һәр көн ничә мең җан инсан һәм хайван файдаланып торалар (Аллаһы Тәгалә сәвабын насыйп итсен). Нигъмәтуллаһ хәзрәт гыйльме батыйнда камил булып, күп вакыт тарикать гыйлеме белән шөгыльләнеп, гыйльме заһирга кәмаль тырышлык күрсәтә иде. Заманында басмаханә һәм китаплар аз булганлыктан, китаплар сатып алыр өчен күп тырышлык һәм маллар сарыф итте диләр; үз кулы белән язган җыентыклары бардыр, һәр җирдән һәм һәр фәннән нәкыль-күчермәләре бар. Заманында тәфсире Казыйдан[2] дәрес алганы

---

[1] Җиһангир хан Бүкәй хан углы (1802–1844) вә Ширгази хан – казакъ ханнарыннан.

[2] Тәфсире Казый – бөек галим Бәйзавый (вафаты һиҗри 685 елда) хәзрәтләренең, Коръәни Кәрим аятьләрен җитди шәрехләгән зур күләмле хезмәте.

өчен, тәфсире Шәйхзадә нөсхәсен күчертеп алырга Эстәрлебаштан Бәйрәкәгә билькасд (ниятләп) барып кайтты диләр; заманыннан калган Эстәрлебашында язылган һәм Бохараи шәрифтән алдырган күп кулъязма китаплар бу көнгә кадәр сакланган.

Мәрхүм Нигъмәтуллаһ хәзрәтнең 1810 елда олы улы Мөхәммәдхарис хәзрәт дөньяга килде: 1814 елда икенче улы туды, Мөхәммәдхәррас дип исем бирелде. 1833 елда улы Мөхәммәдхарис хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) Бохараи шәрифкә Оренбургның генерал-губернаторы тарафыннан 1833 елның 24 сентяберендә Бохарага барырга бирелгән 1380 нче номерлы рөхсәт кәгазе белән заһир һәм батыйн гыйлем өйрәнер өчен сәфәргә чыкты, 1841 елда гыйлем алып исән-сау кайтты; 1841 елда июльнең 14 көнендә «Ыргыз буендан сәламәт бу йиргә килдек» дип язган хаты бар. 1841 елда шәйх Нигъмәтуллаһ улы Мөхәммәдхарис хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) Бохараи шәрифтән заһир һәм батыйн гыйлемнәрне өйрәнеп һәм әхлакы хәмидә алып, сау-сәламәт кайтып, шул ук елны дәрес укытырга башлап, бер-ике елдан соң яран (дуслар, мөрид) тәрбия итәргә башлады диләр. 1844 елда икенче улы Мөхәммәдхәррас мәрхүм (рәхмәтуллаһи галәйһи) хәзрәтләре Бохараи шәрифкә гыйлем алыр өчен сәфәргә чыкты; ул елларда Эстәрлебашта җәмгыять күп иде, һәр яклардан гыйльме заһир һәм гыйльме батыйн алыр өчен килгән шәкертләр кәмаль тырышлык белән гыйлем һәм әхлак өйрәнеп, хосуси булараk әдәп ягыннан иң югары дәрәҗәләргә ирештеләр. 1844 елда, һиҗрия белән 1290 елда кәттә хәзрәт шәйх Нигъмәтуллаһ Биктимер улы (рәхмәтуллаһи галәйһи) хәзрәтләре 27 март көнне җитмеш өч яшендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчтеләр. Мәрхүм гаять галим, гамиле мөттәкый (тәкъва) һәм шәйхе камил, амири билмәгъруф вән-нәһи ганил мүнкәр (Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелган), Рәсүлуллаһның сөннәте белән шөгыльләнеп, хадимул-гыйльм (гыйлем хезмәтчесе) һәм мөршиди камилләрдән (иршад итүчеләрдән) иде. Мәрхүм Нигъмәтуллаһ ишан хәзрәттән соң улы Мөхәммәдхарис Нигъмәтуллаһ улы (Ишан хәзрәт исеме белән данлыклы) Эстәрлебашта имам, мөдәррис һәм Эстәрлебашның шәйхе булды.

Мөхәммәдхарис хәзрәткә кануни указ алганчыга кадәр, Оренбург мөфтие тархан Габделвахид Сөләйманов хәзрәтләре тарафыннан 1844 елда 4 апрельдә Эстәрлебаш авылында мәчеттә имам булып һәм мәдрәсәләрдә һәр фәннән дәрес укыту өчен дип бирелгән рөхсәт кәгазе бардыр. Шаять шул елларда кануни указ да бирелгән мөгаен. Мәрхүм Мөхәммәдхарис хәзрәтләре 1810 елда дөньяга килеп, 1833 елда Бохараи шәрифкә барып гыйльме заһир һәм батыйн өйрәнеп, 1841 елда сәламәт кайтып дәрес укыта һәм тәгълим кыла башлап, шәехлек дәрәҗәсенә ирешеп, 1844 елда атасының урынына камил хәлифә булып калдылар. 1846 елда Каргалыда Габдуллаһ кантун Дәүләтшаһ Чынлы улы хәзрәтләренең кызын алып кияү булдылар. Мәзкүр Габдуллаһ кантун мәхдүм акыллы, әһле фирасәт (зиһен иясе) һәм игътибарга лаек кеше иде, 1883 елда вафат булды. Мөхәммәдхарис хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) заманында Эстәрлебашта һәр фәннән дәрес укыту һәм тәгълимләр күбәйде, хәлфәләр күп булып һәркайсысы төрле фәннән дәрес укытып китабәт һәм мөкаләмә кылышу (гарәпчә язу һәм сөйләшү) мәшһүр булды. Хәлфәләрнең һәркайсысы үзләренә махсус мәдрәсәләрдә шәкертләргә һәркайсының дәрәҗәсенә күрә дәресләр өйрәтеп, шәкертләр исә хәзрәтнең дәресенә вакытында һич соңга калмыйча хәзер булалар иде; бу дәресләр гыйльме-ысуле һәм Хәдисдән, Тәүзыйх, Тәлхис, Мишкәт һәм Тәфсире Казыйдан булалар иде. Укучылар арасында галимнәре һәм сүзләшергә тырышучылары, хәзрәттән рөхсәте камил һәм ишарә алып, дәресләрдә күп мөкаләмә (гарәпчә сөйләшеп) һәм һәркем үз белгәненчә тәкърирләр кылып (дәрес аңлатып), кайбер дәресләр ике-өч сәгатькә кадәр хәтта тагын да күбрәк вакытка сузыла иде. Бу заманнарда Эстәрлебашка гыйльме заһир һәм батыйн өйрәнер өчен килүчеләр элеккесеннән күбрәк булды. Кыргыз якларыннан, Минзәлә, Оренбург һәм Казан тирәләреннән һәртөрле голяма, әгьния, үмара һәм гавамнардан (галим, бай, җитәкче һәм гади халык арасыннан) күп кешеләр кайберләре гыйльме заһир һәм батыйн өйрәнер өчен, кайберләре дә изһару ухуввәт филләһ (Аллаһы Тәгалә юлында кардәшлек, якынлык күрсәтү) өчен киләләр иде... Бу заманнарда кәттә хәзрәт

(рәхмәтуллаһи галәйһи) вакытларыннан калган Эстәрлебаштагы мәчеткә җәмәгать сыймый башлады; шул сәбәптән олы бүлмәне 1858 елда төзеделәр, эченә дүрт йөзгә якын кеше сыядыр. 1852 елда энесе Мөхәммәдхәррас Нигъмәтуллаһ улы хәзрәтләре Бохараи шәрифтән сау-сәламәт әйләнеп кайтып гыйлем таратуга кереште. Бу вакытлар Эстәрлебашның шөһрәт тапкан вакытларыннан иде. Һәр яктан Эстәрлебашка галимнәр арасыннан күп кешеләр килеп мөслим (мөселман) булып Эстәрлебашны мактыйлар иде. Мәрхүм Габдессәлям һәм Габделвахид мөфти хәзрәтләре Эстәрлебашына берничә тапкыр килделәр диләр; мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев хәзрәтләре дә Эстәрлебашны яратучылардан берсе иде; Эстәрлебашында өй төзетеп, үз теләге белән килеп торыр иде; соңыннан өен вакыф[1] итеп калдырды (Аллаһы Тәгалә кабул итсен). Галим һәм игътибар иясе кешеләр арасыннан Килем Хөсәен хәзрәт, Урманай[2] Габделгазиз хәзрәт, Бикбау[3] Габделгалим хәзрәт, Чакмак[4] Габдуллаһ хәзрәт, Бәйрәкә Габделгали хәзрәт, Мәчти[5] Әхмәдҗан хәзрәт һәм Такталачык[6] шәйхе Фазлуллаһ хәзрәтләр (рәхмәтуллаһи галәйһим әҗмәгыйн) һәр ел Эстәрлебашка килеп, бераз торып, гыйлем таратып һәм изһарү хуб филләһ кылып (Аллаһы Тәгалә юлында кардәшлек, якынлык күрсәтеп) китәләр иде. Эстәрлебашта шәкерт күп булганлыктан, Мөхәммәдхарис хәзрәт мәрхүм заманында күп мәдрәсәләр яңадан төзелде, таштан суханә төзелеп, өстендә Мөхәммәдхщррас хәзрәт өчен дәресханә төзелде. Хәлфәләрнең барысы дәрестә куәтле булганыннан һәм Мөхәммәдхарис хәзрәт Эстәрлебашта икенче имам өчен указ алып тарикать гыйлемен тараткач, дин һәм дөнья иң югары мәртәбәләргә ирешкәннән соң, Мөхәммәдхарис хәзрәт Хаҗ сәфәренә барырга ният иттеләр. 1859 елның 24 декаберендә

---

[1] *Вакыф* – берәр кеше тарафыннан килерен җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал, милек.

[2] Урманай – Татарстанның Минзәлә төбәге.

[3] Бикбау авылы – Татарстанның Минзәлә төбәге.

[4] Чакмак – Татарстанның Мөслим төбәге.

[5] Мәчти – Татарстанның Актаныш төбәге.

[6] Такталачык – Татарстанның Актаныш төбәге.

Оренбургның генерал-губернаторы тарафыннан рөхсәт, ягъни Хаҗ билеты бирелеп, 1860 елда Хаҗ сәфәренә чыкты. Сәфәрдә Шам Шәрифкә һәм Мәдинә-и Мөнәүвәрәгә барып, Хаҗ кылып, 1860 елда сау-сәламәт кайтып җиттеләр. Билетында 3 августта Истанбулда, 1860 елда 11 августта Адиста (Одессада) дип язылган билге күренәдер. Хәзрәт сәфәргә чыкканда озата баручы дуслары һәм кайткан вакытта каршы алыр өчен килүчеләр өч меңнән күбрәк булды дип әйтелә. Хаҗ сәфәреннән исәнлек-саулык белән күп китаплар алып кайтты. Хаҗдан соң Мәккә һәм Мәдинә тәртибенә күрә рамазан шәрифнең ахыргы ун кичендә тәравих намазы вакытында хәтем булып, сәхәрдән соң толуге фәҗердә (иртәнге намаз вакытында) хәтме «Сәхихи Бохари» (Сахихи Бохари исемле хәдис китабы хәтме) булып дога мәҗлесе була иде. Мәрхүм Мөхәммәдхарис хәзрәт ике-өч мәртәбә Казан ягына чакырылып кунак булып, һәм өч мәртәбә Урал өлкәсе, ягъни Җаек тарафына, беренче мәртәбә 1863 елда Глинни дигән җиргә Исәнбаевлар гаиләсе чакыруы белән махсус кунак булып барды; һәм киләсе елга шул ук Исәнбаевларның улы Габдуллаһ мәхдүмгә никах кылу өчен, туй мәҗлесенә барды; 1870 елда Җаек кальгасына Әбүбәкер белән Габбас Белоусовларга улы Гобәйдуллаһ мәхдүмгә кыз ярәшергә туйга барды; барганда һәм кайтканда юлда һәм барган җирләрдә һәр яктан галим, бай һәртөрле кешеләрдән торган җыелышлар булды дип сөйлиләр; бу елларга кадәр шул мәҗлесләрне күргән һәм сәфәрләрдә булган кешеләр һәр кайсылары бу вакыйганы шатлык һәм мәхәббәт белән зикер итәләр. 1893 елны Ялпакталга барган вакытыбызда казакъ картларыннан бер карт мәрхүм Мөхәммәдхарис хәзрәтләре бу якларга килгән вакытларында мәҗлесләрендә булган бер казакъ карты безгә: «Балалар Локман Хәким[1] мең ел яшәде дип әйтәләр, әмма ки ул мең ел тормаган икән, һәр мәҗлесенә карап кайберен бер елга, кайберен биш елга хисап итеп мең яшь шуның белән хисап иткән икән, әмма ки сезнең бу Мөхәммәдхарис хәзрәтнең мәҗлесенә катнашырга мөмкинчелегез булды, сез мең

[1] Локман Хәким – Коръәни Кәримдә телгә алынган шәхес.

яшәдегез, гафил булмагыз, ганимәт (бәхетле кеше иканегезне) белегез», – дип әйтә иде. Мөхәммәдхарис хәзрәт галим, гамил (гыйлеме белән гамәл итүче), тәкъва, матур һәм килешле итеп аңлатып сөйләүгә оста, гүзәл холык иясе һәм гаять тә юмарт булып, яхшылыклары һәртөрле кешегә берүк тигез иде, йортында һәрвакыт ничәмә кешеләр кунак булып, кайбер көннәрдә йөзләп кеше дәстәрханыннан сыйландылар. Бу юмартлыгыннан башка, гыйльме тыйбтан (медицина) насыйбы булганыннан ничәмә авыруларны дәва итеп, киемсезләргә кием биреп, утарханә дигән урында кырыкка якын ятимнәр һәм фәкыйрьләр өчен фәкыйрьханә тотып, ничәмә еллар аларны туйдырып асрады. Бер ачлык елны тирәякта иген һәм бәрәкәт булмавыннан ачлык белән интеккән халыкка бер елда өч мең пот кадәр ашлык таратты диләр. Хәзрәтнең шөһрәте, һәркемгә булган яхшылыгы һәм дәүләткә каршы мәхәббәте мәэмүрләргә (чиновникларга) мәгълүм булып, бөек падишаһ хәзрәтләренә җитешеп, император Александр әс-сани (икенче) хәзрәтләре 1869 елның 16 августында биргән әмере белән тарханлык дәрәҗәсенә иреште. Тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең Эстәрлебаштагы биналары арасыннан истәлек итеп кешеләр һәм хайваннар өчен, ак таштан юнып, гөмбәз белән эшләнгән зур таш күпере бар. Тархан Мөхәммәдхарис хәзрәт гыйльме, хильме һәм юмартлыгы белән һәркемнең игътибарына лаек булып, үз заманында әмри билмәгъруф вән-нәһи ганилмүнкәрләрдә (Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелуда) сүзе һәр кешегә үтә иде: заманының мәэмүрләре (чиновниклары) кайбер старшиналарны хәзрәт янына әдәп алыр өчен җибәрәләр иде. 1869 елда Оренбург якларында сәхрә казакълары арасында талаш һәм тынычсызлыклар мәйданга килгәндә, Оренбургның генерал-губернаторы Крыжановский тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтне чакырып: «Сезләрне сүзе үтүче кеше дип ишетәбез, казакъларга мәслихәт итеп араларында үтерешү булмасын», – дип һәм тынычлык эчендә яшәүләре өчен өндәп кәгазь язуын үтенүе буенча, шул 1869 елның 23 хәмәлендә[1] ка-

[1] 22 марттан 22 апрельгә кадәр вакыт арасы.

закъларга нәсыйхәт язды; һәм шул нәсыйхәт буенча казакълар тынычсызлыкны ташлап, иминлеккә ирештеләр. Эстәрлебашта шул кәгазьнең нөсхәсе бар, имзасы һәм пичәте бар; нөсхәсендә күбрәк Ислам дине һәм милләт куәтләндерү өчен тынычлык кирәк дигән сүзләр язылган. Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәт хәзерге дөньядан хәбәрдар кеше булып, фәннәр өйрәнергә һәм телләр белергә зарур һәм кирәк дип әйтә иде диләр. Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) тырышлыгы һәм максаты изһару үлфәт (Аллаһы Тәгалә юлында кардәшлек, якынлык күрсәтү), вәгазь һәм нәсыйхәт иде; гаять галим, тәкъва һәм шәйхе камил булып, Бохараи Шәрифтәге мәүләнә шәйх Ниязколый әт-Төркмәни хәзрәтләренең хәлифәсе иде; 1870 елның икенче ноябрендә һиҗрия белән 1286 елда шәгъбан шәрифтә сәнәи камәрия (ай елы) белән алтмыш өч яшендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчтеләр (рәхмәтуллаһи рәхмәтән вәсигатән); җеназасендә өч меңнән артык кеше булды һәм вафатыннан соң берникадәр мәрсияләр (кеше вафат булганнан соң, аны мактап язган шигырь, мөнәҗәтләр) язылды.

Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәттән (рәхмәтуллаһи галәйһи) соң Эстәрлебашта мәчет һәм мәдрәсәгә рәис булып Мөхәммәдхәррас хәзрәт Нигъмәтуллаһ улы (рәхмәтуллаһи галәйһи) калды. Мөхәммәдхәррас хәзрәт 1814 елда дөньяга килеп, 1844 елда Бохараи шәрифкә китте. 1856 елда Бохараи шәрифтән сау-сәламәт кайтып, имам булып тәгълим һәм дәрес бирү белән шөгыльләнде, 1870 елда Эстәрлебашта хәлифә булды. Ләкин авыруы аркасында йортыннан еш чыга алмады. 1871 елның 30 ноябрендә илле җиде яшендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Мәрхүм гыйлеме белән гамәл итүче һәм шәйхе камил иде (рәхмәтуллаһи галәйһи васигатән).

Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәттән соң урынына улы Габдуллаһ мәхдүм имам булды. Мөхәммәдхәррас хәзрәттән соң урынына улы Латыйфуллаһ мәхдүм имам булды. Латыйфуллаһ мәхдүм 1878 елның август аенда вафат булды (иннә лилләһи һәм иннә иләйһи раҗигун). Латыйфуллаһ мәхдүмнән соң урынына тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең икенче улы Гобәйдуллаһ

мәхдүм имам куелды; бу елларда Эстәрледә ахунд һәм мөдәррис Гобәйдуллаһ хәзрәт булып, мәдрәсәләрдә дәрес бирүче хәлфәләрнең өстендә рәис һәм мөдир иде. Эстәрлебашта мәрхүм тархан Мөхәммәдхәррас хәзрәттән соң Эстәрлебашның шәйхе булып калган кеше шәйх Зәйнуллаһ Хосраушир улы иде. (Бамир хәлфә исеме белән данлыклы) Зәйнуллаһ хәзрәт хәлифә Ниязколый әт-Төркмәни хәзрәтнең хәлифәләреннән булган Эстәрлетамак Шәрәфетдин[1] хәзрәтнең Чиләбе якларындагы хәлифәсе Габделхакны мәрхүм хәзрәттән камиллек, рөхсәт һәм иҗазәт алып, шәйхлеккә ишарәләре булганыннан Эстәрлебаш шәйхе булдылар. Әмир хәзрәт 1810 елларда дөньяга килде, 1827 елда Өфе өязе Арслан авылыннан Эстәрлебашына шәкерт булып килеп, гыйлем алып, мәдрәсәдә торып, тәсаувыф әһеле булып, хәзрәтләрнең хезмәтендә җитешеп әдәп өйрәнеп, һәрвакыт йортта һәм сәфәрдә булган вакытларында көндез һәм төнлә һәр өч хәзрәт заманында яннарында булып, гүзәл холык һәм тәкъвалык белән камиллеккә иреште. Мөхәммәдхарис хәзрәтнең хәлфәләре Мөхәммәдхафиз һәм Мөхәммәдьяр хәлфәләр үз заманында вафат булдылар һәм күбесе авылларында имам һәм мөдәррис иделәр. 1875 елларда мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) заманыннан калган хәлфәләрнең иң мәшһүрләреннән берсе Габдуллаһ хәлфә бине Нигъмәтуллаһ (Хаҗи Хәлфә исеме белән данлыклы) (Сарапул өязе Буби авылыннан) 1864 еллар чамасында Эстәрлебашка Казаннан, Мөхәммәдкәрим хәзрәт мәрхүмнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) мәдрәсәсенә килеп гыйлем һәм фәннәр өйрәнгән иде. Эстәрлебашта һәр гыйлемлеккә көч сарыф итеп, хосуси буларак фикыһ һәм әл-осуль гыйлеменә сәләтле иде; 1880 елларда Эстәрлебашның иң галим кешеләреннән берсе булып санала иде. Мәрхүм тархан Мөхәммәдхәррас хәзрәт заманыннан соң Эстәрлебашның күпчелек шәкерт һәм мәхдүмнәре Гобәйдуллаһ, Латыйфуллаһ, Хәбибуллаһ һәм башка-

[1] Шәрәфетдин бине Зәйнетдин әл-Эстәрлетамакый. Казанда, Бохарада һәм Эстәрлетамакта уку-укыту эшендә, шәехлектә һәм башка очракларда мулла Нигъмәтуллаһ белән бергәләп эш иткән. 1262 (1845) елның шәгъбан аенда, җитмеш җиде яшендә Эстәрлетамак шәһәрендә вафат була.

лар һәркайсылары Габдуллаһ хаҗи хәлфә мәрхүмнең шәкертләре иделәр. Габдуллаһ хаҗи хәлфә егерме елга якын Эстәрлебашта камил тырышлык белән дәрес биреп тәгълим итте. 1883 елда рамазан шәриф **гаетеннән** соң август аенда Хаҗ сәфәренә китеп шул ук елны сау-сәламәт Хаҗ кылып, Хаждан соң авырып Мәдинәи Мөнәүвәрәгә килеп авыруы артып, гашура[1] көн 1883 елның 2 ноябрендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте; кабер шәрифе Мәдинәи Мөнәүвәрәдәдер. Мәрхүм галим, гамил, тәкъва һәм гыйлем хезмәтчесе кеше иде (рәхмәтуллаһи галәйһи васигатән). Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) 5 нче улы Габделмәҗид мәхдүм иде, яшь чагыннан Минзәлә өязе Чакмак авылында булган Габдуллаһ хәзрәт мәдрәсәсендә шәкерт булып гыйлем өйрәнеп, бөтен Чакмак авылы тирә-ягында мәхәббәт хасил итеп, 1886 елда хәзрәтләренең фатихасы белән Бохараи шәрифкә барып гыйлем һәм фәннәр өйрәнергә тотынды; 1890 елда Эстәрлебашның ихласлы мөридләреннән (ишан шәкерте) һәм Илек шәһәренең игътибарга лаеклы яхшы сәүдәгәрләреннән булган Гобәйдуллаһ хаҗи исемле кеше Габделмәҗид мәхдүмгә мәхәббәт күрсәтеп хәраҗат (чыгымнар, акча) җибәреп, Бохараи шәрифтән кайтарып аңа кызын бирде һәм июнь аенда никах, зөфаф һәм туй мәҗлесләре үткәрде; җәй айларын Илек һәм Эстәрлебаш арасында үткәреп, көз килгәч, Бохараи шәрифкә гыйлем һәм фәннәрен камилләштерер өчен сәфәргә чыкты; 1892 елда Эстәрлебашка кайтып, гыйлем һәм фәннәр укытуга кереште. Габделмәҗид мәхдүм дәрескә һәм тәкърирргә сәләтле һәм эшендә тырыш адәм булганы өчен, дәресләр башлаганда шәкертләрнең барысы бик сөенделәр. 1893 елның 10 мартында Хаҗ сәфәренә китте; Хаждан Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә барып, энесе Габделкадыйр мәхдүм белән очрашып, Хаҗ тәмамыннан соң ваба авыруы белән фәкать ун сәгать авырып, 1893 елның 12 зөлхиҗҗәсендә (14 июнендә) егерме алты яшендә вафат булды; кабере Мәккәи-Мөкәррәмәдә Җәннәти Мөгаллә исемле зираттадыр. Мәрхүм

[1] Гашура көне – мөхәррәм аеның унынчы көне.

хаҗи Габделмәҗид мәхдүм гаять фазыйл, галим, юмарт һәм һәркемгә мәхәббәтле бер зат иде, гомерен гыйлем юлына сарыф итте. Аллаһы Тәгалә аз гомеренә күп саваплар бирсен (рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән).

Мәрхүм Мөхәммәдхарис хәзрәтнең өченче улы Хәбибуллаһ хәзрәт мәхдүм 1856 елда дөньяга килде; яшь вакытларында Эстәрлебашында Габдуллаһ хаҗи хәлфәдән дәрес алып, 1872 елда Чакмак Габдуллаһ хәзрәт мәдрәсәсенә китте. 1872 елдан 1878 елга кадәр Чакмакта гакаидтән кайбер шәкертләргә дәрес укытып, шул 1878 елда Бохараи шәрифкә китте. Бохараи шәрифтә ике яки өч ел торып, гыйлем һәм фәннәрне камилләштергәннән соң, Үргәнечтә мәрхүм шәйх Ниязколый әт-Төркмәни хәзрәтнең хәлифәсе булган мәрхүм шәйх Мөхәммәдшәриф әл-Үргәнчи ән-Нугай хәзрәтнең улы һәм хәлифәсе булган Мөхәммәдзакир хәзрәткә яран (дус, мөрид) булып изен һәм рөхсәт алып, 1884 елның 24 августында сау-сәламәт Бохараи шәрифтән Эстәрлебашка кайтты, һәм шул ук елның ноябрь аенда Тәфсире Казыйдан дәрес бирә башлады. Дәреснең башында «Хайрукүм мән тәгалләмәл Куръәнә вә галләмәһү» (Сезнең иң хәерлегез Коръәнне өйрәнеп, башкаларга өйрәткәнегездер) хәдисе шәрифен укып «Амин шулай булса иде» дип, нотыклар әйтеп, догалар үтенеп, Бохараи шәриф тәртибе буенча ифтитах (кереш) мәҗлесе ясап дәрес башлар иде. Хәбибуллаһ мәхдүм хәзрәт Эстәрлебашта 1884 елдан башлап 1893 елга кадәр тәфсир, хәдис, осуль һәм фикыһтан, нәхү һәм кәләмнән чын тырышлык белән, мәшәкать һәм кәсеб итүне ташлап, ун ел кадәр дәрес бирде. 93 елларда инспектор тарафыннан мәнегь (тыю) кәгазе килү сәбәбе белән, бер вакытлар дәрес укытуыннан туктап торса да, 95 елларда министр тарафыннан рөхсәт алып, яңадан дәрес укытырга кереште. Хәбибуллаһ мәхдүм хәзрәт галим, фазыйл һәм батыр сүзле кеше иде. Үргәнечтә шәйх Мөхәммәдзакир хәзрәт Мөхәммәдшәриф улы тарафыннан кешеләрне тарикатькә өндәү һәм иршад әмере бирелгән булса да, ачык итеп яран (дуслар, мөрид) тәрбияләү белән шөгыльләнмәде. «Башта заһир гыйлем кирәк: батыйн гыйлем, заһир гыйлем чиләгенә тамчы-тамчы салган суыбыздыр, әүвәл чиләк таза

булсын, чиләк таза булмаса, тамчылап тамган су пычранып торыр һәм файдасы да булмас; башта чиләк таза булсын, соңыннан иншаллаһ су булыр», – дип мисал китерә иде. Хәбибуллаһ мәхдүм хәзрәт амири бил-мәгъруф (кушканнарны үтәүче) һәм сахибул-гайрәт (тырышлык иясе) булып, Эстәрлебашта гыйлем таратып, 1897 елның 20 гыйнварында кырык бер яшендә вафат булды (рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән).

Тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) бишенче улы Габделкадыйр мәхдүм (1866 елда дөньяга килде) башта Эстәрлебаш мәдрәсәсендә торып, соңыннан 1889 елда Хаҗга барып, Хаждан соң Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә гыйлем алып һәм тасхихи кыйраәт итеп (Коръән укуын гүзәлләштереп), ике мәртәбә Хаҗ кылганнан соң, 1893 елның 10 октябрендә сау-сәламәт Эстәрлебашка кайтты; хәзерге вакытта да Эстәрлебаштагы шәкертләргә Коръәнне дөрес итеп укуны өйрәтеп һәм мәдрәсәнең мөдире булып торадыр.

Эстәрлебашта гыйлем алып бу заманнарда исемнәре офыкка таралган галим һәм голямалардан сау-сәламәт булып гыйлем бирү белән шөгыльләнүче, мәчетләрдә имам булып торучы, вәгазь һәм нәсыйхәт итүчеләрнең мәшһүр һәм игътибарга лаек булганнарыннан кайберләре: Бәйрәкәдә Габделгали хәзрәт, Ялпакталда Габдуллаһ ахунд, Җаек кальгасында Габделсалих ахунд, Әстерханда Габделфәрид ахунд, Күкчәтауда Мөхәммәдсадыйк мулла, Нижний Новгородта, ягъни Мәкәриәдә Сәмәрканд ахунд, Симипалада Мөхәммәдхәлим ахунд, Каргалы шәһәрендә Хәйруллаһ мәхдүмнәр һәрбере – Эстәрлебашта заманында шәкерт булган затлардыр.

Эстәрлебашында хәзерге көннәрдә элеккегечә һаман уналты мәдрәсә булып, һәр ел тәгъмирләре (ремонт) һәм тәрбияләре күренеп тора; ундүрт хәлфә Гобәйдуллаһ ахунд хәзрәт Мөхәммәдхарис улының (рәхмәтуллаһи галәйһи) карамагында шәкерт укыталар, һәр фәннән дәресләр укыла; шәкертләрнең саны элеккегедән төшкәне юк. 1897 елдагы гомуми санау буенча Эстәрлебаш мәдрәсәсендә кунучы шәкертләр биш йөз җитмеш кеше дип язылды. Гомуми санаудан соң кырыклап шәкерт та-

гын мәдрәсәгә гыйлем алыр өчен килгәннәр; мәдрәсәдә кырыкка якын яшәмичә килеп-китеп укучы шәкертләр дә бар; шул хисап белән Эстәрлебашта барысы алты йөз утызга кадәр шәкерт дәрес һәм тәгълим алып дин өйрәнү тырышлыгы эчендәдер. Эстәрлебашының яхшы якларыннан берсе: кыш көннәрендә мәчеттә, җәмәгать белән укылган намазларның күбесендә, бер имам артында меңгә кадәр җәмәгать җыелып намазлар үтәлә, бу Аллаһның рәхмәте һәм догаларның бәрәкәте беләндер мөгаен. Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең дүрт улының һәрбере Эстәрлебаш мәдрәсәләренең тәгъмир (ремонт) һәм тәртип (тәртип эчендә тоту) һәм тәрбияләре өчен тырышлык белән торалар. Аллаһы Тәгалә гыйлемгә иң югары мәртәбәләргә чыгарга, галимләргә һәм гыйлем өйрәнергә теләүчеләргә тәүфикъ һидаять бирсәң иде; падишаһыбыз император бөек Николай Александрович хәзрәтләренә озын гомерләр биреп, мөселманнарга каршы миһербан һәм шәфкатьләрне күбәйтеп, ризыкларыбызга бәрәкәт бирсәң иде, һәрвакыт гыйлем өйрәнеп, галимләргә игътибар биреп, гыйлемне мактау вә гыйлемлек юлында булып; үзеңнең катыңда кабул булган гыйбадәтләр белән сөенеч эчендә гомеребезне кичерсәк иде; изге, салих колларыңны телгә алган мәҗлесләрдә, иңе-чиге булмаган рәхмәтеңне өстебезгә файдалы яңгырлар кебек яудырып, изге, салих затларыңа кавышырга насыйп итсәң иде, дип һәр укучыдан ихласлы дога итү һәм фатиха укуларын үтенәм. Амин.

# ОПИСАНИЕ ДЕРЕВНИ СТЕРЛИБАША И СТЕРЛИБАШЕВСКОГО МЕДРЕСЕ

**действительного члена Уфимского губернского статистического комитета, магзума Шакира Харисовича Тукаева**[1]

На юг от губернского города Уфы, приблизительно в 150 верст, на запад от уездного города Стерлитамака в 55 верстах и от станции Уфимской железной дороги Шафрановой к востоку в 70 вер-

---

[1] По сведениям, ранее полученным сотрудниками Института В. Усмановым, Н. Насибуллиной от военного инженера-конструктора Мунасипова Халима Абдулмазитовича (1931–2013), во времена разрушения мечетей, закрытия медресе в советские годы Мухаметшакир хазрат успел передать семье Мунасиповых ряд книг и документов, среди которых была рукопись «Описание деревни Стерлибашево и Стерлибашевского медресе действительного члена Уфимского губернского статистического комитета, магзума Шакира Харисовича Тукаева». Далее этот труд, вместе с некоторыми редкими книгами, был передан в распоряжение свата Х. Мунасипова Абдулбария Мухаметхафизовича Ганиева, проживающего в Уфе. Год передачи рукописи точно неизвестен, предположительно 1960–1970-е годы. Позже эта рукопись, написанная на русском языке на кириллице в 1890 году передана на хранение в Фонд рукописей Государственной книжной палаты Республики Башкортостан. Труд М. Тукаева нашел отражение в трудах ученого Ш.Н. Исянгулова.

Для этого сборника труд «Описание деревни Стерлибашево и Стерлибашевского медресе действительного члена Уфимского губернского статистического комитета, магзума Шакира Харисовича Тукаева» взят из первоисточника и с комментариями отдельных мест предоставляется вниманию читателей. *Источник: Тукаев Ш.Х. Описание деревни Стерлибаша и Стерлибашевского медресе действительного члена Уфимского губернского статистического комитета, магзума Шакира Харисовича Тукаева Описание деревни Стерлибаша и Стерлибашевского медресе. 1890 г. Государственная книжная палата РБ. Рукописный фонд. Папка № 6. Рукопись. Без пагинации.*

стах, приблизительно под 53°24' северной широты и 73°5' восточной долготы находится дер. Стерлибаш. Она получила свое название по своему местоположению «Стерли» и «баш» (голова – исток, начало), будучи расположена по обеим сторонам реки Стерли недалеко от ее истока; правая часть селения меньше, на ровном месте, а левая половина расположена отчасти на равнине, и большая часть на южном склоне горы, которая защищает Стерлибаш от северных ветров. Река Стерли ведет свое начало из болотистого места, известного под названием Стерли, на расстоянии от деревни около 5 верст. С версту она течет маленьким ключом, верстах на 4-х от деревни, ниже горы Акчагула, с правой стороны сливается с маленьким светловодным ключом, текущим по каменистой местности Чияли-тубе. В 2 верстах ниже Стерли с правой стороны впадает в нее другой ключ Умартале-елга и немного ниже –третий ключ Карамалы-елга. После слияния этих ключей река уже под названием Стерли течет по направлению к СВ[1] и впадает в Ашкадар при слиянии его с Белой в 4 верстах ниже города Стерлитамака [1].

По Стерли на полуверсте ниже дер. Стерлибаша в местности Саз (болото) находится два серных источника, из которых местные жители берут воду для умывания, особенно весною, когда эта вода, как говорят жители, целебнее, чем в другое время года. Особенно вода полезна для умывания от чесотки.

С северной стороны Стерлибаша, как было выше сказано, возвышаются невысокие, но красивые горы, которые издали, представляются как бы волны и имеют по частям несколько названий: Кладбищенская, Чишма-баш-тау, Кум-тау, Кызыл-тау, Бикмет-тау, где добываются: дикий камень и хороший песок и глина, годные для выделки кирпичей.

К югу от Стерлибаша, где берет свое начало река Стерли, имеется лесу 480 десят., принадлежащий башкирам Стерлибашевского общества[2], но к сожалению, беспощадно вырубленный, за

---

[1] СВ – северо-восток.

[2] Башкиры-припущенники Стерлибашевского общества – это записавшиеся в башкирское сословие этнические татары. Здесь и далее по тексту термин «башкиры» или «башкиры-припущенники» следует понимать только как сословие.



Описаніе
деревни Стерлибаша и Стерлибашскаго медресе
(: Дѣйствительнаго Члена Уфимскаго Губернскаго Статистическаго Комитета, Магзума Шакура Хадисовича Тукаева :)

На югъ отъ губернскаго города Уфы, приблизительно въ 150 верстахъ, на западъ отъ уѣзднаго города Стерлитамака въ 55 верстахъ и отъ станціи Уфимской желѣзной дороги Шафрановой къ востоку въ 70 верстахъ, приблизительно подъ 53° 24' географической широты и 73°5' восточной долготы находится дер. Стерлибашъ. Она получила свое названіе по своему мѣсто-положенію „Стерли" и „башъ" (: голова — истокъ, начало :), будучи расположена по обѣимъ сторонамъ рѣки Стерли недалеко отъ ея истока; правая часть селенія меньше на ровномъ мѣстѣ, а лѣвая половина раскинута отчасти на равнинѣ, а большею частью на южномъ склонѣ горы, которая защищаетъ Стерлибашъ отъ сѣверныхъ вѣтровъ. Рѣка Стерли беретъ свое начало изъ болотистаго мѣста, извѣстнаго подъ названіемъ Стерли, на разстояніи отъ деревни около 5 верстъ. Съ версту она течетъ маленькимъ ключемъ, верстахъ на 4-хъ отъ деревни, ниже горы Акчагыла, съ правой стороны сливается съ маленькимъ свѣтловоднымъ ключемъ, текущимъ по каменистой мѣстности — Чишмутуръ. Въ 2-хъ верстахъ ниже въ Стерли съ правой стороны впадаетъ другой ключъ Умартале-елга и немного ниже третій ключъ Карамалы-елга. Послѣ сліянія этихъ ключей рѣка уже подъ названіемъ Стерли течетъ по направленію на С.В. и впадаетъ въ Ашкадаръ при сліяніи его съ Бѣлой, въ 4-хъ верстахъ ниже города Стерлитамака.

исключением маленького участка, оставленного для отапливания мечети и домов лиц духовного звания; этот участок во времена Хаджи Хазрета Тархана[1] служил пчельником и от этого и в настоящее время называется пчельником Хазрета. На месте бывшего леса в настоящее время имеются только кустарники, между которыми преобладает орешник, где в иные годы собирают довольно много орехов, как было, например, в 1878 и 1888 годах. Орехи продаются жителями дешево 60–55 коп. за пуд и даже дешевле; но тем не менее однакож, некоторые жители зарабатывают на этом до 50 руб. в лето. В Стерлибашевском лесу годами бывает и малина, из которой местные женщины самым простым образом приготовляют пастилу, в зимнее время она ценится довольно дорого, по 50 и 60 коп. фунт, но приготовление ее бывает в ничтожном количестве [2].

Из других ягод родится здесь рябина, которую жители вовсе не пользуются. Изредка бывает изобилие черемухи, которая собирается жителями и употребляется ими в пищу, а многие ее сушат на зиму, когда черемуху продают на базарах ценою по рублю пуд. В местных лесах калина родится почти ежегодно; она собирается и употребляется в пищу в различных видах, а излишек продают на базарах по 30 коп. за пуд. Почти каждое семейство припасает калины на зиму, и подвешивают ее на чердаках, где и сохраняется в продолжение зимы. Из ягод на полях Стерлибаша бывают земляника и костяника, которые родятся довольно обильно и собираются жителями для местного употребления. В садах поспевают ягоды и груши, довольно хорошего качества. Посаженные лет 50–60 тому назад березы имеют в диаметре вершк. 5–6,5. Есть и липовые деревья, которым насчитывают около 70 лет и сохранились они до сего времени без всяких повреждений и каждое лето цветут очень хорошо. Яблони, которые были посажены еще при Катта-Хазрете[2], около 60 лет тому назад, и в настоящее время

---

[1] Хаджи Хазрет Тархан – Мухаметхарис Тукаев сын Нигматуллы (отец Шакира Тукаева).

[2] Катта-Хазрет – Нигматулла Тукаев сын Биктимира (дед Шакира Тукаева).

дают довольно хорошие яблоки. Своею величиною обращает на себя внимание ива, которая, как говорят, существует около 70 лет. Сосны, которые более 50 лет тому назад, были привезены из-за Белой, служат неувядающею зеленью украшением сада.

Климат Стерлибаша вообще сухой. Лето бывает жаркое. Зимою бывают северные холодные ветра. Вообще климат Стерлибаша очень здоровый, никаких местных болезней не существует. Вблизи Стерлибаша больших болот нет. По берегам Стерли ни болот, ни озер нет.

Дер. Стерлибаш расположена, как было сказано выше, по обеим сторонам Стерли, занимает пространство около 10 десятин [3]. Улицы неправильные, кривые, больших улиц, пересекающих деревню по течению Стерли, две. Главная разрезающая дер. Стерлибаш имеет ширины около 10 сажень, но неправильная – кривая; всех переулков 7, которые пересекают главную под разными углами. На некоторых частях, около центра построены каменные тротуары, хотя узкие, но довольно хорошие для деревни, для чего материалом служит дикий камень, добываемый около Стерлибаша. Берега речки Стерли в дер. Стерлибашевой высокие, неудобные для переезда, и потому построен в 1870 году каменный мост покойным Тарханом[1]. Мост через Стерли перекинут аркой, сохранившейся до сего времени без всякой порчи. Работа произведена местными каменщиками, материалы добыты на месте. Главная часть большой улицы, около центра, в случае надобности, освещается.

Расположение построек в дер. Стерлибаш неправильное, никакие формальности плана не соблюдены; впрочем, для него специального плана не имеется. Большая часть домов окнами в ограду и внутри усадьбы, так что с окнами на улицу очень мало домов. Домов в Стерлибашевой 279, которые по большей части выстроены из черного леса; из соснового очень немного; крытых

---

[1] Тархан – Мухаметхарис Нигаметуллин (Тукаев), по архивному источнику, имам-хатыпом и мударрисом Стерлибашевской мечети стал по указу Оренбургского губернского правления за № 14816 от 20 октября 1845 г. См.: ЦГИА РБ. Ф. И-295. Оп. 10. Д. 66. Л. 106.

тесом около 50, остальные лубком и соломой. Дома разделяются на две категории: вакуфные и местных жителей, в число которых входят и дома духовных лиц. Принадлежащих вакуфу 30, крытых тесом 10, лубком 15, а остальные 5 соломой.

Всех медресе 16, из них одно крыто железом, крашенным в зеленый цвет, остальные все крыты тесом, из них с крашеными крышами 6, все на каменных фундаментах. Выстроены из соснового леса. Духовным лицам [4] принадлежат 5 домов, крытых тесом, один лубком; все выстроены из соснового леса на фундаментах. Принадлежащих местным жителям башкирам 125; они по большей части выстроены из черного леса; из них крытых тесом 6, лубком 45, остальные соломой; кроме упомянутых домов живут еще в мазанках, которых около 15. Построек из воздушного кирпича в дер. Стерлибашевой теплых, в которых живут сами хозяева, около 10, холодных немного. Все воздушные постройки – работа местных мастеров. Государственным крестьянам принадлежит 28 домов, которые выстроены из черного лесу, из соснового только один, который крыт тесом, лубком 5, остальные соломой, землянка одна, мазанок две.

Принадлежащих посторонним, проживающим в Стерлибашевой, мещанам Стерлитамакским, Оренбургским и Сеитовского посада Оренбургского уезда 12 домов; выстроенных из соснового лесу и крытых тесом 2, лубком 5, остальные соломой. Лицам разного звания – 15, из которых сосновых 3, остальные черного лесу; крытых тесом 5, лубком 5, остальные соломой.

Дома, принадлежащие местным крестьянам, башкирам и некоторым посторонним лицам состоят из одной комнаты, а некоторые и с перегородками. У лиц духовных, некоторых мещан и у немногих других дома состоят из 2–3 комнат. Согреваются дома преимущественно русским печами, но у немногих, более зажиточных, голландками. Домохозяев, имеющих холодные постройки очень мало; для скота хлева плетневые; которые по большей части летом отапливаются, а на зиму, осенью плетут новые.

Мечеть Стерлибаша отличается своею величиною [5], устройством красочная. Она выстроена в 1814 году при имаме мударисе

1. Куен дәфтәре кулъязмасы. Шариклы ручка белән язылган Махсус төпләнгән. Гарәп графикасында. 1980 елларныкы. Тышлыгы яшел төстә.

2. Сәхифәләр 10,0×14,0 см зурлыкта.

3. Тупланма бәет белән ачыла:

«Бисмилла» диеп башлыймын башын,
Әҗәл тикшерми картын һәм яшен.

Тыңлап торыгыз, колак салыгыз,
Бераз булса да гыйбрәт алыгыз.

Кызганыч хәлдә безнең балалар,
Изгелек юлдан мәхрүм калалар.

Зур биналарны ташлап китәрсең,
Углың-кызыңны хәйран итәрсең.

Фани дөньяны ташлап китәрбез,
Ташламый булмый, ни хәл итәрбез.

Сәфәрләр ерак, азык күп кирәк,
Намаз артыннан теләек теләк.

Дөнья кирәген тапмый калмыйсыз,
Ахирәт хәлен искә алмыйсыз.

Якты дөньяга кунакка килдек,
Үлем хәлләрен күрәсен белдек...

4. 10б биттән бу әсәрнең үлчәм-вәзене үзгәрә:

«Мөбарәк!» – дип, кардәшләрем,
Нәсыйхәтләр укыйм сезгә,
Моны ишетеп кабул күреп,
Догалар кыласыз безгә.

Безнең күңел шуны көтә,
Сездин дога өмет итә,
Мөэминнәрнең догалары
Кертер безне җәннәтләргә...

5. 15 а биттә әсәр тәмамлана:

Коръән укыр – хәмид булыр,
Күңелгә ул дәва булыр,
Кабергә һәм юлдаш булыр,
Ятла «Тәбарәк», «Ясин»не.

Бу дөньяга күпләр туган,
Туганда кайгылы булган,
Бар да дөньяны куйган,
Ятла «Тәбарәк», «Ясин»не.
Әмин,
Йа Рабби илаһи, әмин!

6. 15б биттән яңа әсәр башлана:

«Бисмиллаһир-рахманир-рахим!»

«Лә иләһи илләл-лаһ» –
Гарше-Көрси баскычы,
«Лә иләһи илләл-лаһ» –
Җиде оҗмах ачкычы.

Караңгы гүр яктысы –
«Лә иләһи илләл-лаһ!»
Җиде тәмуг йозагы
«Лә иләһи илләл-лаһ!»

«Лә иләһи илләл-лаһ»ның
Карамагыл азына,
«Лә иләһи илләл-лаһ» –
Мәңге бетмәс хәзинә.

«Лә иләһи илләл-лаһ!»

7. 16а битнең яртысыннан тагын да яңа әсәр башлана:

«Бисмиллаһир-рахманир-рахим!»

Ходаның рәхмәте берлән
Була җомга-гает көннәр,
Гафил булмыйк, ир-мөэминнәр,
Барыбыз бер туганбызлар.

Ике мөэмин килеп бергә,
Күрешсәләр чын күңел берлән,
Түгелер гөнаһасы аның,
Гөнаһасы калмас бер дә.

Ике мөэмин күрешкәндә
Салават әйтеп күрешсә,
Ходаем насыйп итәр
Аларга мәңгелек җәннәт...

8. 17а–20б биткәчә буш битләр кидә.

9. 20б биттә һәм 21а битләрдә 1900 елдан 1995 елгача хайван ел календаре бирелгән. Тычкан, Сыер, Юлбарыс, Куян, Ялу, Елан, Ат, Куй, Маймыл, Тавык, Эт, Дуңгыз еллары. Алар һәммәсе дә татар хайван ел календаренә карыйлар, исемнәре белән монгол һәм кытай, японнарныкыннан аерылып торалар. Хәер, охшашлары да бар.

10. Хайван ел календаре астында мондый язу бар: «Бу язуларны истәлек өчен язамын, караган саен искә алырсыз мин Миңгәрәйне, Булатов Гомәр мулла Шакир угылы. Моны язганда 83 яшемдә идем, гафу итәсез, әзрәк бозылган урыннары булды».

11. 21б–22б битләрдә язмалар юк.

12. 23а биттә «Ай исемнәре» (мөселман ай исемнәре барысы да) китерелә.

13. Алга таба яртылаш кисеп алынган буш битләр китә.

14. Халык сөйләгән риваятьләргә күрә, элгәрге чорларда авылларының җирле бер артист әфәндесе, халык өчен дип, бу шигырьләрне яттан укып тамаша ясарга маһир булган. Шигъри юлларга авыл агайларының исемнәрен дә кушып-кушып җибәрә икән, шуның белән игътибарны җәлеп иткән, имеш. Аны хәтта

Дантеның «Илаһи комедия»сенә тиң торырлык әсәр итеп телгә алып сөйләделәр.

15. Тупланманы Шакир улы Гомәр мулланың улы Миңгәрәй Булатов төзегән. Әсәрләрнең авторы ачыкланмады. 83 яшендә үзе иҗат итүе бераз шик уята. Әсәрләр электән халык арасында сөйләнеп йөртелгән булса кирәк.

№ 27

1. Кулъязма китап, башы-ахыры һәм тышлыгы юк.

2. Сәхифәләр 10,2×15,7 см зурлыкта.

3. XIX гасырның беренче яртысында Россиядә эшләнгән калын сары кәгазьгә язылган.

4. Беренче битенең яртысы юк. Коръән сүрәләре язылган.

5. 8а биттән кызыл кара белән гарәпчә язуда «Мөнәҗәт» килә.

6. 9а биттә кызыл кара белән язуда «Риваять кылдылар» дип башланып, Җәгъфәр Садыйкка нисбәтле вакытның кайсы сәгате изге булуы хакында ырым язылган, мәсәлән: «Шимбә көн әүвәл сәгать яхшыдур» һ.б. Шулай итеп, көннәрнең хасиятләре сөйләнелә.

7. Алга таба «Фасыл дәр япани дөши» («Төшләрне ачыклау бүлеге») дип аталган төшләрне юрау хакында хәбәрләр килә.

8. Алга таба, шул ук биттә Мөхәммәд пәйгамбәр турында «Хикәят» килә.

9. 12б биттә «Бишвакыт намаз» һәм догалар урнаштырылган.

10. 19б биттә авыруларга догалар бирелә. Тел тотлыкканда укыла торган дога белән башлана. Төрле бөти текстлары бирелә.

11. 23а биттән хәдисләр китә.

12. Җыентык 32б бит белән тәмамлана.

13. Тупланманың төзүче-авторы ачыкланмады.

№ 28

1. Кесә дәфтәре. Тышлыгы катыргы кәгазьдән. Эчке ягына латин хәрефләре белән «Садыйков Хәбир» дип язылган. Дәфтәрне туплаучы булуы ихтимал. Башлангыч өлеше коелган. Җыентыкның сәхифәләре номерланган. Сакланган өлеше 28 нче номерлы бит белән башлана.

2. Сәхифәләр 10,3×15,7 см зурлыкта. Буйлы һәм шакмаклы дәфтәр битләреннән төзелгән. Язмалары гарәп графикасында.

3. 1а биттән догалар, Коръән аятьләре һәм аларга тәрҗемәләр урнаштырылган.

4. 17а биттә – «Әсхабе-кәхаф» хикәяте.

5. 17б биттә «Вәлиуллаһ хикәяте» күчерелгән.

6. 19а биттән «Рисаләи-нурнамә» («Нур китабы» риваләсе) урташтырылган.

7. 31а биттә «Догалыклар» башлана.

8. 38б биттә «Хәдис-шәрифә» килә.

9. 44а биттә мөселманча тору-яшәү хакында мөнәҗәт урнаштырылган һәм аның бер өлеше бирелгән.

10. Аның артыннан ук Г. Тукайның «Шүрәле»се күчерелгән.

11. 48а биттә – «Бер солдатка» шигыре.

12. 50а биттә – «Бер мескенгә» шигыре,

13. 50б биттән «Мәүлед бәйрәме» шигыре урнаштырылган.

14. 52а биттә «Җәннәт исемнәре» исемлеге бирелгән.

15. 53а биттән 57б биткәчә «Мөнәҗәт. Сугыш» әсәре килә:

Германиянең межасы
Никтер ерак тоелды,
Межадин барып кергәч,
Башдин уе коелды.

Межадин без барып кергәч,
Германияләр качалар,
Безнең урыс солдатлары
Артдин утны сачалар...

16. 58а биттә иман китерү мәсьәләләре белән бәйле мәкалә урнаштырылган.

17. 69б биттә – Миладиның 569 елында Мөхәммәд пәйгамбәрнең тууы хакында мәкалә.

18. 73а һәм 73б битләрдә ятимлек хакында мөнәҗәт кисәге бар. Дәфтәр шуның белән тәмамлана.

19. Бу дәфтәр эчендә берничә язулы кәгазь бар аларның беренчесе 1 а биттә «Үлем хакында бәет» дип атала. Анда 2б биттә 1966 ел дип куелган язу бар. Бу язма 4 сәхифәдән тора.

20. Дәфтәр эчендә шулай ук «Сагынычлы хат» дип башлап язылган 1а һәм 1б битләрдән гыйбарәт хат тексты бар.

21. Шулай ук дәфтәр эчендәге аерым сәхифәдә, 1а биттә җәннәткә кертелүчеләр хакында мөнәҗәт бар. Аның бер бите буш.

22. Тупланманы әзерләүче, язылган елы ачыкланмады. XX гасыр урталары җыентыгы дия алабыз.

ТУРМАЙ АВЫЛЫНДА ТАБЫЛГАН КУЛЪЯЗМАЛАР

№ 29

1. Кулъязма китап. Гарәп телендә. Суфичылык китапларыннан берсе. Шома Урта Азиядә эшләнгән шома кәгазьдә (Кукан-Коканд кәгазе). XIX гасыр ахыры – XX йөз башына карый, 1а һәм 8б битләрдә өч мөһер бар. Анда «Мөхәммәд-Шакир ибне Хафизи, 1307» дип язылган. Беренчесе зәңгәр кара белән салынган мөһер, икенчесе кара төстә, шул ук мөһер, өченчесе зәңгәрсу төстә, шул ук мөһер, әмма начар сугылган.

2. Сәхифәләр 13,5×20,0 см зурлыкта.

3. «Китабүн-галә һадиел аййам вә әййәдил мәсьәләтил хәнифийәти би сөннәти икълам» язмасы белән башланып китә. Ул рамкага алынган.

4. Әсәр ахырында каллиграф-хаттатның кул билгесе бар.

5. 9б–11б битләрдә каллиграфик язулы гарәпчә дога бирелгән, кара кара белән язылган.

6. 11б биттә «Фи рабигиль-әһвәл 1362, Габделкадир Тәүфикъ Әш-Шәлби» дигән язу бар, аннары мөһере кара кара белән сугылган. Анда «Габделкадир Тәүфикыш-Шәлби» дип язылган.

7. 12а–15б битләрдә, өске яктан тегелгән, кәгазьләре башка төрле, юка, Мөхәммәд Әмин ибне Сәет-Әхмәт ибне Сәет Ризван тарафыннан язылган «Хикмәтүл-голамәи-әгълам» («Бөек галимнәрнең хикмәтләре») мәкаләсе килә.

8. Бу мәкалә ахырында зәңгәр кара белән язылган язмада китапның Мөхәммәд Әмин ибне Гарифныкы булуы белдерелә, «1332, 22 җәмәдиүл-сани» датасы бирелә. Матур каллиграфик язулы.

9. 16 а биттән матур каллиграфик язулы дога килә, зәңгәр кара белән эшләнелгән. Бу өлеш ташбасма ысул белән басылган, Хива басмасы булырга кирәк.

10. 17 биттә түбәндәге өстәмә язуы бар. Анда «Шәйхелислам ибне Габделкадир әл-Уфави» дип язылган. Язуда хөтбә икәнлеге аңлашыла. Совет чорына каравы да ихтимал. Хөтбә 16б биттән башланып китә, 20 б бит белән тәмамлана, ахыры юк.

11. Кулъязма Турмай авылында Сәмәрханов Сөббухта саклан-ган. Ул аны Институт «Мирасханә»сенә тапшырды.

№ 30

1. Сызыклы дәфтәр битләренә хәер сорашуга каршы нәсыйхәт итеп язылган, татар телендә, гарәп графикасында 1а–2б бит-ләрдән гыйбарәт мәкалә.

2. Сәхифәләр 16,5×20,5 см зурлыкта. Мәктәп укучысы дәф-тәре битләренә гарәп графикасында язылган.

3. Сәмәрханов Сөббухта сакланган.

№ 31

1. Тышлыгы, башламы юк. Кулъязма китап. XIX гасырга ка-рый. Татар телендә.

2. 1а–34б битләрдә җәннәт һәм тәмуг вакыйгалары белән бәйле гакыйдә килә.

3. 35а биттә «Шәйхулла Нигъмәтулла угылы 1883 елда» дигән язуы бар. Бу факт кулъязманы туплаучының шушы кеше булуын фаразларга мөмкинлек бирә.

4. Алга таба «Илаһи бәет» бирелә, тезмәдә.

5. 36а биттән татарча нәсыйхәт башлана, чәчмә белән язылган.

6. Кулъязма 56б бит белән тәмамлана.

7. Сәхифәләр 10,5×16,5 см зурлыкта.

№ 32

1. Татарча, «Мәүлед китабы» күчермәсе.

2. Башы-ахыры юк. 1а–2б битләрдә.

3. XX йөз башы кулъязмасы, кара кара белән, матур язулы эшләнгән.

4. Сәхифәләр 10,5×17,5 см зурлыкта.

5. Күчерүчесе ачыкланмады.

№ 33

1. XX йөз башы кулъязмасы, шәехләр исеменә атап дога уку тексты.

2. Кара кара белән язылган, татарча.

3. Сәхифәләр 10,5×17,5 см зурлыкта.

№ 34

1. XX йөз башы кулъязма тупланмасы. Әүвәлге сәхифәләре Идрисовларның Казан һәм Уфадагы Сәүдә йортлары тарафыннан бастырып чыгарылган китап тышлыгының бер өлгесеннән гыйбарәт. Анда «Идрисов, Галиев вә ширкәтләре» дигән басма рәвештәге язу бар.

2. 1а–9б битләрдә «Мохтасар гыйльме хәл» күчермәсе.

3. Сәхифәләр 17,5×22,0 см зурлыкта.

4. Турмай-Кайраклы авылыннан Сәмәрханов Сәббахетдин Хәсән улы (1932 елгы) кулында сакланган. Төзүчесе, кемнең кулы булуы хакында хәбәр юк.

5. Тупланманы күчерүчесе ачыкланмады.

№ 35

1. Мөнәҗәтләр тупланмасы. Укучы балаларның дәфтәр битләренә зәңгәр кара белән күчереп язылган.

2. Турмай-Кайраклы авылында табылды.

3. Сәхифәләр 15,0×20,0 см зурлыкта.

4. Мөнәҗәтләрнең берсеннән өзек:

Кабер дигән ерак сәфәр –
Без дә шунда барасы,
Берәү дә түгел бит мөстәснәсе,
Аңардан читтә калырга.

Кабер дигән мәхкәм сарай,
Ишеге юк, кереп булмый,
Эчендәге әрвахларның
Хәлләрене белеп булмый.

Пәйгамбәр сүзләрен ятла,
Аның бойрыкларын сакла,
Мөселманлык рухың белән
Усал утларны түк-ташла.

Кәмимәи-касседә, әгъладә
Муафикъ әйләсен ул Хак,
Тәнем туфракта булса да,
Рухымны әйләсен ул шат.
Амин! Тәмам.

№ 36

1. Коръән чыккач укыла торган доганың кульязма күчермәсе 1а–1б битләрдә.

2. Сәхифә 15,0×22,0 см зурлыкта. Кара кара белән язылган.

№ 37

1. Хат. «56 нчы елда» дип тәмамлана. Гарәп графикасында, татар телендә. Әтисе Имаметдингә улы Мөхетдин язган.

2. Сызыклы дәфтәр битенә зәңгәр кара белән язылган.

3. Сәхифә 15,0×20,0 см зурлыкта.

4. Турмай-Кайраклы авылында саклангaн.

№ 38

1. «Шигырьләр нөсхәсе» исеме куелган дәфтәр өлеше, 2 сәхифәдән, 4 биттән гыйбарәт.

2. 2а биттә бер шигырь күчермәсе исән.

3. XX йөз урталарында төзелгән дәфтәрдән, зәңгәр кара белән сызыклы дәфтәргә язылган.

4. Сәхифәләр 16,0×20,0 см зурлыкта.

5. Төзүчесе, күчерүчесе ачыкланмады.

№ 39

1. Хөтбәләр җыентыгы, гарәп телендә. Шулай ук вәгазьләр дә тупланган.

2. Кара кара белән язылган, 10 сәхифәдән гыйбарәт.

3. XX йөз башына карый.

4. 1б–2а битләрдә – «Хөтбә гайдел-рамазан» («Рамазан гаете хөтбәсе) тексты.

5. 2б биттә – «Хөтбә сани» (Икенче хөтбә) тексты.

6. 3а–7б битләрдә – «Вәгазь гайдел-рамазан» («Рамазан бәйрәме вәгазе») тексты.

7. 7б–8а битләрдә – «Хөтбә гайдел-корбан» («Корбан гаете хөтбәсе») тексты.

8. 8а–10б битләрдә – берничә җомга хөтбәләре текстлары.

9. Төзүче-авторы ачыкланмады.

№ 40

1. Тулы китап, башы-ахыры, тышлыгы бар. Күн тышлы.

2. Турмай авылы музеенда сакланган, Институт Мирасханәсенә акт белән тапшырыла. Акт кәгазе дә бар.

3. Бу – «Гыйльме-фараиз» («Фарызлар хакында белем») китабы, гарәп телендә.

4. Сәхифәләр 16,0×26,5 см зурлыкта.

5. Тексты кара кара белән матур итеп язылган. XIX гасыр кульъязмасы.

6. Кульъязма китап 4,0 см калынлыкта.

7. 1а битендә «Әнәч авылы Шыяп хәлфәнең үзе язган кульъязмасы Шәмсетдинов Бариның карт этисе» дигән язуы бар.

8. Кульъязма ахырында: «Китабун Шиһабетдин вәлид Шәмсетдин Аланчи фи карьяти Эстәрлибаш вә фи мәдрәсәи хаҗиелхәрамин ишан Мөхәммәдхарис вәлид Нигъмәтулла» дип («Мәккәгә хаҗ кылган Мөхәммәдхарис Нигъмәтулла улы мәдрәсәсеннән һәм Эстәрлебаш мәдрәсәсеннән Шиһабетдин Шәмсетдин Аланчы улы китабы», ә аннары «Әт-тәматтун тәмаман бәгуне Аллаһ мөлкел-мәнаб фи вактул-сәхәр дәгъвәтуллаһ эстәҗәбин мени йа АллаҺ, амин, бирәхмәтүкә пор рахман-иррахим», ягъни «Аллаһы Тәгаләнең мөлкәтендә, иртәнге вакытта, Аллаһның рәхмәте белән тәмам булды, шәфкать иясе Аллаһтан күп төрле рәхмәтләр белән» дип язылган.

9. Бу «Фараиз» китабы кульъязмасын Шәмсетдин Аланчы улы Шиһабетдин Стәрлебаш мәдрәсәсендә күчереп язган.

# СТӘРЛЕБАШНЫҢ ЗАТЛЫ КИТАПЛАРЫННАН – «ДӨРРЕЛ-КӘЛАМ»

*Фәрит Яхин*

Тарихи вакыйгалар тезмәсен барлаучыларга таныш хәлләрдән берсе – XVII йөзнең 62–64 елларында (1662–1664) татарларда Бәкҗан Туктамышев җитәкчелегендәге зур бер күтәрелеш булып, халык кузгалышлары Ука, Идел буйларыннан Уралга һәм Себернең Табул (Тобольски) якларыннан Ишим төбәгенәчә җәелә. Россия кул астында кала барган Татар иленең үз холкын күрсәтеп алуы була бу. 1548 елда башланып киткән Олы чума бәласеннән тәмам югалып-кырылып бетүгә йөз тоткан татар халкының кабат тернәкләнә башлап, аңына кайта баруыннан бер хәбәр итеп кабул итәбез һәм бәялибез моны. Россия хөкүмәте ягыннан воеводалар Ф.Ф. Волконский, И.М. Павлор, Д. Полуэктов, И. Блудов, В. Бланк һәм башкалар җитәкчелегендәге гаскәри көчләрнең өстен чыгуларыннан соң, Бәкҗан Туктамышев явы гаярьләренең бер өлеше Стәрлебаш якларында сыену таба. Баш күтәргән халык белән хөкүмәт санлашып эш итми мөмкин түгел икәнлеген аңлый. 1663 елның көзендә баш күтәрүчеләр ягыннан Ишмөхәммәт Дәүләтбаев Уфа воеводасы А.М. Волконский белән сөйләшүләр алып бара башлый. Бу вакытта Казан воеводасы булган Ф.Ф. Волконскийда 1662–1663 елларда тәрҗемәче буларак хезмәт иткән, аннары баш күтәрүчеләр ягына чыккан һәм яу җитәкчесе булып киткән И. Дәүләтбаев халыкның үз зар-

ларын патшага үзләре барып сөйләргә теләвен белдерә. Мәсьәлә бер ай эчендә хәл ителә. Патша Шымытым Алексей Михайлович (1629–1676, тәхеткә 1645 елда күтәрелә) бу баш күтәрүләрнең үзәге булган Нугай даругасыннан татар һәм башкорттан илчеләр белән очрашырга ризалыгын 1663 елның көзендә белдерә. Илчеләр итеп Актай Дүсмөхәммәтов һәм Динмөхәммәт Юлаев сайлана. 1664 елның башында алар Мәскәүгә килә. Татар һәм башкортларның зарлары тыңланыла һәм каршылыксыз кабул ителә. Алексей патша ахырда илчеләргә теләкләре кабул ителүне раслаган грамоталар тапшыра. Илчеләр Актай Дусмөхәммәтов һәм Динмөхәммәт Юлаев шул грамоталар белән 1664 елның февралендә кайтып җитәләр. Шул ук елның җәендә Нугай даругасы халкы белән Уфа воеводасы арасында килешү кабул ителә. Моңа кадәрле Уфа воеводасы булган А.М. Волконский вакытыннан алда мәртәбәсеннән төшерелеп, аның урынына Ф.И. Сомов воевода итеп куела. 1664 елның көзендә Казан даругасы татарлары һәм башкортлары да илчеләрен Уфа воеводасына җибәрләр. Моны шул ук Ишмөхәммәт Дәүләтбаев оештыра. Турыдан-туры аңлашулардан соң, баш күтәрүчеләрнең теләкләре исәпкә алына, каршылыклар туктатыла. Аннары да Ишмөхәммәт Дәүләтбаев бу юнәлештә эшен дәвам итә. 1665 елда Себер татарлары Табул воеводасы белән килешенү төзи. Төп мәсьәләләр җир милкенә һәм салым җыю сәясәтенә бәйле була. Халыкның теләкләре кабул ителә. Тарихта патша хөкүмәтенең өстен чыгуы буларак аңлатылган бу вакыйгалар, асылда, халыкның үз максатларына ирешүе хакында сөйлиләр. Мәскәүдә халыклар белән килешенеп яшәргә мөмкин икәнлеген төшенеп алалар. Бу зур вакыйга була. Россиядә халыклар белән аңлашып сөйләшү мөмкин икәнен патша Шымытым Алексей Михайлович үз өлгесендә күрсәтә һәм аны халыкта «Ак патша» дип атый башлыйлар. Шушы вакыттан татарда «Ак патша» төшенчәсе барлыкка килә, «Ак патша безнең хәлебезне белми, аңардан дөреслекне яшерәләр, белдертү кирәк, ул безнең яклы» дигән утопия туа. Алексей патшаның акыллы гамәле халык күңелендә хөкүмәткә карата ышанычны кире кайтара.

Барлык тырышлыклары өчен Ишмөхәммәт Дәүләтбаев тарханлык мәртәбәсен ала, 1675 елның мартында Мәскәүдә Казан даругасы татарларының һәм башкортларының Кырымга каршы яуда катнашырга ризалыгын белдереп килешүгә кул куя. Бу факт аның Россия хөкүмәте каршында Нугай даругасында татар-башкорт әмире буларак танылуын күрсәтә.

1681 елда Россиядә татарларга бәйле сәяси һәм икътисади шартлар кабат үзгәрә. Бу елда Касыйм ханлыгы тәхеттә утырган Фатыйма солтанның үлеме сәбәпле һәм башка хан күтәрелмәүгә бәйле рәвештә бетерелә. Бу ханлык Россия эчендә татарларга үз ханлыклары барлыгын күзаллаткан, билгеле.

Җитмәсә шушы 1681 елның 16 нчы маенда «Об отписке у Мурз и Татар поместий и вотчин, и о выгодах, какие принявшим Христианскую веру предоставляются» дигән исемле указ боярлар белән бергәлектә кабул ителә. Бу вакытта Россия тәхетендә патша булып 19 яшьлек Федор Өченче утыра (Федор Алексеевич Романов (1661–1682) 1676 елдан Россия патшасы). Ул тәхеткә күтәрелгән елда башланып киткән Рус–Кырым сугышы Госманлы императорлыгына каршы алып барыла, 1681 елда Россия Киевне һәм Донның сулъяк яр буйларын, ике арадагы чикне Днепр буйлап уздырып, Бакчасарай солыхы нигезендә үзенә ала, Кырым ханлыгына казна (ясак) түләү яңартыла, Запорожьега мөстәкыйльлек, Мәскәүгә бәйсезлек бирелә. Сугыш шулай тәмамлана. Федор патша Россиядә поляклар үрнәгендә яшәүне тагын көчәйтеп өлгерә, татарларны көчләп чукындыру сәясәтен киң җәелдерә. 1682 нче елда аның урынына патша булып агалы-энеле Иван Бишенче (Иоанн Алексеевич Романов (1666–1696) һәм Петр Беренче (Бөек Петр, Петр Алексеевич Романов (1672–1725) киләләр.

1681 елдагы күтәрелүдә Сәет Ягафәров, тиздән аны халык Сәет-батыр дип атап йөртә башлый, үзен хәтта хан буларак игълан итә. Күчүк Юлаев җитәкчелегендәге башкорт баш күтәрүчеләре, Россиядә мөселманнарга карата сәясәтнең үзгәртeләчәге хакында ишетеп, тиздән патша хөкүмәтенә бәйгыт бирәләр. 1682 елның июнь башында рус гаскәри көчләре, казак-

лар һәм башкортлар Сәет-батыр явы белән Ык буенда олы орышка керәләр. Көрәш аяусыз бара. Яуда Сәет Ягафәров каты яралана. Аны яугирләре тиз арада алып китәләр. Баш күтәрүчеләр җиңеләләр. Әмма халык күтәрелеше 1684 елның ахырынача диярлек дәвам итә.

Татарларның баш күтәрүләре, башкортлар белән бергә, билгеле, 1704–1711, 1735–1740, 1755–1756 елларда көчәеп-көчәеп ала. Иң куәтлесе, патша тәхетен селкетеп алганы, 1773–1775 еллардагысы, тарихларга «Пугачев явы» буларак кереп калганы була.

Халык күтәрелешләре хисләрнең кайнарлыгына турыдан-туры бәйле, алар рухи алгарышны тудыра. Ул чорда да шулай барган. Татарлар үз яуларына башкортларны да ияркәннәр һәм киресенчә дә булган. Аларның үзара килешенеп баш күтәрүләре хакында тарихи хәбәрләр шактый. Бер-берсенә ярдәмгә килергә өлгермәгән очракларда дошманнарын җиңүгә ирешү аларга авырга килгән. Башкортларның тынгысыз булулары, кызу канлы һәм үзсүзлелек кебек сыйфатлары татарларга да тәвәккәллек өстәгән. Татарларның баш күтәрүләре дини-сәяси һәм икътисади кысуларга протест буларак килеп чыккан. Аларның башында дини җитәкчеләре, имамнар торган һәм алар хәрби җитәкче ролен дә башкарган. Шунлыктан аларны «мөрит хәрәкәтләре» буларак та танырга тиешбез. Көчләп чукындыруларга каршы юнәлдерелгән абыз-агайлар (ягъни укымышлы-хафизлар) хәрәкәтләреннән аермалы буларак, мөрит баш күтәрүләре икътисади таләпләр белән дә озатыла барганнар һәм кискен сәяси юнәлеш тотканнар. Аларның татар милли-азатлык һәм татар-башкорт сугышлары икәнлеген танымый мөмкин түгел. Анық ахыры Идел-Урал-Себергә җәелгән 1773–1775 еллардагы Е. Пугачев явы буларак билгеле.

XVIII гасырда Россия хөкүмәтендә, халыкларны әхлаклы һәм тәрбияле тоту өчен, диннең роленә ышанып карау көч ала. Халыкларны христиан дини оешмалары булдыру ярдәмендә үзенә буйсындыру һәм бәйле тоту сәясәтен Византия ничек электән җәелдерсә, Госманлы императорлыгы да XV йөздә шушы юлга баса һәм мөфтиятләргә таяна башлый. 1782–1786 елларда

Россия хөкүмәте кыргыз-кайсаклар өчен мәчетләр төзетүне тизләтү турындагы фәрманнарын бер-бер артлы кабул итә. 1783 елдан Кырым ханлыгы Россия составына алына, Таврида мөселманнарының хакларын саклауны һәм яклауны патша хөкүмәте үз өстенә йөкләвен белдерә. Шул сәбәпле Кырым мөфтиятенең роле арта. 1788 елда эчке Россия мөселманнары өстеннән уңышлы идарә итү максатында, моның өчен имамнарны файдалануны, алардан ышанычлыларын һәм белемлеләрен сайлап алуны оештыру өчен, үзләренә аерым мөфтият булдыру хакында фәрман кабул ителә. 1789 елның 4 декабрендә Уфада «Собрание» җыела, мөфтият рәсми төстә эшли башлый. Беренче мөфти итеп Хөсәенов Мөхәммәтҗан Габдеррахман улы 1788 елның 22 сентябрендә үк патша хөкүмәте тарафыннан билгеләп куела. Мулла итеп казан татарлары арасыннан чыккан кешеләрне билгеләп куюга аерым игътибар юнәлтелә һәм бу хакта фәрманда махсус күрсәтелә[1].

Эчке Россия мөселманнарының мөфтияте төзелү татарларда дини-мәдәни, икътисади, хәтта олы бер сәяси (ә безнең мөфтият чынлыкта милли автономия үзәге булган, моны танырга кирәк) җиңүләреннән санала ала. Аны башкача бәяләү мөмкин дә түгел, шулай ук дини җиңүгә генә кайтарып калдыру да дөрес булмас. Россия шартларында татарларга мөфтият ачылуны аларның, Касыйм ханлыгы бетерелгәннән соң йөз ел узгач, милли сәяси хакларын торгызуда зур җиңүләреннән берсе иде.

Татар дини үзәкләренең берсе электән Стәрлебашта булган. Р. Фәхретдин монда 1719 елда Хөсәен бине Габдеррахман бине Әнәс Әл-Борындыкыйның имам һәм мөдәррис булуын яза[2]. Нисби исеменнән аңлашылганча, ул Борындык авылыннан икән. Исеме язылган таягы мәчеттә имамнар кулында XX йөз башында да кулланылган[3]. Әмма башка бер риваятькә таянып, Р. Фәхретдин

---

[1] *Ишмухаметов З.А.* Социальная роль и эволюция ислама в Татарии (Исторические очерки). Казань: Татар. кн. изд-во, 1979. С. 33.

[2] *Фәхретдин Р.* Асар. Беренче җилд. Икенче җөзьә. Оренбург: Типография Г.И.К аримова, 1901. Б. 56.

[3] Шунда ук.

аның этисе Мансур ахун бине Габдеррахман икәнлеген дә искәртә һәм шунда ук: «Һәрхәлдә Россиядә беренче мөфти улан Мөхәммәтҗанның атасыдыр»[1], дип тә белдерә. Мөфтинең бабасы Габдеррахман булганлыктан, ә Әлмәт шәһәре янындагы авылның Габдеррахман исемен йөртә башлавын да искә алсак, риваятьтәге «Мансур ахун» башка кеше булып чыга. Ә менә Габдеррахман авылының электә Борындык булуына шик калмый. Тагын да шуны төгәл ачыклап китәргә тиешбез; беренче мөфти Мөхәммәтҗанның фамилиясе берничек тә Хөсәенев түгел, бәлки Габдрахманов, ягъни бабасы Габдрахманның исеменнән ясалган булырга тиеш тә, әмма ул «Гусейнов» йөри, димәк, чыннан да фамилиясе Хөсәенев булып чыга. Боларның укымышлы нәселдән икәнлекләре дә аңлашыла.

Мөхәммәтҗан Хөсәенов (Гусейнов) – мөфтият оештыру тәкъдим-проектын эшләгән, патша хөкүмәтенә аны әзерләп тапшырган кеше дә. Бу вакытта ул гаскәри офицер хезмәтендә йөргән, казый-гаскәри буларак хәрби-каратель комиссия яуларында катнашып ышаныч яулаган, кабарды, кыргыз-кайсак өстеннән Коръән тотып әмер тоткан ахуннардан берсе икәнлеге дә патша хөкүмәтендә яхшы билгеле икән[2].

Аның этисе Хөсәен имамлык иткән заманнардан Стәрлебаш татар мәгарифе учакларыннан берсе булып күтәрелә, монда мәдрәсә тоту, шәкертләр укыту эше алга китә. Бу заманнарда мондый данлыклы имамнар ишанлык иткәннәр, үз тирәләренә мөритләрен җыйганнар. Р. Фәхретдин 1795 елда бу мәдрәсәдә Гаделшаһ бине Габдулланың хәлфәлек иткәнлеген дә искә ала[3]. Мөхәммәтҗан мөфтинең үзе хакындагы мәкаләсендә дә ул аның этисе Хөсәен булуын, бабасының Габдеррахман икәнен

[1] *Фәхретдин Р.* Асар. Беренче җилд. Икенче җөзьә. Б. 57.

[2] *Ишмухаметов З.А.* Социальная роль и эволюция ислама в Татарии (Исторические очерки). С. 32.

[3] *Фәхретдин Р.* Асар. Беренче җилд. Икенче җөзьә. Б. 56.

яза[1]. Шушы ук мәкаләсендә аның 1758 елда туууын ачыклый[2], мөфти хезмәтен 1789 елның 22 сентябреннән башлавын яза[3]. Аны ул 34 ел дәвамында башкарып килә. Аның чорында Гаделшаһ бине Габдулла, халыкта «Гаделша ишан» буларак дан тоткан имам-хатыйп, Стәрлебашта мәдрәсә тота һәм мөфтинең этисе Хөсәен бине Габдеррахманның эшен дәвам итә.

Гаделша ишан тумышы белән Богдан авылыннан була. Р.Фәхретдин бу авылны Бөре ягыннан дип күрсәтә[4]. «Сиксән яшенә ирешеп, 1227 тарихында[5] вафат улды. Кабере мәгълүмдер»[6], ди. Балыклы Күл авылыннан данлыклы ахун Хәсәнетдин бине Шәмсетдин, Минзәлә ягындагы Дөреш-Мөслим авылыннан Шәмгун мулла аңардан белем алганнарын, Гаделша ишанның гыйлем иясе, оста мөгаллимнәрдән булуын язып, күчерелгән китаплары, аларны улларына һәм белемле кешеләргә васыять итүенә туктала, аларны таратмаска, бергә тотарга кушуын искәртә[7]. Аның улы Дәүләтшаһ була. «Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ, «Дәүләтшаһ ишан» димәклә мәгъруф вә мәшһүр кемсә уладыр»[8], дип белдерә Р. Фәхретдин. Ә бу Дәүләтшаһ ишан исә татарның данлыклы шагыйре Һибәтулла Салиховның хәлфәсе инде.

Дәүләтшаһ башта Кышкар мәдрәсәсендә, аннары унтугыз ел Курсада имам булып тора, мәдрәсәдә укыта. «Бу Казан йортында байларның зәкәтләрене күп ашадым, имде үзем зирагать[9] итеп, кул кәсебем илә мәгыйшәт кылсам[10] иде», дия, Оренбург

---

[1] *Фәхретдин Р.* Асар. Беренче җилд. Дүртенче җөзьә. Оренбург: Типография М.-Ф.Г. Каримова, 1903. Б. 181.

[2] Шунда ук. Б. 182.

[3] Шунда ук. Б. 183.

[4] *Фәхретдин Р.* Асар. Беренче җилд. Алтынчы җөзьә. Оренбург: Типография М.-Ф.Г. Каримова, 1904. Б.280.

[5] Хәзерге ел исәп буенча: 1811 елда.

[6] Шунда ук.

[7] Шунда ук. Б. 281.

[8] Шунда ук. Б. 283–284.

[9] *Зирагать* – иген үстереп.

[10] *Мәгыйшәт кылсам* – тормыш итсәм.

төбәгендә улан Чебенле карьясына һиҗрәт итмеш[1]»[2]. Монда яшәп, мөритләр тәрбияләп, шәкертләр укытып, игенчелек белән шөгыльләнеп, 1832 елның 3 декабрендә 75 яшендә вафат була[3]. Улы Габдулла дәүләт хезмәтендә 25 ел кантон булып эшли, ә улы Габделгалләм Илек шәһәрендә имамлык итә.

Дәүләтшаһ ишан Бохарада да белем ала. Ниязколый Төрекмәнинең укучысы була. Аның белән күрешергә өч тапкыр соңыннан да барып кайта. Һибәтулла Салихов «Мәҗмәгыл-әдәп» китабында бер касыйдәсен аңа багышлаган, «Кәлам фәне»нә Дәүләтшаһның игътибары зур булган[4]. «Дин юлында хак сүзне сөйләүче улып, Аллаһы Тәгалә юлында һичкемең шелтәсеннән курыкмаз иде»[5], ди Р. Фәхретдин, аны бәяләп, явыз кешеләрнең усаллыгыана да илтифат итмәгән ул[6]. Һибәтулла Салихов белән Нигъмәтулла бине Габдеррәхим аның хәлифәләре булганнар[7]. Дәүләтшаһ ишанның әтисе Гаделшаһ бине Габдулла бине Богдан Стәрлебашта яшәгән һәм мөфти Мөхәммәтҗанның әтисе Хөсәен бине Габдрахман урынына имам-мөдәррис эшләрен дәвам иткән. Олы ишаннарның берсе буларак танылып, мөритләр тәрбияләгән. Ә улы Дәүләтшаһ исә Ниязколый Төрекмәнинең хәлифәсе булып, Кышкардан Курсага имам-мөдәррис итеп күчерелгән, бу вакыйгаларда мөфти белән Оры авылы имамы Фәтхулла ишан арасындагы каршылыкның да роле аз булмаган. Ахырда Дәүләтшаһ Курсадан Чебенлегә игенче буларак яшәргә теләвен сәбәп итеп күченеп киткән һәм әтисе кебек үк ишан буларак танылган, Стәрлебашка имам-мөдәррис буларак әтисе урынына килергә теләк белдермәгән. Монда аның заманында Нигъмәтулла ахун дан тоткан. Ул да, Дәүләтшаһ ишан кебек, Ниязколый Төрекмәнинең хәлифәләреннән икән, аның хезмәтендә торган, бай сәүдәгәр

---

[1] *Карьясына һиҗрәт итмеш* – авылына күченеп китә.

[2] *Фәхретдин Р.* Асар. Беренче җилд. Алтынчы җөзьә. Б. 284.

[3] Шунда ук.

[4] Шунда ук. Б. 290.

[5] Шунда ук. Б. 290–291.

[6] Шунда ук. Б. 291.

[7] Шунда ук. Б. 284.

балаларыннан берсе[1]. Аның Габдулла, Гыйсмәтулла, Сираҗетдин, Сәгъдетдин, Хәмидә исемле туганнары булган, балалары Мөхәммәтхарис, Мөхәммәтхаррас, Мәрзыя булган. «Бунларың балалары вә нәселләре күп вә төрле йирләрдә мөнтәшир[2] һәм «Тукай» фамилиясе илә мәгъруф[3] улмакдалардыр»[4], дип Р.Фәхретдин, бай яшәвен, шәкертләре күп, дуслары ишле икәнне белдерә, диндар һәм тәкъва кеше булуын яза, «буның заманында Эстәрлебаш карьясе хакыйкать бер дәрел-гыйлем улмышдыр[5]», ди[6]. Тәфсир, хәдис, әхлак гыйлемнәрен укытуга зур игътибар биреп, Әбүннасыйр Габденнасыйр Курсавиның «Шәрхе-Гакаид» китабыннан Аллаһны тану-иман шартларын укыткан. Шиһабетдин Мәрҗанинең Нигъмәтулла ишанны бик югары бәяләве хакында да Р. Фәхретдин искәртә, аның сүзләрен дәлилгә китерә[7]. Балалары да үзләрен тәрбияле һәм игелекле кешеләр буларак күрсәткәннәр.

Нигъмәтулланың әтисе – Биктимер, аның әтисе – Тукай, аның әтисе Үткән исемле икәннәр[8]. Патша Россиясендә ясаклы крестьяннар (ә татарлар һәммәсе дә диярлек ясаклы, билгеле), алпавытка беркетелгән крестьяннардан аермалы хәлдә, нәселләре чыккан авылга нисбәтле теркәлергә мәҗбүр булганнар, солдатка каралганда үз авылларына кайтып, шуннан алынырга тиеш саналганнар. «Асыллары Малмыж мөзафәтендә[9] Салавыч карьясеннән улып,– дип яза Р. Фәхретдин, Нигъматулла ишанның нәселен

---

[1] *Фәхретдин Р.* Асар. Икенче җилд.– Тугызынчы җөзьә.– Оренбург: Мөхәммәтфатих бине Гыйльман Кәримов матбагасы, 1904. Б. 77–78.

[2] *Мөнтәшир* – таралып.

[3] *Мәгъруф* – билгеле.

[4] Шунда ук. Б. 78.

[5] *Эстәрлебаш карьясе хакыйкать бер дәрел-гыйлем улмышдыр* – Стәрлебаш авылы чыннан да бер гыйлем йорты булган.

[6] Шунда ук.

[7] Шунда ук. Б. 79.

[8] Шунда ук. Б. 77.

[9] *Мөзафәтендә* – төбәгендә, ягында.

барлап. – Җәдде улан[1] Тукай бу тарафа һиҗрәт әйләмеш[2] иде»[3]. Моннан Тукай бабаларының дөрес исеме Туктамыш булганлыгы аңлашыла. Чөнки «Тукай» үзе «Туктамыш» исеменнән («Мөхәммәт»тән «Мамай» ясалган кебек) кыскартылып, тел җаена китереп ясалган. Шунысы кызыклы, 1662–1664 елгы баш күтәрүләрдә җитәкчеләрнең берсе Бәкҗан Туктамышев булган. Тукайның атасы менә шул Бәкҗан булырга да мөмкин. Әмма бу фаразыбызны расларлык фактлар юк. Шунлыктан аңа нигезләнергә ярамый. «Вәлиде[4] Биктимер әһле-кәсеп[5] вә мәгъруф таҗҗарлардан[6] улмыш, имеш»[7], – дип яза Р. Фәхретдин. Нигъмәтулла Тукаев ишан 1843 елда 72 яшендә вафат була[8]. Димәк, ул 1771 елда туган булып чыга. Тарихта 1777 елдан эзе югалган Туктамыш Ижбулатов дигән шәхес бар. Ул 1730 елда Пермь ягында Барда авылында туган санала, 1755–1756 еллардагы баш күтәрүләргә каршы чыга. Ул үзе бай руда шахталары хуҗасы булган. Гаскәр булдырып, баш күтәрүчеләрне шулар ярдәмендә бастырып та йөргән. Шулай старшина дәрәҗәсенә ирешкән һәм патша түрәсенә әверелгән. Алга таба дәүләт комиссияләрендә эшләгән. Үзен белемле һәм грамоталы кеше буларак күрсәткән, җирле халык мәнфәгатьләрен яклаучы буларак дан алган, 47 сәхифәле 35 пункттан торган наказ-күрсәтмә текстын да ул төзегән. 1771–1773 елларда Польша өстенә яуда катнашкан. 1774 елда Пугачев явын бастыруы өчен җибәрелгән. Июнь аенда мулла Һадигут Тимясев (Һадиутдин Тимашев) белән берлектә Е. Пугачевка хат язган, аны патша Петр Өченче буларак тануын белдереп, бәйгыт биргән һәм полковник дәрәҗәсенә лаеклы

[1] *Җәдде улан* – бабасы булган.

[2] *Һиҗрәт әйләмеш* – күченеп килә.

[3] *Фәхретдин Р.* Асар. Икенче җилд.– Тугызынчы җөзьә.– Оренбург: Мөхәммәтфатих бине Гыйльман Кәримов матбагасы, 1904. Б. 77.

[4] *Вәлиде* – атасы.

[5] *Әһле-кәсеп* – кәсеп иясе, эш кешесе.

[6] *Мәгъруф таҗҗарлардан* – танылган, данлыклы сәүдәгәрләрдән.

[7] Шунда ук. Б. 77.

[8] Шунда ук.

дип табылган[1]. Аның 1777 елдан эзен җуюы шушы вакыйгаларда катнашуыннан икәнлеге аңлашылып тора.

Язучы Зәки Зәйнуллинның «Тукаевлар»[2] дип аталган китабы бар. Ул «Фәнни роман» жанрында язылган. Шуның «Нигъмәтулла бине Биктимер Тукаев» бүлегендә, автор үзе белдергәнчә, Мөхәммәтшакир Тукаевның «Тарихы-Эстәрлебаш»[3] китабына нигезләнеп, кызыклы хәбәрләр бирелә. Анда Нигъмәтулла ишанның Габдулла Тукай нәселеннән икәнлеге сөйләнелә, 1772 елда туганлыгы языла[4]. «Тарихы-Эстәрлебаш»ка мөрәҗәгать итеп, анда Нигъмәтулла хәзрәтнең 1773 елда туганлыгы күрсәтелә[5]. Р. Фәхретдин аның кабер ташы күчермәсен «Асар»да бирә, анда вафаты 1260 икәнлеге сүз белән, тезмәдә болай дип язылган: «Тәүфа улды[6] ул мәрхүм, ки йитмеш ике сал үзрә[7], биң[8] ике йөз дә алтмышта вә ли Һиҗрәттән, и фахыр»[9]. Бу һиҗри ел исәптәге 1260 ел 1843 елның башларына туры килә. Ул гына да түгел, вакыйга мөхәррәм аенда булган, көне күрсәтелмәгән[10]. Ә һиҗри ел исәбендә ел мөхәррәм аеннан башлана. Димәк, үлем вакыйгасы 1843 елның башына, гыйнвар аена туры килә. Бу вакытта аңа 72 яшь икәнлеге дә кабер ташында ачык белдерелгән. Шулай итеп, Нигъмәтулла ишан 1771 елның башында (һәрхәлдә беренче яртысында) туган. «Тарихы-Эстәрлебаш»та язылганча, 1812 елда, Гаделшаһ ишанның вафатыннан соң, Стәрлебаш мәдрәсәсендә укыта башлаган, 1913 елда имам-мөдәрис булырга мөфтияттән указ алган[11]. Аның заманында казакъ ханнарының балалары аның

---

[1] https://ru.wikipedia.org/wiki/Туктамыш_Ижбулатов (мөрәҗәгать итү датасы: 01.10.2020)

[2] *Зәйнуллин З.* Тукаевлар. Эстәрлетамак, 2017. 287 б.

[3] *Тукаев М.* Тарихы-Эстәрлебаш. Казан: Кәримия, 1899.

[4] *Зәйнуллина З.* Тукаевлар. Б. 147.

[5] Шунда ук.

[6] *Тәүфа* – вафат.

[7] *Сал үзрә* – яшендә.

[8] *Биң* – мең.

[9] *Фәхретдин Р.* Асар. Икенче җилд.– Тугызынчы җөзьә. Б. 84.

[10] Шунда ук.

[11] *Зәйнуллин З.* Тукаевлар. Б. 147.

мәдрәсәсендә белем ала. 1814 елда агач утыртуны гадәткә кертә, 1836 елда Стәрлебашта фонтан эшләтә[1]. Ул эшләткән чишмә һәм фонтанны 1955 елда гына сүткәннәр[2]. Нигъмәтулла ишан заманына күрә бик зур галим һәм шагыйрь булып, даны еракларга тарала, аның язган һәм күчергән китаплары халык арасында кулдан-кулга күчеп йөргән[3]. Әмма әсәрләренең әдәбият тарихыбызда әлегә игътибарга алынганнары юк. Аларны өйрәнү эше дә көн тәртибенә куелмады. Нигъмәтулла ишан Стәрлебашта Гаделшаһ ишанның эшен дәвам итә, бу яклар гыйлем төбәгенә әверелә. Андый үзәкләргә галимнәр һәм әдипләр җыелмыйча калмый. Алар бар җирдә китаплар да языла. Менә шуларның берсе – «Дөррел-Кәлам» китабы. Стәрлебаш төбәгендә язылган китаплардан фәндә игътибар ителгән хезмәтләрнең дә тәүгесе санала ал ул.

**«Дөррел-Кәлам» китабына кертелгән әсәрләр һәм аларның авторлыгы мәсьәләсе.** Татар әдәбияты тарихы фәнендә «Дөррел-Кәлам» китабының авторы буларак шагыйрь Һибәтулла Салиховны (1794–1867) күрсәтү гадәткә кергән. «Татар әдәбияты тарихы» томнарында аның бары тик бер генә авторныкы икәнлеге, беренче тапкыр Һ. Салихов үзе исән вакытта ук (1856 елда) дөнья күргәнлеге ачык белдерелә[4]. 2015 елда басылып чыккан «Татар әдәбияты тарихы» китабында[5] филология фәннәре докторы М. Гайнетдиновның «Һибәтулла Салихов» мәкаләсе[6] урнаштырылган, анда «Дөррел-Кәлам» хакында болай язылган: «Мәрсияләренең берсен[7] «Мәҗмәгъ әл-әдәб» дигән

---

[1] *Зәйнуллин З.* Тукаевлар. Б. 148.

[2] Шунда ук. Б. 150.

[3] Шунда ук.

[4] Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. 2 т. XIX йөз татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. Б. 150.

[5] Татар әдәбияты тарихы: 8 томда / [төз. Р.Ф. Рахмани]. 3 т.: XIX йөз / [фәнни мөх. Ф.Г. Галиуллин]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 551 б.

[6] Шунда ук. Б. 110–120.

[7] Сүз, галим аңлатуынча, 1832 елның 3 декабрендә (М. Гайнетдинов белдергән дата) вафат булган Дәүләтшаһ ишан хакында бара. Һ. Салихов үзенең шушы мөгаллименә һәм шәехенә вафаты белән бәйле мәрсияләр язган, димәк.

күләмле китабына кертә («Әя дуслар, килең, гыйбрәт алың бу фани гаддардан» бүлеге). Икенчесе «Дөрр әл-кәлая» китабында кушымта рәвешендә басыла»[1]. Мәкаләдән күренгәчә, «Дөррел-Кәлам» китабына бәя дә бирелми, аның нәрсә ни-нәрсә икәнлеге дә аңлатылмый, шагыйрьнең әсәре дә анализланмый.

«Дөррел-Кәлам» аннан соң да, 1917 елгы революциягә кадәр берничә тапкыр басылып чыккан китапларның берсе булып тора. Мәсәлән, 1901, 1912 елгы Казан басмалары да бар. Түбән Курса авылыннан хаҗи Шәмсетдин бине Хөсәен варислары һәм ширкәте нәшер итә, сабын заводлары хуҗалары Мусиннар хиражаты (спонсорлыгы) белән бастырып чыгара.

«Дөррел-Кәлам» китабы 1856 елда басылып чыгуга галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Андагы әсәрләрнең авторлары, яки авторы хакында да сүзләр кузгалмый калмаган, билгеле. Шушы уңайдан, мәсәлән, XX гасыр башы әдипләребездән Ф. Әмирхановның бабасы Хөсәен Әмирхановның 1883 елда Казанда дөнья күргән «Тәварихы-Болгария» хезмәтендә бу китапның авторы итеп Уфа губернасы Әхмәт авылы (хәзер Татарстанның Сарман районында) мулласы Һибәтулланы атый, аның Нигъмәтулла мулланың улы икәнлеген белдереп, тагын да болай дип яза: «Уфа өязендә Әхмәт авылында галиме фазылу мөршиде камил[2] Дәүләтшаһ ишан хәзрәтләренең хәлифәседән[3] Һибәтулла бине Нигъмәтулла күп еллар гыйльме-заһир вә гыйльме-батыйннан тәгълим биреп[4], күп адәмнәр кәмалаткә йиткәннәр[5]. «Дөррел-Кәлам» исемендә вә һәм хуп мөнәҗәте[6] бар»[7].

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 3 т. Б. 111.

[2] *Галиме-фазылу мөршиде-камил* – олы дин галиме һәм камиллеккә ирешкән мөритләрдән.

[3] *Хәлифәседән* – олырак ишанга буйсынып, үзе дә мөритләр туплап ишан булган, шәкертләрен булдырган суфилардан.

[4] *Гыйльме-заһир вә гыйльме-батыйннан тәгълим биреп* – бу дөнья һәм Ахирәт көненә бәйле гыйлемнәрне өйрәтеп.

[5] *Кәмаләткә йиткәннәр* – камиллеккә ирешкәннәр.

[6] *Вә һәм хуп мөнәҗәте* – шулай ук яхшы һәм күркәм шигъри догасы.

[7] *Әмирханов Х.* Тәварихы-Болгария.– Казан: Университет табигъханәсе, 1883. Б. 45.

Х. Әмирхановның бу сүзләрен инкяр итү урынсыз сыман, чөнки шул заманнарда яшәгән зур галимнәребезнең берсе санала ул. Әмма биредә Һибәтулла Салиховны Һибәтулла Нигъмәтуллин белән бутаулары ачык аңлашыла. Бәлки, Х. Әмирхановның хаталануыннан чыгып, Һ. Салихов һәм Нигъмәтулла ишан хакында үз заманында Казанның олы галимнәре дә хәбәрдар булмаганнар, дияргәдер?

Хикмәт анда түгел, билгеле. Әдәби әсәрләрнең авторларын ачыклау өлкәсендә эзләнүләр барган. Бу – шуның күрсәткече генә. Татарда, Шәрык әдәбиятларына хас булганча, әсәрнең авторы текст эчендә, андагы сүзләргә һәм фикерләргә ияртеп бирелгән һәм әдипләр күп очракта үзләрен уйдырма имза астында атаганнар. Хәтта электән укылып килгән әсәрләрнең авторлары һәм аларның шәхесләре хакында белешү, тормышлары белән кызыксыну XIX йөзнең соңгы чирегендә татар мохитендә дә барлыкка килә һәм үсә башлый. Авторлык һәм хронология мәсьәләләре бүгенге көндә дә текстология һәм әдәбият гыйлемнәренең актуаль өлкәсенә карыйлар.

Стәрлебаш мәдрәсәсендә төзелгән (ә бу мәсьәләдә бәхәсләшү урынсыз, чөнки анда шул вакытта Стәрлебашка бәйле шагыйрьләрнең әсәрләре генә кертелгән) бу китапка «Дөррел-Кәлам» дип исем бирелү факты да кызыклы. «Дөррел-Кәлам»не татарчага тәрҗемә итсәк, ул «Кәлам энҗесе» (дөресрәге: «Каләм энҗеләре») дигән мәгънәгә туры килә. «Кәлам» дигәндә «Гакаид гыйлеме», ягъни «Гакыйдә», «Иман шарты» күздә тотыла, «гүаһлык белән раслау», «инануны тел белән әйтеп раслау» дигән мәгънәгә ия. Димәк, «Дөррел-Кәлам» Аллаһы Тәгаләгә инану мәсьәләләрен яктыртуга багышланган әсәр булып чыга.

Китап тышлыгында, «Дөррел-Кәлам» дигән исеме күрсәтелгәннән соң, «Һәм нәзмы-сарсази ләкабиһи Фәйзел-Бари, фи мәрсиятин «Мулла Фәттахетдин әл-Болгари», хәлифәтиш-шәихит-Төрекмани әл-Бохари һәм «Мәрсия-ил-хаҗи мулла Хәсән Пашати» («Һәм Фәйзел-Бари (Аллаһның Изгесе) кушаматын йөртүченең шигъри тезмәләре, шәех әт-Төрекмәни әл-Бохариның хәлфәләреннән мөрите «Мулла Фәттахетдин әл-Болгари

мәрсиясе» һәм «Хаҗи Хәсән Пашати мәрсиясе») дип язылган, ягъни, төпләнмәгә кертелгән әсәрләрнең эчтәлекләренә бәйле исемлеге бирелгән. Димәк, әлегә шушы мәгълүматлардан чыгып аңлаганыбызча билгеләсәк тә, «Дөррел-Кәлам» тезмә әсәрдән гыйбарәт җыентык булып тора, анда өч шагыйрьнең дүрт әсәре урнаштырылган сыман күренә: 1) «Дөррел-Кәлам»; 2) «Фәйзел-Бариның шигырьләре»; 3) «Фәттахетдин Болгари мәрсиясе»; 4) «Хәсән Пашати мәрсиясе». Әмма болар белән генә чикләнергә ярамый. Җыентыкның асылына төшенер өчен, аның белән якыннан танышырга, китап тышына чыгарылган хәбәрләрне дөрес аңлау-аңламавыбызны тикшерергә һәм бәяләргә тиешбез.

Татар әдипләренең гарәпчә һәм фарсыча текстлары берникадәр үзенчәлекле булулары белән аерылыбрак торалар. Сүзләр тезмәсен төзүдә, фикерне укучыга җиткерүдә дә авторларның үз үзенчәлекләре булмый калмый. Бу – табигый күренеш. Шулай булмаса, башка төрле сораулар тудырыр иде. Шунлыктан тышлыктагы фарсыча язылган мәгълүматка кире кайту һәм аны башкача аңлату вариантларын да карау кирәк табылды. Моңа текстны ачык аңлап җитмәвебезне тоемлап калу да этәргеч бирде. Мәгълүматның нәкъ менә аңлашылып җитмәгән өлешен кабат, башкача тәрҗемә итеп тә була. «Һүммә нәзмы Сәрсази ләкабиһи»не «Һәммәсе дә имзасы «Сәрсази» шигырьләре» дип аңларга-аңлатырга мөмкин. Димәк, «назмы сарсази» тезмәсен «шигъри тезмә» дип түгел, бәлки «шагыйрь Сарсази» дип тә тәрҗемә итеп була. Тик ул вакытта шагыйрь Сарсазиның тагын да «Фәйзел-Бари» («Аллаһның Изгесе») дип искәртелүе сәер. Әллә «Фәйзел-Бари» әсәр исемеме? «Фәйзел-Бари» ләкабе алган шагыйрь кем ул, «Сарсази» кем? Бәлки бу имзаларны ул чорда иң актив иҗат иткән, үзенә төрле-төрле имзалар алырга яраткан шагыйрь Гали Чокрыйга нисбәт итәргәдер? Әллә болар, «Сарсази» да, «Фәйзел-Бари» да, икесе ике төрле кешеме? Аннары, «Дөррел-Кәлам» әсәренең авторы нигә күрсәтелмәгән?

Күренеп тора, китапның исеме генә дә шактый күп сораулар тудыра. Әгәр дә борынгы әдипләрнең кайсы кем булуын сөйләгән «тәзкирә гыйлеме», ягъни әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез тари-

хына бәйле энциклопедик характердагы борынгы китапларыбыз табылса, әллә ни кадәр мәсьәләләрне җиңел чишә алыр идек.

Бәлки «Дөррел-Кәлам»нең авторы буларак башка берәүне – Фәйзел-Бари кушаматлы шагыйрьне дә атарга тиешбездер? Тагын шунысы әһәмиятле, китапның тышлыгында башка бер автор күрсәтелгән, әмма фәндә исә аны икенче кешегә нисбәт итәләр түгелме? Димәк, бу мәсьәләне ачыклау, ахыргача хәл итү сорала.

Әгәр дә мантыйкка хилафлык итмичә фикер йөртсәк, «Фәйзел-Бари»ны «фәйзил-бариин фи-мәрсиятин» дип уку дөрес була ала, ягъни «Аллаһның изгесе мәрсиясеннән» булырга тиеш иде, дигән вариантны алга чыгарырга мөмкин. Әмма бу сүзләр алдыннан «ләкабиһи» («аның кушаматы») гыйбарәсе тормас иде. Моны буталу дип тә кабул итәргә мөмкин, ягъни шул чорга хас җөмлә төзү, хәбәрне белдерү тәртибе түгелме, дияргә кирәк. Бу рәвештәге икеләнүләрне китапның эчтәлеге юкка чыгарыр дип ышанырга кала. Шуның өчен дә аның эчтәлегенә мөрәҗәгать итү сорала.

Тупланма «Дөррел-Кәлам» дип исемләнгән поэма белән ачыла. Алдагы мәкаләбездә белдерелгәнчә, ул дүрт «баб»тан (ягъни бүлектән) гыйбарәт, һәр бүлек тагын да аерым тематик бүлекчәләргә бүленгән. Урыны-урыны белән сүз дәлиленә Коръән аятьләре мисал итеп китерелә, һәм шуларга көч бирүче шәрех буларак, авторның үз фикерләре бәян ителә. Һ. Салиховның «Мәҗмәгыл-әдәп» («Әдәп мәҗмугасы», 1839) китабы да шушы тәртиптә язылган.

«Дөррел-Кәлам» – иман шартларын бәян итеп аңлатуга корылган, ахырында шундый мәгълүматы бар: «Мин таәлифин әлгалимил-гамәл вә мөршидил-кәмил фи гасриһин мулла Һибәтулла мин хәлифәи ишан Дәүлатшаһ рәхмаһүм Аллаһү Тәгалә» («Ишан Дәүләтшаһның, аңа Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булсын, хәлифәләреннән, гамәлендә галим һәм камил суфи-мөрид заманындагы мулла Һибәтулланың язганныннан») дигән мәгълүмат бирелгән. «Дәүләтшаһ ишан» дигәнендә, игенчелек хезмәте белән көн күрү теләге белән Түбән Чебенле авылына килеп урнашкан, тарихи-легендар шәхес, Стәрлебаш мәдрәсәсендә Хөсәен мулладан соң

мөдәррислек иткән Гаделшаһ ишанның улы хакында сүз бара. Түбән Чебенледә Дәүләтшаһ ишанга авыл халкының мәдрәсә салуы да билгеле.

Шул Түбән Чебенле авылында Һ. Салихов та туа, ул вакытта аның этисе Сәетбаттал Салихов исә монда мулла булып тора. Һибәтулланы ул шушы Дәүлатшаһ ишанга укырга бирә. Аның мәдрәсәсен тәмамлагач, Һибәтулла Оренбург Каргалысында Вәлидетдин Багдадыйда укый. Аннан соң Түбән Чебенлегә мулла булып кайта.

«Дөррел-Кәлам» поэмасының авторы Дәүләтшаһ ишан мөрите Һибәтулла булуы хакындагы әлеге мәгълүмат рамка эчендә текст алдыннан куелган. Шушы сәбәп аркасында, ахрысы, галимнәр китаптагы башка әсәрләрне дә «Дөррел-Кәлам»нең состав өлеше буларак күзаллаганнар.

Шуны ассызыкларга тиешбез: «Дөррел-Кәлам»нең авторы Һ. Салихов икәнлеге бәхәскә алынырлык җирлек юк. Х. Әмирхановның аны башка кешегә нисбәт итеп, ягъни Сарман янындагы Әхмәт авылыннан ишан Нигъмәтулланың хәлифәләреннән Һибәтулла мөрите язган дигәннәре белән килешеп булмый. Хәер, аның Дәүләтшаһны Нигъмәтулла белән бутавы да ачык күренеп тора. Бу исә – Х. Әмирхановның ялгышканлыгын ачык белдерүче факт.

Тупланмада, «Дөррел-Кәлам»нән соң, икенче булып, мәрсия жанрында язылган әсәр килә. Мәрхүмне автор «исемең сәнең һәбең» (ягъни, «исемең синең бүләгең») дип белдерә. Һ. Салиховның үзе хакында да, мәсәлән, «Тәндә җаным...» шигырендә, авторлыгын күрсәткәндә, «исемем Аллаһ һибәсе» («исемем Аллаһ бүләге») дип яза. Шуны сәбәп итеп, мәрсия авторы Һ. Салихов булырга тиеш дигән фаразны уздыру урынлы. Әмма әсәр ахырындагы «...би каләмил-габдел-зәгыйфь ибне Нигъмәтулла гаффаруллаһ ләһүмма...» («Аллаһның зәгыйфь колы Нигъмәтулла улының, Аллаһ аларны гафу кылсын, каләменнән») дигән аерым хәбәрнең булуы мәсьәләгә шунда ук ачыклык кертә. Алардан мәрсиянең авторы Һ. Салихов түгел, бәлки «ибне Нигъмәтулла» («Нигъмәтулла улы») икәнлеге беленә. Бу төгәл аңлашылып тора. Димәк, мәрсия-

не әтисенә багышлап улы Нигъмәтулла язган, дип уйларга мәҗбүрбез. Аның шулай ук данлыклы шәхес, шагыйрьлеге хакында да тарихи хәбәрләр бар. Әмма бу «ибне Нигъмәтулла» дип белдерелүгә карап, мәрсиянең чыннан да ишан улыныкы булуы расланырмы? Ачыктан-ачык, атап күрсәтелгән булгач, нишләп дәлилләнмәс икән? Аннары, Харис Тукаевның шигырьләре саклану факты үзе бер зур фәнни әһәмияткә ия хәбәр түгелме?

Харис Тукаевның әтисе Нигъмәтулла ишан – инде ачыклап узган идек, Стәрлебашның мәшһүр ишаны Нигъмәтулла бине Биктимер бине Тукай бине Үткән әс-Салаучи (1844 елда вафат)[1] дигән кеше[2]. Бу кешенең ике улы булган, берсе – Харис, икенчесе – Харрас.

Нигъмәтулла ишанның җеназасында бик күп мәрсияләр укыла. Шуларның берсенең авторы улы Харис Тукаев икәнлеге «Асар»дагы тексттан да күренә. Аның шулай ук имам-мөдәррис, ишан булганлыгы, зур галим һәм шагыйрь мәртәбәләрендә танылуы да билгеле. Һ. Салиховның чордашы һәм фикердәше икәнлеге дә әсәреннән аңлашылып тора.

Харис Тукаев 1810 елда дөньяга килә[3]. 1833–1841 елларда Урта Азиягә китә. «Бохарада Гобәйдулла бине Ниязколый әт-Төркмани хозурында тәрбияләнеп», аның мөриде була[4]. Әтисе Нигъмәтулла ишанның авырып китеп чакыртуы сәбәпле, Стәрлебашка кайта, имам-мөдәррис була. Р. Фәхретдин аны Бохарадан «кайтдыгында һәм шәехлек итте» дип белдерә[5]. 1860 елда хаҗга бара. Хаҗ вакыйгаларын хатларында бәян итеп бара. Аларның берничәсе «Асар»да урын алган[6]. Шуларның дүртенчесендә ул: «Сәламәт кайтып, үз телемез илә сөйләргә

---

[1] *Фәхретдин Р.* Асар. Икенче җилд. Тугызынчы җөзьә. Б. 77–93.

[2] Акмулланың әтисе шушы Нигъмәтулла ишан Тукаевның (аны галимнәр «Биктимеров» дип тә язалар) мөриде булган.

[3] *Зәйнуллин З.* Тукаевлар. Б. 150–152.

[4] *Фәхретдин Р.* Асар. Икенче җилд. Унбишенче җөзьә. Оренбург: «Кәримов, Хөсәенов вә ширкәте» паровой матбагасы, 1908. Б. 505.

[5] Шунда ук. Б. 505.

[6] Шунда ук. Б. 507–509.

насыйп улсын»[1], – дип яза. Ул үз шәкертләренә рус телен өйрәнергә әмер итә. Аңлаганыбызча, рус теленә татарда мәхәббәт тәрбияләү эшен ул башлаган, имеш. «Халык арасында төрле хәбәрләр шаигъ улып[2], хосусан, шәһәрләрә варып киләннәр, чәйханә вә мөсафирханәләрдә ишетмеш хәбәрләре, имешдимешләре карьяләрә китереп таратдыкларында, бунының сәбәбеннән берәр төрле фетнә заһирыннан[3] куркып, газета укымак лазем игътикадына[4] кәлмеш вә шул вакытта мөгътәбәр улан «Голос» газетасына мөштәри[5] уларак, бер кемсәдән тәрҗемә иттермәк лә мәзмуненә моталлигъ[6] улыр, имеш»[7]. Хатыннарыннан беренчесе – агай-энеләреннән Биктимер улы Гобәйдулланың кызы Зәйнәп, икенчесе шулай ук агай-энеләреннән Габдулла кантонның кызы Фаизә икән[8]. Бу хатынның әтисе Габдулла кантон патша хөкүмәтенә хезмәттә олы мәртәбә иясе түрә булган, Гаделшаһ улы Дәүләтшаһның улы[9] икән. Димәк, Фаизә Түбән Чебенле ишаны Дәүләтшаһның оныгы булып чыга, ә Харис Тукаев– кияве. Балалары: Габдулла, Гобәйдулла, Хәбибулла, Шакир, Габделмәҗит, Габделкадыйр, Зөбәйдә, Зөһрә[10]. Харис ишан, ягъни Биктимер улы Нигъмәтулла ишан улы Харис Тукаев 1870 елның ноябрендә вафат була[11]. Аның урынына энесе Харрас бине Нигъмәтулла бине Биктимер имам-мөдәррис була, әмма 57 яшендә 1871 елда рамазан аенда вафат була, данлыклы балалары Ләтыйфулла һәм

---

[1] *Фәхретдин Р.* Асар. Икенче җилд. Унбишенче җөзьә. Оренбург: «Кәримов, Хөсәенов вә ширкәте» паровой матбагасы, 1908. Б. 509.

[2] *Шаигъ улып* – таралып.

[3] *Заһирыннан* – күренүеннән.

[4] *Игътикатына* – ышануына.

[5] *Мөштәри* – язылучы.

[6] *Мәзмуненә мотталигъ* – эчтәлегенә бирелгән, фикер бәяны юнәлешенә мөкибббән.

[7] Шунда ук. Б. 505–506.

[8] Шунда ук. Б. 505.

[9] Шунда ук.

[10] Шунда ук.

[11] Шунда ук.

Габдеррахман икән[1]. Мәдрәсәдә мөдәррислек эше Харис ишан улы Габдулла Тукаевка кала. Имамлык эшенә Ләтыйфулланы сайлыйлар, әмма ул 1878 елда вафат була[2]. Шуннан соң имам-мөдәррис итеп Харис ишан улы Гобәйдулла (Габидулла) сайлана, әмма ул 1883 елда хаҗ сәфәрендә Мәдинә шәһәрендә вафат була[3]. Стәрлебашта Харис ишанның дүртенче улын, Шакир (Мөхәммәт-Шакир) хәзрәтне (1867–1932), имам-мөдәррис итеп сайлыйлар[4]. Шулай итеп, Стәрлебаш даны Тукаевлар кулында кала.

Шул рәвешле, «Дөррел-Кәлам» җыентыгында басылган икенче әсәрне (аны «Нигъмәтулла ишан мәрсиясе» дип атау дөрес булыр), китапның үзендәге хәбәргә карап, Харис Тукаевныкы дия алабыз. Бу мәрсияне башкорт галимнәре Дәүләтшаһ ишанга багышланган дип баралар, эчтәлегендә надан муллаларны тәнкыйтьләү ята дип аңлаталар[5]. «Дөррел-Кәлам» поэмасыннан «Тәммә», ягъни «Тәмам булды» дип күрсәтелгән, аннары «Мин таәлифин әл-галимил-гамәлу мөршидил-кәмил фи гасриһи мулла Һибәтулла мин хәлифәи ишане Дәүләтшаһ рәхмәһүммә Аллаһү Тәгалә», ягъни «Дәүләтшаһ, аларга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте ирешсен, ишанның хәлифәләреннән гамәлле галим һәм камил мөрит Һибәтулла мулланың үз заманында язганнарыннан», дигән язуның урнаштырылуыннан килә. Шуннан соң бисмиллаһ гыйбарәсе белән мәрсия башланып китә. Бу мәрсия текстының ахырындагы «Бигуналлаһу тәгалә интиһәи илә ахриһа, бикаләмин габдез-зәгыйф ибне Нигъмәтуллаһ, Гаффаруллаһ ләһүммә, вә ли назымиһа. Амин!» (ягъни «Аллаһы Тәгаләгә һаман да (бер очтан икенче очка кадәр сыгынабыз), зәгыйфь колы каләменнән, Нигъмәтулла улына, Аллаһтан аңа ярлыкау үтенәбез, һәм аның шигыреннән. Амин!») дигән язу килә. Бу сүзләр Дәүләтшаһ

---

[1] *Фәхретдин Р.* Асар. Икенче җилд. Унбишенче җөзьә. Б. 533.

[2] *Зәйнуллин З.* Тукаевлар. Б. 152.

[3] Шунда ук.

[4] Шунда ук.

[5] https://ru.wikipedia.org/wiki/Салихов,_Хибатулла_Саитбатталович (мөрәҗәгать итү датасы: 13.10.2020)

ишанның Нигъмәтулла ишан улы булуын белдерә түгелме? Димәк, мәрсиянең Нигъмәтулла улы Дәүләтшаһка багышланганлыгында бәхәс калмаска тиеш сыман. Дөрес, андый фикергә дә килергә була. Әмма монда бер комачау килеп туа: Дәүләтшаһның атасы Гаделшаһ ишан булган – Әбу Дәүләтшаһ Гаделшаһ ибне Габдулла ибне Богдан. Димәк, Дәүләтшаһ берничек тә ибне Нигъмәтулла була алмый.

Мәрсиядә шагыйрь Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итә һәм беренче биш бәетендә үзенең чиксез сагыш-кайгыга төшүен белдерә, тәмам гаҗиз һәм бәхетсез булуын яза. Сәбәбе «җиһаннан кәчде һәб шихем» («дөньядан кичте камил шәехем») аркасында икән. Һәммә туганнары, һәммә юлдашлары кайгыга бирелгәннәр. Аларны шагыйрь изге кешеләр буларак атый. Гадәт буенча гөнаһларыннан азат итеп, һәрнәрсәдә тыелып, барысы да диндар булып җыелганнар. Алар өчен дин нуры сүнде, җиһан эче бозыклык белән тулды, бәхет дәвере үтте, ди унынчы бәетендә. Моның ахыры шайтан юлына басу белән тәмамланачагын да искәртә. Шәех өйрәткәнчә яшәргә чакырып, дөнья турында фәлсәфә итүгә күчә һәм аның әхлакый йөзен ямьсез сурәттә тасвирлый. Шәехен «заманның мөкатдәсе», әһле хассы», ягъни аксөяге буларак атый. Әмма кайбер галимнәрнең мондый сүзләргә эче пошуын яза, аларны «аю кебек ачуланалар», «сулышлары тәмам кысыла», «эчләрендәге ачу белән елан кебек йомарланалар» дип тасвирлый. «Халаикъ шулкадәр азган... күрерләр үзеңне дошман», ди 20 нче бәетендә. Аларның берләре заманаными фетнәләр чоры дип белә икән, икенчеләре дөньяны көферлек урыны буларак күзаллый, аларны тыеп торырга мөмкинлек тә юклыгын яза шагыйрь. 22 нче бәетендә үзе хакында:«Кадерсез әйләп үзем, нә чөн заигъ (зая) кылам сүзем? Йөререм бән йомып күзем, деләрсә нәйләсен инсан»,– дип белдерә, ягъни, үз-үземне нәрсәгә кадерсезләргә, сүземне әрәм итәргә, күземне йомып йөрим, кешеләр теләсә нәрсә эшләсеннәр, ди. Әмма беркөн аларны Хода орачак икән. Алар шәригатьне тотмаганнар. Бу фетнәчеләрне 26 нчы бәетендә санап китә: «Игенчеләр гошер бирмәс, ганиләр ашка өндәмәс, фәкыйрьләр өмәгә килмәс», ди. Шуннан соң шагыйрь 27 нче

бәеттән үз шәехе Дәүләтшаһның рухи көчен сурәтләүгә күчә. Моны ул киңәш биргән төстә яза: матур холкың белән сөйләп, сүзне яхшылыкка әйтсәң, «җиһан тулы халык берлә һичбер күрмәс бере дошман», ди. Яшәешеңне, сүзеңне матур итеп, аларны эткә, карчыгага тиңләмәсәң, сүзләреңә колак салырлар, «хуш әйдең дирләр», дип яза. Шунда халык синнән вәгазеңне сорар, тота алмасак – безгә зыян, тотсак – дәүләт, диячәкләрен дә искәртә. Ишаны менә шундый кеше булганлыгын шагыйрь 34–35 нче бәетләрендә дә искәртә. Моның өчен ул халык белән утырганында хакыйкать сүзләрен китереп әйтсә дә, халыкның тыңламавын белдерә. Шуннан соң заманның бозылуына, галимнәрнең наданлыгына хәйран итә, алга таба үзеннән дә зарланып ала: аның кешелекле назлысы юк, динле кешесе юк, арка куяр яраны юк, серләремне яшерергә генә кала, ди. Аны эзләп дәшә. Әмма табалмаудан күңеле хәйранга калган. Менә шунда шагыйрьнең лирик герое Аллаһка сыенырга мәҗбүр икәнлеген белдерә, аның юлдаш, яр булуын үтенә. «Ирер исмем «Сәнең Һәбең», дәхи касме муаһибең, Кылың җисмем мәзаһийнең тарикында идә сәйра», ягъни «Исемем була «Синең Бүлгең», тагын да өлешем – вәгъдә иткән бүләкләрең, Җисемене дине юлында гизүче итсәң иде», ди. Монда «Синең Бүләгең» дигәндә, шагыйрь үзен күздә тота. Бу – «Һибәтулла», ягъни «Аллаһ бүләге», символик мәгънәдә искәртү. Ул шунда ук вәгъдә ителгән бүләкләр, ягъни җәннәт рәхәтлекләре турында да искәртә. Боларга лаек булу өчен, аңа җисемен дә дин юлында йөртергә кирәк икән. Шуннан соң ул 51 нче бәетендә үзенең хаталы булуын искәртә, һәм «Бари»дан, ягъни «Ходайның Изгесе» шәехеннән ярдәмен үтенә.

Укып чыккач, шигъри яктан гаҗәеп камил дәрәҗәдә төзелгән мәрсия бу, дияргә кала. Әсәр формасы белән дә, эчтәлегендә дә камил, һәртөрле тәнкыйтьне күтәрә алырлык итеп эшләнгән. Бәхәс юк, ул Һ. Салиховныкы, шәехе-ишаны Дәүләтшаһка багышланган. Шулай итеп, әсәрнең эчтәлеге һәм андагы авторлыкка бәйле гыйбарәләр кемнең каләменнән булуын үзләре үк белдерделәр. Югыйсә, мәрсиянең алдыннан һәм артыннан куелган хәбәрләр авторлыкны хаталы нисбәтләүгә этәрә ала иделәр.

Шулай да ни өчен «Ибне Нигъмәтулла» диелгән соң, нигә Дәүләтшаһ ишан Нигъмәтулланың улы аталган?

Һәм тагын да, ни өчен «Гаффаруллаһ» диелгән? Бәлки Ибне Нигъмәтулла Гаффаруллаһтыр?

Тарихта Гаделшаһ ишанның да, Дәүләтшаһ ишанның да хатлары Р. Фәхретдин күчермәсендә сакланып калган[1]. Аларда «Гаделшаһ» исеменнән һәм «Дәүләтшаһ» дип язылганнан соң, «Гаффаруллаһ-ләһүмма» дигән сәламләү сүзләре кулланылган. Бу исә мөритләр арасында аларны шулай сәламләү тәртибе кабул ителгәнлеге хакында сөйли. Ул, димәк, «Аллаһы Тәгалә аларны ярлыкаучы» мәгънәсенә ия, һәм аларның мәртәбәләрен күрсәтә. Р. Фәхретдиннең язганынча, күчергән китабы ахырында «Гаделшаһ бине Габдулла, Гаффаруллаһ зәнүбиһа» дип үзе хакында белдергән[2].

Тик «ибне Нигъмәтулла» булуы, «ибне Гаделшаһ» дип аталмавы сәер. Гаделшаһ ишан Стәрлебашта 1811 елда 80 яшендә вафат булган[3]. Туган елы 1731 елга туры килә. Улы Дәүләтшаһ ишанга килгәндә, ул Кышкарда һәм Курса авылларында 17 ел имам булып торган. Аннары, Казан ягын калдырып, Оренбург ягындагы Түбән Чебенлегә кайткан. Монда имам Һибәтулла Салиховның этисе Сәетбаттал икән. Араларында каршылык чыкканмы-юкмы – ул кадәресе тарихка мәгълүм түгел. Әмма Сәетбаттал мулланың Дәүләтшаһ ишанга мөрит булуы, ә мәдрәсәсендә улы Һибәтулланың укуы – яхшы билгеле.

Дәүләтшаһ ишанның хатыны – Казан ягыннан Мәмеш авылы Госман бине Габдулла мулланың кызы Шәмсия, балалары: Мөхәммәтша, Мөхәммәтсадыйк, Габдулла, Гобәйдулла, Әхмәтша, Габдеррәхим, Габделгалләм, Салиха, Ләтыйфә, Газизә. Арадан Габдулла дәүләт түрәсе булып, 25 ел кантон башлыгы хезмәтендә торган. Кызы Ләтыйфә Куганакта данлыклы имам Тәмур бәк ахун ибне Вәлиданга кияүгә чыккан. Башка балалары олы имамнар һәм

---

[1] *Фәхретдин* Р. Асар. Беренче җилд. Алтынчы җөзьә. Б. 280–284.

[2] Шунда ук. Б. 280.

[3] Шунда ук.

абыстайлар икән. Әхмәтша улы Бохарада укыган чорында вафат була[1]. Болар арасында Нигъмәтулла исемле баласы юк. Димәк, Дәүләтшаһ ишан берничек дә Нигъмәтулла исемле кешенең этисе була алмый, аңа бәйле «ибне Нигъмәтулла» дип белдерү дә урынсыз. Аның хәлифләреннән берсе – Һибәтулла Салихов, икенчесе – Нигъмәтулла. Әмма бу Нигъмәтулланың этисе Габдеррәхим булуы ачык билгеле[2]. Алар Дәүләтшаһның Гаделшаһ ишан улы булганлыгын төгәл белгәннәр һәм белми мөмкин дә түгелләр. Шул сәбәпле Дәүләтшаһ ишанны «ибне Нигъмәтулла» дип белдерү редакция хатасы икән дип фараз итәргә мәҗбүрбез. Бу исә мәсьәлә чишелде дигән сүз түгел.

Мәрсиянең ахыры «Йөзем кара, үзем карый, үзең улгыл бәңа йари, Гаталар әйлә, и Бари, хаталары кылып гофран» дип тәмамлана. Дәүләтшаһ ишан 1832 елның 3 декабрендә 75 яшендә вафат була[3]. Бу факт исә Һ. Салиховның шушы мәрсиясенең датасын ачык билгеләргә ярдәм итә. «Дөррел-Кәлам» поэмасын аның 1832 елга кадәр язганлыгын белергә була. Дәүләтшаһ ишанның 1757 елда туганлыгын да искәртә алабыз.

Һ. Салиховның 1832 елның декабрендә язылган «Дәүләтшаһ ишан мәрсиясе» белән бергә «Дөррел-Кәлам» җыентыгында тагын да өч мәрсия урын алган. Эчтәлегеннән чыгып, аларның беренчесен «Мулла Фәттахетдин Болгари мәрсиясе» дип атарга кирәк, икенчесенең исеме «Фи мәрсиятин вәлидәтилҗәлләяти» («Үз әниемнең мәрсиясеннән») дип куелган, өченчесе «Мәрсиятүл-хаҗи мелла Хәсән Башати» («Мулла Хәсән Башати хаҗи мәрсиясе») дип аталган. Авторлары «Мулла Фәттахетдин Болгари мәрсиясе»нең авторы «Гали Гари вә Болгари» дип текст эчендә күрсәтелгән. Тагын да ахыргы бәетендә «яраннар сорса кем назыйм, аңа юллар башы ләзем» дип тә белдерә. Шушы күрсәтмәсе нигезендә, бәет башларындагы хәрефләрне укысак, «Мөхәммәтгали Чокрый Бәһари» дип укырбыз. Икенче мәрсиядә

---

[1] *Фәхретдин* Р. Асар. Беренче җилд. Алтынчы җөзьә. Б. 284.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.

Гали Чокрый үзенең кайсы яктан булын күрсәтеп яза, әсәрнең авторы итеп «Вади Болгари»ны атый. Бу имза да Г. Чокрыйныкы. Аныкы икәнлеге фәнгә дә яхшы мәгълүм. Автор бу мәрсиясен «касыйдә» буларак та атый. Ул Г. Чокрыйның үз әнисе Гөлбаһарга багышлап, 17 яшендә Пермь губернасы, Осы өязе, Танып авылы Хәйреззаман бине Габди мәдрәсәсендә укыган чагында язылган, фәндә югалган исәпләнелгән мәрсия. Бу әсәрнең табылуы шуңа күрә аеруча әһәмиятле.

Х1Х йөзнең беренче яртысы элегик татар шигърияте (ягъни мәрсияләр һәм мәдхияләр язу дәвере) Һ. Салихов йогынтысында үсеш ала. Ул Г. Утыз Имәни иҗаты белән аваздаш булып, үзенә бер әдәби мәктәп барлыкка китерә. «Дөррел-Кәлам» китабын шул мәктәпнең табигатен күзалларга ярдәм итүче җыентыкларның берсе буларак тану дөрес булыр.

### «Дөррел-Кәлам» поэмасы үзенчәлекләре хакында

Һибәтулла Сәетбаттал улы Салихов (1794–1867) татар диндар-суфи шигъриятенең соңгы вәкилләреннән берсе булып тора. Ул – элегия дәверенең иң олуг затлы әдипләреннән, суфичылык романтизмы белән сугарылган, иманга таянган татар ислам шигъри мәктәбен саклаган һәм үстергән, халык алдында әүлия мәртәбәсендә күрелгән бөек шәхес. Бу шигъри мәктәпкә Кырым, Касыйм, Казан, Әстерхан, Кавказ, Оренбург, Стәрлебаш, Себер якларыннан шактый санда шагыйрьләр кергәннәр, алар арасында зур әдипләрдән Габдеррәхим Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Әхмәтҗан Табуллы (Тубиле), Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый булган.

1856 елда Казанда дөнья күргән «Дөррел-Кәлам» дип аталган шигъри җыентык Һ. Салиховның күләмле поэмасы белән ачыла. Әсәрнең соңгы юлларының берсендә шагыйрь: «Фи китабин исмүһи – «Дөррүл-Кәлам» – дип белдерә, ягъни «Китапның исеме – «Кәлам энҗесе», ди. Шушы сүзләреннән авторның бу әсәрне аерым китап буларак язганлыгы күренә. Аңа бәйле рәвештә җыентыкның үзен дә нәширләре «Дөррел-Кәлам» дип исемләгән. Безнең максатыбыз шушы поэманы әдәби-текстологик анализ принципларында тикшереп бәяләүдән гыйбарәт.

1

«Дөррел-Кәлам» поэмасы Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларын бәян итү белән башланып китә. Автор: «Тәңрегә чиксез шөкер итәм», – дип белдерә һәм Аллаһның тугыз үзенчәлегенә инандыруга күчә. Беренче урынга барчаларга ярдәм итүче булуын куя, моны кадыйрлыгына бәйли: «Сөнгычендә һәм йәнә камил торыр» («Сәнгате эчендә һәм шулай ук камиллек иясе»), – ди. Аның кодрәтеннән һәммә нәрсә килә: галәмне дә, хәтта бер уч туфрактан Адәмне дә бар кылган. Адәм дигәндә шагыйрь, Адәм пәйгамбәрне генә түгел, һәммә кешеләрнең бар кылынуын күз алдында тотып яза. Үзенчәлекләрен бәян иткәндә, кайсыларына бер шигъри юл, кайсыларына тулы бәет багышлый. Бишенче үзенчәлеге итеп ул Аллаһның тиңдәше һәм арадашчысы юклыгын, алтынчы үзенчәлеге буларак, электән барлыгын, ягъни беренчел (кадими) үзенчәлекләрен белдерүне алга чыгара һәм шунда ук Аллаһның үлемсезлеге белән мәңгелеген атап үтә. Җиденче үзенчәлеге – галәм серләрен бар кылуында, сигезенчесе – гөнаһларны ярлыкаучы һәм гафу итүче булуында, тугызынчысы – мәңге-бакый ризыклы итүендә. Ахырда шагыйрь: «Васфы аның – «кулһуаллаһы Әхәд» («Үзенчәлеге аның – «Аллаһыны бердәнбер дип әйт»), – дип, поэмасының бу бүлеген Коръәннең «Ихлас сүрәсе»ннән хәбәр белән тәмамлый.

Алга таба поэмада аерым-аерым дүрт бүлек бирелә. Автор аларны «Әл-Баб» дип атап, саннарында күрсәтеп, исемләп белдереп бара. Алар шулай ук тематик бүлекчәләргә бүленеп бирелгән. Шагыйрь аларга да аерым исемнәр куйган.

Беренче бүлек – «Әл-бабул-әүвәлүн фит-тәрбиһи бил-мәүти» («Беренче бүлек үлем куркынычы хакында»). Һ. Салихов сүзен барча җан ияләренә үлем насыйп ителүе хакында хикмәт әйтүдән башлап китә, Коръән аятьләреннән искәртеп, Ләүхә-Каләм, җәннәт-тәмуг, Гарше-Көрси хакында белдерә, Аллаһы Тәгаләнең мәңгелек булуын яза, һәр кешегә үлем вәгъдә ителүен белдереп: «Малы-мөлкен, җөмләсен тәрк идисәр», – ди, адәм баласының барча байлыгын, казанганын ятларга калдырып, кара җир куенына ихтыярсыз китәчәге хакында искәртә.

Кешегә әҗәлдән котылырга, үлем килгәч, хәтта бер генә сулыш алырга да чара юк икән. Кичен генә сау-сәламәт булган кешеләр дә таң атканчы тар кабергә керәләр, ди шагыйрь. Бу әҗәл илләрне җимерә, хатыннарны тол калдыра, балаларны ятим ясый. Шушылар хакында шигъри бәяннарын биргәч, шагыйрь бу урында фикерләрен хикмәт әйтү ысулында төенләп куя: «Бу әҗәл куймас кешене дөньяда, Бу әҗәлнең дәрденә юктыр дәва».

Шушы сүзләренә дәлил буларак, шагыйрь аерым фактларга, шәхесләргә күчә. Сүз үтемлеге өчен укучыга ул бер-бер артлы конкрет сораулар белән мөрәҗәгать итә. Дусларың да анда киттеләр, Аллаһның сөеклесе Мөхәммәд пәйгамбәргә дә бу дөнья таяныч булмады, газыйлар да тар кабергә керделәр, тәхет иясе шаһзадәләр, мин-мин дип мактанучылар да юк, ата-аналарың, сөеклеләрең инде берсе дә калмады, аларга таяныч була алмаган дөнья синеме таяндыра, дип белдерә. Шушылар хакында язганнан соң, тагын фикер йомгагына килә һәм: «Гыйбрәт алгыл сән болардан, и фәлән, Сәңа һәм йитәр бу нәүбәт бигөман»,– дип хикмәткә хас шигъри нәтиҗә ясый да кабат теманы үстерүгә күчә. Бу юлы инде гүргә керү вакыйгаларын сурәтләп ала.

Алга таба «Зикре дөнья мәккәрү-гаддарә» («Мәкер иясе һәм хәйләкәр дөнья хакында») дигән бүлекчә ачып, дөнья малына кызыкмаска тиешлек хакында яза. Дөнья малы кешене һәлакәт диңгезенә салучы икән. Ул һәммә кешеләрне җәфаландыра, әмма беркайчан терәге була алмый. Байлык тышкы яктан гына алтын кебек ялтырый, әмма аның эчке ягы агудан һәм агулы еланнан гыйбарәт. Шагыйрь дөньяны «сачы дүклек, дешләре дөшмеш» («чәче коелган, тешләре төшкән») карт хатын, ягъни карчык белән тиңли. Җитмәсә, «кына» диеп кулларына каннар җыя, кара күмер белән күзенә сөрмә тарта, ак кирпеч белән йөзен агарта, бизәкләргә бизәнә. Дөньяның мәкерен Һ. Салихов уйнашчы хатын гамәлләре белән тиңләп сурәтли, укучысын, «и ага» дип, шуның мәкерләреннән сакланырга үгетли.

Поэманың беренче бүлеге шулай тәмамлана. Алга таба «Әлбабус-санийун фит-тәнбиһи иләл тәүбәти» («Икенче бүлек (Ахирәттә) уянганчы тәүбәләнү хакында») бүлеге килә, аны автор

«Бәйанүл-йәүмүл-Хәшр» («Мәхшәр көне хакында») һәм «Фи бәйанит-тәүбәтин» («Тәүбә итү хакында») дип аталган аерым бүлекчәләргә бүлә.

Бу бүлекне шагыйрь үгет-нәсыйхәт белән башлап китә, күзне ачарга, җирдәге гыйбрәтләрне күрергә чакыра. Наданлык йокысы күзеңне баскан, йокы йөзеңне саргайткан, ди. Гафләт йокысы дигәндә, мистиклар летаргик халәтне күздә тоталар. Дөнья малына кызыгу да аларда летаргик йокы халәте буларак аңлатыла. Укучыга мөрәҗәгать итеп, Һ. Салихов «күзләрең бер бөртек чүпне һәм пакьлектән нәҗесне аермас булды», ди, «юл ярагын алырга» чакыра. Боларның мәгънәсе аңлашылып тора, ул укучысын диндарлыкка дәшә. Динсезлек, шагыйрь фикеренчә, «күзгә наданлык карасын сөртү» һәм тормыш «юлында үзеңә мәшакать йөкләү»дән гыйбарәт.

Шушы фикерләрен бәян иткәч, «юлыңда бер караңгы өй» бар, анда ихтыярсыз керү хакында бәет китереп, берничә шигъри юлларда кабердә бәдәннең хур булып, тешләрнең коелуы, газап кырмыскалары һәм чаяннарының үле тәнне ашавы, бу хәшәрәтләрне куарга дәрманның калмавы хакында яза да, бары тик дөрес гамәлләрнең генә яхшы юлдаш икәнлеген белдереп, фикерен йомгаклап куя.

Алга таба Мәхшәр көне хакындагы бүлекчәдә шагыйрь кабердән барча кешенең кубарылуын һәм бәндәләрнең «бәдәннәре куркудан тетрәнәчәген» яза, һәркемнең яхшы-яманнан Аллаһ каршында җавап тотачагына туктала, савапсыз гамәлләр кылмагансың икән, ни эшләрсең диярәк укучысына мөрәҗәгать итә, «Хак сәңа идә хисап» дип, Һ. Салихов Аллаһның бәндәләреннән ничек сорау алуын сөйләп уза. Ә җавапта кешенең дөньяда сансыз гөнаһлар кылуын, бәндәнең үлемнән курыкмыйча саташып йөрүен, «гыйбадәткә буй куймавын», «туры юлны ташлавын» бәян итә, тормышта яшәвен тигәнәккә бату белән тиңли, соңга калмыйча тәүбә итәргә һәм «барлык кылган эшләренә борчылырга» чакыра. Шуннан соң мантыйклы рәвештә тәүбә хакындагы бүлекчәгә күчә.

Һ. Салихов туры юлга тәүбә ярдәмендә керергә мөмкин, башка чара юк дип белдерә. Аллаһны ул бу бүлекчәдә «барлык

гөнаһларны гафу итүче», «гафу итеп ярлыкаучы шәфкать иясе», «гыйбадәт тәүбәсен кабул итеп гафу итүче» дип атый. Әмма моның өчен тәүбә кабергә кергәнче, дөньяда яшәгән вакытта ук итү тиеш икән. Алга таба шагыйрь тәүбәнең һәркемне «юлга күндерүе», «максатка ирештерүе», «уттан коткаруы», ягъни җәннәткә керүгә сәбәп икәнлеген аңлатып үтә һәм тәүбәне «барча гыйбадәтләрнең башы», «барча олугларның эше» дип атый.

Һ. Салихов бу бүлекчәдә пәйгамбәрләр хакында да яза, аларның «гөнаһ-бозыклыклардан пакь» икәнлекләрен, ә Мөхәммәд пәйгамбәрнең барча нәби-рәсүлләргә имам булуын, шулай да «көн дә йөз тапкыр тәүбә итүен» искәртеп уза. Укучысына «гомерең фәскы-гыйсъян белән үтте» дип ачуланып мөрәҗәгать итә, Тәңре кушмаган эшләрне кылырга өметләнмәскә чакыра. Шуның белән әсәрнең икенче бүлеге тәмамлана.

Поэманың алдагы бүлеге «Әл-бабус-салисун фи бәйанин фаидәтис-салати» («Өченче бүлек гыйбадәт-намазларның файдасы хакында») дип аталган. Шагыйрь сүзне намаз-доганың бәндәләрне тәмугтан котылдырачагы хакында язудан башлап китә. Бу бүлекнең тәүбә хакында хәбәрләр бирүдән соң килүе игътибарга лаек. Моның белән шагыйрь тәүбәсез кешенең гыйбадәткә лаеклы була алмавын искәртә. Тәһарәт хакында сүз юк. Моны тәһарәтне тәүбә алыштыра дигән сүз буларак кабул итәргә ярамый. Бу үзенчәлегеннән авторның мантыйгы суфичылык өйрәтмәләре нигезендә корылганын аңларга тиешбез. Бүлектә Һ. Салихов, намаз кылуның саваплары, аларны калдыру, бинамаз бәндәнең хәле яманлыгы хакында аңлатканнан соң, Мөхәммәд пәйгамбәрдән намазны ташлау хакында сорагач, ничек дип җавап бирүенә бәйле хәбәрне әдәби вакыйга ясап сурәтли.

Билгеле булганча, биш вакыт намаз – мөселманлык билгесе, автор бу бүлектә шушы мәсьәләне хикмәт дәрәҗәсенә күтәреп яза, әйткән сүзләренең үгет-нәсыйхәт икәнлеген дә искәртә. Шуннан соң дүртенче бүлеккә күчә. Аны «Әл-бабур-рабигун фи бәйанин әл-әмсал», ягъни «Дүртенче бүлек мәсьәләләр бәйаны» дип атый, анда да нәсыйхәтләрен бирә.

Төзелешенә игътибар итсәк, «Дөррел-Кәлам» поэмасының һәр бүлеген Һ. Салихов нинди мәсьәләне күтәргән строфа белән бетерсә, аның артыннан килгән бүлекне дә шул ук мәсьәләне кузгату белән башлый, әмма бу юлы ул мәсьәләгә киңрәк туктала.

Һ. Салихов нәсыйхәтне сабак, дәрес бирү белән тиңли, Аллаһның белемне әмер итүен, белем ярдәмендә хатадан тыелу юлы табылуын белдереп уза. Кылмаска диелгән гамәлне башкаручыны Аллаһ тәмугка дучар итәчәген аңлаткач, тыелганнан качкан кешеләрнең җәннәтле булачагын язып, автор алга таба җәннәт һәм тәмуг хакында бүлекчә урнаштыра. Анда алдан җәннәтнең сыйфатлары, рәхмәт нурыннан барлыкка китерелүе, туфрагының зәгъфран, ташларының энҗе-мәрҗән икәнлеге, ризыкларның муллыгы бәян ителә. Аллаһ җәннәттә «һәрбер колына бер шәһәр бирә», «һәр шәһәр эчендә җитмеш мең сарай була», «һәр сарай эчендә бер нурлы тәхет бар» дип белдерә. «Һәр тәхеттә бер нурлы хури утыра» икән. Моны раслап Коръәннән Аллаһның сүзләре китерелә. Шуннан соң җәннәткә кергән бәндәләрнең хәлләре сурәтләнә, Коръәндәге болар хакындагы хәбәрләрдән шигъри тәрҗемәләрне текст эчендә «диде Коръәндә бу илә» дип бәян итеп бара. Шуннан соң гына Һ. Салихов җәһәннәм хакындагы бәяннарына күчә. Җәннәт нурдан бар кылынган булса, Аллаһы Тәгалә җәһәннәмне «катрә уттан» бар итте, ди шагыйрь. Тәмугка керүчеләр, анда күргән газаплар искәртелә, Аллаһтан гафу итүен үтенүләрен, түзәрлек хәлләре калмавын белдерүләрен яза. Әмма Аллаһы Тәгалә аларның теләкләрен кире кага, сәбәбе – берсе дә дөньялыкта яхшы гамәлләр кылмаганнар, пәйгамбәрләрнең сүзен тотмаганнар.

Һ. Салиховның тәүбә мотивын югары куюы шәехе Дәүләтшаһ ишан өйрәтмәләреннән килә. Чөнки Дәүләтшаһ ишан, үзе хөрмәт иткән һәм чын мөселман дип санаган кешеләрнең исемнәрен телгә алганда «Гаффаруллаһ» дип әйтүне гадәт иткән. Аның бу үзенчәлеге хәтта язмаларында да күренә.

Бүлек ахырында шагыйрь үгет-нәсыйхәтләр бирүгә күчә, дөньялыкта яшәгәндә бары тик яхшылыклар кылырга, бозыклыкка бармаска чакыра, «дөньяны биреп, җәннәтне ал сатып», ди. Гыйсъянны ул Шайтан белән тиңли, бәддогага таручының

«Тәңрегә дошман» икәнлеген яза, «ялган һәм гайбәттән телеңне пакь кыл», ди. Шуннан соң, ахырда, «Фи бәйанин әл-хәсәдаһ» («Көнчеләр хакында») бүлекчәсен урнаштыра.

Һ. Салихов көнчелектән азат булуны әдәпнең бөек мәртәбәсе буларак таный. Кешеләрнең байлыгына көнчелек итмәскә, Аллаһтан куркып еларга, шуның белән савапка ирешергә, усал сүз әйтеп, читләрнең күңелләрен бозмаска, яхшылык кылып сөендерергә, изгелегең ярдәмендә хәтерләрендә калырга, инде дә изгелеккә көчең җитмәсә, яманлык-золымнан тыелырга, кайгы җыймаска, нәфсене симертмәскә, белгәннәреңне башкалардан яшермәскә, иртән торып намаз укырга, Аллаһтан тәүбә үтенергә нәсыйхәтләр бирә, менә шул вакытта теләкләрең кабул буласын искәртә. Ата-ана рухына атап догалар укырга, гыйффәттә-сафлыкта күңел-кальбеңне сафландырырга, яхшыларга ияргә, һәр эшне әдәпкә таянып башкарырга үгетли, болар исә шулай ук максатыңа җиткерер, ди.

Кешенең кемлеген Һ. Салихов аның чиксез юмартлыкка ия булуында күрә. Әдәпсезләрнең, һичшиксез, Аллаһның шәфкатеннән мәхрүм калачагын да белдерә. Иблиснең әдәпсез булганлыгын искәртеп, бар кайгылар да әдәпсезлектән килә, ди шагыйрь. Әдәпсезлек аркасында кояшка ай тотыла («шәмсе хосуф»), ягъни хәвеф килә, «бәдрә кәсуф була» (бу исә айның ундүртенче көненә бәйле, бу көндә мөселманнарга ят гамәлләрдән тыелу киңәш ителә), ягъни «әллә кемлек, оялмаучылык» була икән. Әдәпсез кеше ике дөньяда да бәхетсез, «акыллы икәнсең, әдәпсезлеккә барма» дип сүзен бетерә шагыйрь.

Шулай итеп, Һ. Салихов үзенең шушы «Дөррел-Кәлам« поэмасын үгет-нәсыйхәт бирү белән сугарылган хикмәт әйтүгә кора. Аның фикерләре суфичылыкка нигезләнгән һәм ул «Кәлам гыйлеме»н дә суфичылык ярдәмендә ачыклап бирә. Билгеле булганча, суфичылык асылда өч өйрәтмәгә корыла: 1) Аллаһка катгый инануга; 2) изгеләргә ышануга; 3) Мөхәммәд пәйгамбәрне хөрмәтләүгә[1]. Һ. Салиховның бу әсәре асылда шушы өч

[1] *Карагыз: Мец А.* Мусульманский Ренессанс. Изд. 2-е. / пер. с нем. Д.Е. Бертельса. М.: Наука, 1973. С. 163.

өйрәтмәнең беренчесенә корылган, калган икесе хакында анда ул бөтенләй дә искә алмый диярлек.

2

«Кәлам гыйльме», ягъни «Гыйльме-Кәлам», иман шартына бәйле фән буларак, инану кагыйдәләрен нигезли һәм дин ысулының асылын тәшкил итә[1]. Албания татарларыннан булган XIX гасыр төрек галиме Ш. Сәми сүзлегендә «Кәлам гыйльме»нә «Олуһият вә вәхдәнияттән (гыйбадәт ителүче зат Хак Тәгаләнең берлеге һәм барлыгыннан) бәхәс иткән һәм боларны акыл, мантыйк һәм хикмәт кагыйдәләре белән исбатлаган гыйлем, гакаид гыйлеме дип аңлатыла»[2] дигән аңлатма бирелгән. Моннан аңлашылганча, «Кәлам гыйлеме»нең икенче төрле «Гыйльме-гакаид» дип аталганлыгы бәхәс тудырмый.

XI гасырда Багдадта хәлифәнең «Шәраитүл-иман»ы халыкка таратылганнан соң[3], төркиләрдә бу гыйлем «Иман шарты» исеме белән йөртелә башлый. Аны мөселман мәктәпләренең тәүге сыйныфларында өйрәнгәннәр. Ул да шушы «Кәлам гыйлеме» инде.

«Кәлам гыйлеме»нең нигезендә биш төргә бүленгән кагыйдәләр җыелмасы ята. Аларның беренчесе – «Тәүхид кагыйдәләре» дип атала, Аллаһның бердәнбер булуын, мәңгелек икәнлеген, һичкемнән тумаганлыгын һәм һичкемне тудырмаганлыгын, аңа тиң һичкемнең һәм һичнәрсәнең юклыгын танырга өйрәтә. Шуны да искәртергә кирәк, Аллаһның сыйфатлары тикшерелә торган «Мәгърифәтуллаһ фәне» исә «Дин ысулы»ның аерым өлкәсенә карый һәм «Кәлам гыйлеме»нә керми.

«Кәлам»нең икенче өлкәсе «Гадәләт» дип атала, ул Аллаһның хөкемнәре мәсьәләсен тикшерә һәм тәкъдир хакындагы фәлсәфәгә корылган. «Кәлам»нең «Тәүхид» өлеше өйрәтмәләрендә катгый аермалыклар булмаса да, «Гадәләт» белән бәйле

---

[1] *Карагыз: Торнау Н.* Изложение начал мусульманского законоведения.– СПб., 1850 // Репринтное издание. М. 1991. С. 36–47.

[2] *Сами Ш.* Камусы-төрки. Беренче җилд. Дәрсәгадәт, 1318/1900. Б. 174.

[3] *Мец А.* Мусульманский Ренессанс. Изд. 2-е. Б. 176.

бүлектә сөнниләр шыгалардан, гаширыйлар әшгарыйлардан шактый аерылып та торалар. Мәсәлән, сөннилар һәркемнең тәкъдире Аллаһтан, ул ни боерган, шул була дип баралар, бу мәсьәләдә катгый фикердә торалар, язмышның Аллаһтан алынган төгәл күрсәтмә кысаларыннан чыкмавын белдерәләр. Һ. Салиховның поэмасында бу мәсьәлә нәкъ шулай яктыртыла.

Шыгалар да тәкъдирнең алдан бирелүенә ышаналар, әмма, сөнниләрдән тыш, алар һәркемнең эш-гамәлендә белгесезлек ята, ул ихтыярдан килә һәм менә шуның хаталы нәтиҗәсе өчен кешеләр Аллаһ алдында җавапка тартылалар дип тә баралар. Шулай итеп, шыгалар кеше язмышын хаос эчендә дип тә игълан итәләр.

Кешенең ихтыяры, сайлап алу ирегe булу ике мәзһәбтә дә кире кагылмый, әлбәттә. Бездә, татарларда, сөнниләрнең сәләфийә юлын тотучыларда, тәкъдирнең Аллаһтан бәндәсенә өлеше итеп бирелүе һичбер бәхәс ителми. Коръәндә исә, асылда, язмыш мәсьәләсенә килгәндә, бу дөньяда кылган гамәлләр өчен теге дөньяда һичшиксез җавап бирәчәклек, Аллаһның бары тик гадел һәм үзенә хас рәвештә хөкем итәчәге хакында сүз бара. Бу яктан Һ. Салиховның поэмасы Коръән белән тулы яңгыраш тапкан. Үлемнең һәркемгә һичшиксез килүе, аның һәркайсы кешегә Аллаһы Тәгалә белгән вакытта кына ирешүе – язмыш фәлсәфәсенең асыл эчтәлеген тәшкил итә.

«Каләм гыйльме»нең өченче өйрәнү өлкәсе – «Нәбүввәт», ягъни пәйгамбәрлек мәсьәләсе. Адәмнән башлап һәм Мөхәммәд пәйгамбәргәчә 124 000 пәйгамбәрнең килгәнлеге, Адәм, Нух, Ибраһим, Муса, Гайсә һәм Мөхәммәднең рәсүл булулары, халыкка дин китерүләре, Мөхәммәднең соңгы пәйгамбәр булуы, аңа шикләнми иман китерү, барча пәйгамбәрләрнең һичшиксез булганлыгына ышану хакындагы фикерләмәләр аның асылын тәшкил итә.

Шыгалар һәммә пәйгамбәрләрне, һичшиксез, гөнаһсыз, саф һәм пакь дип баралар. Сөнниләр моны инкяр итмиләр, әмма пәйгамбәрләрнең дә фәрештә түгел, ә кеше затыннан булып, хаталануларын таныйлар һәм андый очракларны «аяклары таеп китте» дип белдерәләр. Бу хакта Һ. Салихов та поэмасында язып уза.

«Каләм гыйлеме»нең дүртенче өлкәсе – «Мигад», ягъни кабердән кубарылу һәм Ахирәт тормышы мәсьәләләрен яктыртудан гыйбарәт. Анда җан-рух үлемсез дип танытыла. Монда җәннәт һәм тәмуг хакында Коръәнгә, хәдис һәм риваятьләргә таянып фәлсәфә кору дөрес санала. Кыямәт көне, аның һичшиксез булачагы, җаннарның тәннәр белән кушылачагы, Мәхшәргә сөрелү, игелекле һәм яман рухлар, җеннәр һәм башкалар, галәмнең Аллаһ тарафыннан ничек һәм ни рәвешле яратылуы, күкләрнең катлары, Гарше-Көрси, фәрештәләр, изгеләр һәм шуларга бәйле мәсьәләләр «Каләм гыйлеме»нең бу өлешен тәшкил итә. Бу өлкәдә Ислам диненең бер генә мәзһәбендә дә чикләүләр юк. Бары тик Коръәндәге ул мәсьәләләр белән бәйле аятьләр генә инкяр ителергә тиеш түгел. Бу яктан Һ. Салихов шигъри фантазиягә артык бирелмичә, асылда Коръән аятьләре нигезендә генә фәлсәфә кора.

«Каләм гыйлеме»нең бишенче өлкәсе – «Имамәт», ягъни Ислам динендә имамлыкның нәселдән-нәселгә күчүе мәсьәләсе. Бу мәсьәләләр сөнниләрдә бөтенләй юк, шыгалар мәзһәбендә генә бар. Шыгалар имамлыкны Гали сәхабә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең кызы Фатыйма гаиләсеннән мирас буларак килергә тиеш дип баралар. Шушы нәселдән туучылар гына аларда халыкларның тулы хокуклы хөкемдарлары санала.

Шыгалар унике имамны таныйлар, Хәсән белән Хөсәенне хәлифәлектән мәхрүм иткәннәре өчен, агалары өммияһларны һәм габбасиларны инкяр итәләр, уникенче имам булырга тиешле Мөхәммәд-Мәһдине, җир йөзендә могҗиза белән күренми йөри дип, «Сахибе-заман» («Замана хуҗасы») буларак атыйлар.

«Каләм гыйлеме»нең бүлекләре белән чагыштырып барганда, Һ. Салиховның «Дөррел-Каләм» поэмасының эчтәлеген һәм формасын тулысынча дөрес күз алдына китерү җиңелләшә, анда «Каләм гыйлеме»нең һәр мәсьәләсенә бәйле җаваплар ачык яктыртылган, сөнни мәзһәбенә караган сәләфийәдәгечә аңлатылган.

# СТӘРЛЕБАШ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ ӘСӘРЛӘРЕ

*Марсель Әхмәтҗанов*

XIX гасырның 40 нчы елларында төзелгән бер кулъязма җыентыкта татар поэзиясе өчен кызыклы яңа мәгълүматлар табылды. Җыентык 2010 елның июнендә Башкортстан Республикасы Стәрлебаш районының Тәтер-Арслан авылында китап кадерен белүче бер кешедә сакланган.

Кулъязма – мәдрәсәләрдә гарәп теле дәреслеге булып йөргән «Нәхү» китабы, аны Мөхәммәд-Хафиз бине Газизулла бине Фазулла шәкерт чагында күчереп язган. Соңыннан күчерүче, мәдрәсәне тәмамлагач, мулла булып «дамелла Мөхәммәд-Хафиз бине Газизулла» дип икенче урынга да имзасын куйган.

Мөхәммәд-Хафиз Стәрлебаш мәдрәсәсендә хәлфә булып та хезмәт иткән. Әлеге шәхес турында шуннан башка мәгълүмат табылмады. Ул күчергән кулъязма китапның буш калган 5 б–10 а битләрендә шигырь-мөнәҗәтләр урын алган. Бу шигъри әсәрләр дини, мәхәббәт, әхлак темаларына иҗат ителгәннәр.

Җыентыкта беренче «Мөнәҗәт»нең авторы итеп Хафиз күрсәтелгән. Без аны шушы китапның авторы дип уйладык. Икенче бер шигырьдә автор буларак Шәмсетдин исеме телгә алынган, өченчесендә Шәрбәк дип теркәлгән. Күпчелек шигырьләрнең авторлары билгесез. Аларны ачыклау өчен безгә әдәбият галимнәре Хатыйп Миңнегулов һәм Шәйхи Садретдинов тарафыннан языл-

ган «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре» (Казан, 1982) дигән фәнни хезмәт ярдәмгә килде.

Ул китапта Стәрлебашта укыткан татар шагыйре Шәмсетдин Зәки мөнәҗәтләре, шигырьләре һәм шигъри хатлары тупланган. Шуннан чыгып, кулъязма җыентыктагы әсәрләр арасында сигез шигырьнең Шәмсетдин Зәкинеке, берсе Шәрбәкнеке икәнен, калганнарының шагыйрь Хафиз тарафыннан язылган булуына инандык. Моннан тыш, Шәмсетдин Зәкигә нисбәтле әсәрләрнең дә иҗади эшләнеп, Хафиз каләменә нисбәтләнүе мөмкин. Чөнки Шәмсетдин Зәки әсәрләренең бик кыскартылып, яки аерым юллары гына аның шигырьләреннән алынуы мөмкин. Басма һәм кулъязма текстлар арасында аермалыклар шактый зур һәм аерым игътибарга лаек. Безнең фикеребезчә, бу аермалар Шәмсетдин Зәки үзе исән чагында ук аның әсәрләре вариантларда таралу яки башкалар тарафыннан эшкәртелү мөмкинлеген күрсәтә.

Шәмсетдин Зәки шигырьләренең күчермәләре сирәк табыла. Аның әсәре беренче тапкыр 1989 елның апрелендә Ташкент шәһәрендә безнең кулга керде. Ул вакытта без шагыйрьнең Һибәтулла Салиховка кызын сорап язган хаты күчермәсен тапкан идек. Бу хат фәндә мәгълүм һәм аны профессор Хатыйп Миңнегулов 1982 елда матбугатта хәбәр итте. Ул табышыбыз хакында мәгълүматны без дә фәнни басмада игълан иткән идек[1].

2010 елда Тәтер-Арслан авылында табылган кулъязма җыентык күләмлерәк һәм борынгырак дияргә мөмкин. Бу факт Шәмсетдин Зәкинең үзе исән чагында ук шигырьләренең башкалар тарафыннан күчерелеп дөньяга танылуы хакында сөйли.

Без бу мәкаләдә җыентыктагы шигырьләрнең зур өлешен кулъязмадагы тәртип буенча текстологик хәзерләп, кыскача искәрмәләр язып, сүзлекчәләр төзеп бирдек. Кулъязмада сүзләрнең язылышында күп аермалар бар. Биредә аларны нигездә кулъязмадагы рәвештә бирдек, төзәтмәдек: алга таба әле бу аермалар Ш. Зәки әсәрләренең фәнни басамаларын хәзерләгәндә бик мөһим дә булырлар.

---

[1] Әдәбият чыганаклары һәм текстологиия. Казан, 1992. Б. 9–12.

Табылган кулъязма Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә (Мирасханәсендә) саклана (фонд № 39, 7240 нчы саклау берәмлеге). Яңа табылган чыганак Шәмсетдин Зәки һәм Хафизның иң борынгы язма текстлары буларак та кыйммәтле, чөнки алар әсәрләренең XIX гасырның беренче яртысындагы күчермәләре әлегә мәгълүм түгел.

### *Мөнәҗәт № 1*

*Имди йарый әйләңез бу бәндәгә хәйерат[1] үзә,*
*Нәфсинә кол бу гөнаһкяр куймадый тагать[2] үзә.*
*Йахшы кулдан тәүфикъ үзрә эстәрем[3] изге дога,*
*Дайим[4] әйлә мөгаҗҗиб[5] улдым, белмәдем бәндә була.*
*Тәүбә сабыны пелә[6] китсәче, китсәче вә җәһәннәм карасы,*
*Бармыйдыр халык углыйда мән тик гөнаһ ийәсе!?*
*Тасриф[7] илән хәйере кыйлмаз алданып ушбу фәкыйрь,*
*Дин–дөнйа мәгалисе[8] һәр хәлдә хәйран хәкыйрь[9].*
*Кыйл мөйәссәр[10] сәйре[11] үзрә бәндәгә, и зөлҗәлал[12],*
*Кыйлма шаккый[13] ду[14] җиһанда и кәрим, и зөлҗәлал!*
*Һәр заманда мин фәкыйрьгә йулдаш ит иманыңый,*
*Рәхмәтеңлә һәм мәляикә[15] алгай ирди җаными.*

---

[1] *Хәйерат* – изге эшләр.
[2] *Тагать* – буйсыну.
[3] *Эстәрем* – теләрмен.
[4] *Дайим* – һәрчак, даими.
[5] *Мөгаҗҗиб* – хәйран калучы.
[6] *Пелә* – белә.
[7] *Тасриф* – сарыф итү, үзгәртү.
[8] *Мәгалисе* – бөек идеяләр.
[9] *Хакыйрь* – кадерсез.
[10] *Мөйәссәр* – үтәрлек.
[11] *Сәйре* – йөргән.
[12] *Зөлҗәлал* – бөек (Аллаһ).
[13] *Шаккый* – авыр.
[14] *Ду* – ике.
[15] *Мәляикә* – фәрештәләр.

*Кабрем эчрә[1] рәхмәт әйлә, йа кәрим[2] и йа Әхәд[3],*
*Синдин үзгә ул урында әйләмәс һичкем мәдхәд[4].*
*Хәшер[5]-нәшер[6] һәм мизан[7]да, һәм сәругъда[8], һәм сират[9],*
*Һәр хөкемдә фазлың әйлә[10], безләрә вир[11] гел нәшат[12].*
*Һәм шәфәгать[13] рәсүлдән[14], кыйлма мәхрүм, и рәхим[15].*
*Каһәрең кыйлма сез өр безни беражҗим,*
*Кыйл мөшарәф[16], безгә дидар[17] андый йүзләр нур әйлә.*
*Һәр хәсрәттин зийадә[18] анда кол мәсрур[19] ула,*
*Бу зәгыйфь кол вәҗнене[20] ак әйлә рахман әр–рәхим,*
*Һәм кабул әйлә догасын и сәмигы, и хәлим[21] .*
*Бу тел илән күп доганы кыйлды бәшрәм[22] хәйларга,*
*Фазлы берлә фәйзъ[23] итәр дип зөлгата вә бикерийә[24],*
*Зари әйләп мескин Хафиз чүн диди бу сүзләри*
*Хак Тәгалә әйләсүн ак ду җиһанда йөзләри.*

---

[1] *Эчрә* – эченә.
[2] *Кәрим* – юмарт.
[3] *Әхәд* – бердәнбер. Аллаһы Тәгаләнең бер исеме.
[4] *Мәдхәд* – мактау.
[5] *Хәшер* – туплау, ислам динендә мәетләрне бер җиргә туплау.
[6] *Нәшер* – белдерү.
[7] *Мизан* – гөнаһларны үлчәү турында сүз бара.
[8] *Сәругъда* – сорау алу (?).
[9] *Сират* – гөнаһларны сынау өчен кылдан нечкә, кылычтан үткен – тәмуг өстеннән уздырылган күпер.
[10] *Фазлың әйлә* – өстенлегең күрсәт.
[11] *Вир* – бир.
[12] *Нәшат* – сөенеч.
[13] *Шәфәгать* – шәфкать.
[14] *Рәсүл* – Мөхәммәд галәйһиссәлам.
[15] *Рәхим* – рәхимле Аллаһ.
[16] *Мөшарәф* – хөрмәт.
[17] *Дидар* – йөзең.
[18] *Зийадә* – артык.
[19] *Мәсрур* – шатлыклы.
[20] *Вәҗһене* – битене.
[21] *Хәлим* – сабыр.
[22] *Бәшрәм* – адәм балалары.
[23] *Фәйзъ* – белем, файда, муллык.
[24] *Бикерийә* – керсез.

## *Мөнәҗәт № 2*

*И җәмигы әнбийәнең сәрвәри,*
*Син, син әүвәл ахры заман пәйгамбәри.*
*И җиһанның җаный, җанның җаны сән,*
*Бәхри*[1] *мәгъни дә сәгадәт*[2] *кани (?) сән.*
*И камуг атлыларның дәрманы сән,*
*И камуг галәмнәрнең солтаны сән.*
*Сиңа мөштак*[3] *улдый җөмлә әнбийә,*
*Әүлийа, вә такыйа, вә сафийә.*

## *Мөнәҗәт № 3*

*Бармакыңдан икесе бар булды ай,*
*Могъҗизатыңа ирешмәз фокарай*[4].
*Синдә усаф кәмальнең*[5] *саны йук,*
*Синдин әгьраз*[6] *әйләйәннең җаны йук.*
*Без таглый кеби, безгә сән дайәсән,*
*Өстемдә сал шәфагать сәйәсен.*
*Йарин анда бези әй [сән] заль хода,*
*Кәнд үзеңдән кыйлмагыйл нәргиз җөда.*
*Чөн һәр талибләрнең матлубе*[7] *сән.*
*Чөн һәмма гашыйкларның мәхбүбе сән.*
*Сәр шәрәфендән синең нуш*[8] *тидиләр,*
*Җанларны мәст сәрхүш*[9] *итдиләр.*
*Без зәгыйфь өммәтләреңдинмез наман*
*Эстәрмез синдән шәфагать нәр заман.*

Искәрмә: икенче һәм өченче мөнәҗәтләр Х. Миңнегулов китабында (б. 78–79) Шәмсетдин Зәкинең бер шигыре итеп күрсәтелә. Андагы шигырьнең соңгы 20 юлы кулъязмада теркәлмәгән. Ләкин № 2 мөнәҗәттәге баштан ике юл басмада юк.

---

[1] *Бәхри* – диңгез.
[2] *Сәгадәт* – бәхет.
[3] *Мөштак* – омтылучы.
[4] *Фөкарай* – ярлы (надан).
[5] *Кәмальнең* – камиллекнең.
[6] *Әгьраз* – гарыз.
[7] *Матлубе* – эзләгәне.
[8] *Нуш* – татлы эчемлек, исерткеч.
[9] *Мәст сәрхүш* – лаякыл.

## ***Мөнәҗәт № 4***

*Хода, йа пәрдәне күтәр күземдин*
*Мәгасый*[1] *карасын йугыйл йөземдин.*
*Азат әйлә бәндән бу гөманный,*
*Ки фәрекъ*[2] *идәм дөнеми көдезүмдән.*
*Каму гыйсъйан*[3] *вә тәкъсир*[4]*емен гафу ит,*
*Дигәринә*[5] *куркырым йавлак үземдән.*
*Камусындан улса лотыф*[6] *гыйнайәть*[7]
*Бәңа нәфегъ*[8] *улмайа пич кәндәй*[9] *зәхмәт.*
*Нә дәклү дисәм әшгарь*[10] *кодери,*
*Нә сәвдә улса бәңа ушбу сүземдин.*
*... сохбәтен бәңа насыйб ит.*
*Нә хасыйл ула бәңа йалгыз Хода.*
*Сиңа гыйшкым белән дивана булдым,*
*Кыздым канлый йәшем бән күземдән.*
*Бу хәсрәт берлә булдым хәстә шәйдә,*
*Башымны нич күтәрмәсмен деземдән.*

Искәрмә: № 4 мөнәҗәт Ш. Зәки версиясендә озынрак, кулъязмада 16 юл, Х. Миңнегулов (б. 56–57) басмасында 46 юл. Кулъязмада басмада булмаган юллар, алыштырып куелган сүзләр шактый күренә.

## ***Мөнәҗәт № 5***

*Һәр нә кыйлсаң – кыйл бәңа,*
*Иллә кәндүңдин*[11] *бәни кыйлма җөда*[12]*.*
*Хуш сүвәрем лотфың*[13] *вә каһәрүңи*[14]*,*

---

[1] *Мәгасый* – гөнаһлар.
[2] *Фәрекъ* – аеру.
[3] *Гыйсъйан* – фетнә.
[4] *Тәкъсир* — гаеп, кыскарту.
[5] *Дигәринә* – баш кага.
[6] *Лотыф* – мәрхәмәт.
[7] *Гыйнайәть* – кайгыртучанлык.
[8] *Нәфегъ* – файда.
[9] *Кәндәй* – нинди.
[10] *Әшгарь* – шигырь.
[11] *Кәндүңдин* – үзеңнән.
[12] *Җөда* – аерма.
[13] *Лотфың* – гүзәллегең.
[14] *Каһәрүңи* – усаллыгыңны.

*Хуш ичәрүм балыңи вә зәнәреңи.*
*Һәр ни кем – синдән килүр ул яхшыйдыр,*
*Гәр җәфа, вә гәр гата вә йахшыдыр.*
*Чөнки гыйшкыңлә йугырдыйм җанымы,*
*Йулыңа миһрак*[1] *идәрмен канымы.*
*Гәр салурсәң буйыныма*[2] *шәмшир батыйг.*
*Җан шәрримни*[3] *кыймазым дәрыйга*[4].
*Коллыгыңда чүн булубдыр чашне*[5],
*Вирди бу мескин йулыңда башыны.*
*Варлыгымдан тәүбә кыйлдум бән бүген,*
*Үземи йуклыкга салдыйм бән бу көн.*
*Безгә сәйратдур*[6] *без һәм сәрхәйәмез*[7],
*Чүн гыйнайәтдур*[8] *бу йулда сайәмез*[9].
*Гашыйкым бән каһреңз вә лотфыңа*[10],
*Ушбудыр сәндән бәңа, бәндин сиңа.*
*Гәр дәгүлсәм лайык минер вафа*[11],
*Хуш, йарәшнү, вә башыма каһре сафа*[12].
*Чүн сиңа әсмарладыйм*[13] *һәр эшеми,*
*Уда йакдыйм*[14] *гамеми вә тәшвишеми*[15].
*Шул ки мәгънәдән сәргар*[16] *улмадый,*
*Бу мөгаммәдән хәбәрдар улмадый.*

---

[1] *Миһрак* – мәхәббәт.
[2] *Буйынама* – муеныма.
[3] *Шәрримни* – үчемне.
[4] *Дәрыйга* – үкенечкә.
[5] *Чашне* – күзне.
[6] *Сәйратдур* – планетадыр.
[7] *Сәрхәйәмез* – әйләнәбез.
[8] *Гыйныйәтдүр* – ярдәмдер.
[9] *Сайәмез* – сәяхәтчебез.
[10] *Лотфыңа* – гүзәллегеңә.
[11] *Миһер вафа* – тотрыклылык дуслыкка.
[12] *Акһре сафа* – җәберләүче рәхәтлек.
[13] *Әсмарладыйм* – багышладым.
[14] *Уда йакдыйм* – утка яктым.
[15] *Гамеми вә тәшвишеми* – уйларымны.
[16] *Сәргар* – аптыраган.

## ***Мөнәҗәт № 6***

*Гыймадым[1] йәкрәк[2] сиңа, и зәшт[3] талига[4],*
*Вөҗүдең гәр ула әгъйар әзарар.*
*Сән ул дәм дәүләт лайык улурсән,*
*Ки варлыкыңда нәфегъ[5] күрсә һәрвар.*
*Әлең[6] баглу дәгел кән изгү эш кыйл,*
*Чу форсат вакыйтыйдур хәйр дөшвар[7] .*
*Әүхидең булса хакдан гафу рәхмәт,*
*Өмидлүләрни нәүмиз итәм һәрбар.*
*Йыкыйлмышларә кыйлмасаң иганәт[8],*
*Йыкылдыкда сиңа  һәм йук [ходудкяр].*
*Рәва кыйл[9] хаҗәтен гаҗизләрүң гәр,*
*Деләрсең сиңа асан улса дөшвар.*
*Күңел энҗү тимә гел золымы әйләсә һәргиз,*
*Сакын[10] булмассыз, и каһир кәһар.*
*Нә кыйлса аны күрүр адәм углы,*
*Нә иксә аны урыр ахрый кяр[11].*
*Бу өслүб[12] үзрәдүр милкең низамы[13] ,*
*Бу рәсем дәвер идебдүр чәрех[14] дәвер.*

Искәрмә: № 6 мөнәҗәт Ш.Зәки версиясендә 36 юл, кульъязмада 18 юл. Текст кульъязмада кыскарак, сүзләр алыштыру очраклары бар. Басмада текст Х. Миңнегулов китабының 67–68 битләренә туры килә.

[1] *Гыймадым* – таянычым.
[2] *Йәкрәк* – бергә.
[3] *Зәшт* – ямьсез.
[4] *Талига* – алда.
[5] *Нәфегъ* – файда.
[6] *Элең* – кулың.
[7] *Дөшвар* – кыен.
[8] *Иганәт* – ярдәм.
[9] *Рәва кыйл* – үтә.
[10] *Сакын* – кузгалмаучы.
[11] *Кяр* – эшче.
[12] *Өслүб* – калып.
[13] *Низамы* – кануны.
[14] *Чәрех* – тәгәрмәч.

### *Мөнәҗәт № 7*

*Гәр гыйнаятьдән[1] кыйлурса фәтех баб[2],*
*Вирсә сиңа җам гыйшкындан[3] шәраб.*
*Һәр кеми сүвсә аңа вирур таләб,*
*Та таләп[4] булгай васыйлына[5] сәбәп,*
*Һәр кеми кем сүвмәдеи ул падишаһ,*
*Бәс хиҗаб[6] улды аңа сорых[7] сииаһ[8].*
*Гәр булырсың әһле мәйдан риза,*
*Кыйлсын Хак гыйшкыйда җаның фида.*
*Табыласын ул хәбибең васыйлыны,*
*Табыласын һәр морадың асылыны.*

### *Мөнәҗәт № 8*

*Җанә җанын эстәйән килсүн бирү,*
*Дәрдә дәрман эстәйән килсүн бирү.*
*Җөмлә әрвахның газасы бәндәдүр,*
*Җөмлә чадуның дәвасы бәндәдүр.*
*Кил бирүсән, кил бирүсән, кил бире,*
*Килмәз ирсәң йөри бир андан ары.*
*Килдүкүң үзең өчүндүр, и ага!*
*Аның өчүн әйдерәм бу көн сиңа.*
*Ихтыйар җәзаиңи сарыф әйләгел,*
*Шунча-монча эшләрем вар димәгел.*
*Бетмәйә эшең синең нәтамам,*
*Иатмайынча өстүңә күб хәштикәр*
*Кемсә дөнйа максудина йитмәди,*
*Үзе бетмәйенчә, эше бетмәде.*

Искәрмә: кулъязмадагы № 7, 8 нче мөнәҗәтләр Х. Миңнегулов басмасында бербөтен итеп ялганып бирелгәннәр (б. 69). Күләм ягыннан алар икесе дә тигез, 24 әр юл. Текстларда аерым сүзләрнең тәңгәл килмәгән очраклары бар.

---

[1] *Гыйнаятьдән* – булышлыктан.
[2] *Фәтех баб* – бүлекне ачу.
[3] *Җам гыйшкындан* – гыйшык бокалыннан.
[4] *Та таләп* – таләпкә чаклы.
[5] *Васыйлына* – кавышуына.
[6] *Хиҗаб* – чадра.
[7] *Сорых* – кызыл алтын.
[8] *Сийаһ* – кара төс.

## *Мөнәҗәт № 9 (Нәфес)*

*Эстәрем синдән шул күңел,*
*Кем ануңла булса да сиңа йул.*
*Шул күңелдән син йырак иткел бәне,*
*Кем аңыб нәфсене, онытды сәне.*
*Кем ки нәфсееӊ хөкменә мәхкүм*[1] *алур,*
*Тәңри дәргяһындан*[2] *ул мәхрүм улур.*
*Йа, Илаһи, рәхмәтеңдәндүр өмид,*
*Нәфсе шәрендән*[3] *бән кыйлгыл бәгыйд*[4]*!*
*Нәфсе әлинә син бези табшырмагыл,*
*Бези ошбу хурлыкга калдырмагыл!*
*Нәфсе әлинә вирмәгел бердәм бәни, и бези,*
*Лотфың илә бәсләгел һәрдәм бәни, безе.*
*Барча эшләрдә бәңа виргел сәлах*[5]*.*
*Һәм насыйб ит бәңа фәүз*[6] *фәллах*[7]*.*

Искәрмә: № 9 мөнәҗәт басмадагы «Әл-имам» шигыре белән тема ягыннан гына туры килә.

## *Мөнәҗәт № 10*

*И, ходавәндәм, сиңадыр ибтихал*[8]
*Син гата кыйлгыл*[9] *безә фазыл кямал*[10]*.*
*Һәр кемә, кем синдән улмадый хәддад*[11]*,*
*Ул шакадәт*[12] *эчрә калды та абад*[13]*.*

---

[1] *Мәхкүм* – тоткын.
[2] *Дәргяһындан* – бусагасыннан.
[3] *Шәрендән* – явызлыгыннан.
[4] *Бәгыйд* – ерак.
[5] *Сәлах* – намус.
[6] *Фәүз* – җиңеп чыгу.
[7] *Фәллах* – игенчегә.
[8] *Ибтихал* – ялвару.
[9] *Гата кыйлгыл* – бүләк ит.
[10] *Кямал* – камиллек.
[11] *Хәддад* – тимерче.
[12] *Шәкадәт* – зарлану.
[13] *Та абад* – шәһәргә хәтле.

*Чара будур, кем сиңа йалваралум,*
*Йукса айырук, канча*[1] *дийә варалум*
*Синдән анчак эстәрем шаным сине,*
*Кортарый*[2] *вир ушбу бәндәңдән бәни.*
*Хаҗҗтем син син бәнем, айрук дәгел,*
*Үзгәне сорама, бәңа байык*[3] *дәгел.*
*Мөргъ*[4] *җаным аңа тирән итде хуш,*
*Гакыйблә*[5] *нәфсем аңа сәйран этди хуш.*
*Ушбу сүзләри диди хикмәт дели,*
*Ушбу рәмези*[6] *аңлармыз һәр гафили.*

Искәрмә: № 10 мөнәҗәт Ш. Зәки шигырьләре рәтендә Х. Миңнегулов хезмәтендә озын вариантта басылган (б. 65–66). Ләкин сүзләрдә, юлларда аермалар бар.

### ***Мөнәҗәт № 11***

*Кеше, кем булса гашыйк – эчендә – садыйк,*
*Булур ахыры аңа мәгъшукы гашыйк.*
*Нә йирдә бетсә гөл – анда бетәр гарь*[7]*,*
*Нә йирдә кәнеҗ*[8] *үлер, анда улса мар*[9]*.*
*Өмид васыйл йар улдыкда – һәр бар,*
*Хиҗаб – ул арада җәмыйгъ әгъйар*[10]*.*
*Әгәр сорсаң бәнем хәлемне нәр гяһ,*
*Фи би – Аллаһ, миннә Аллаһ, әли Аллаһ*[11]*.*
*Гыйнайәт*[12] *булмас бер кауля*[13] *синдән,*
*Кидәр дәүләт, йөзен чүереп андан.*

[1] *Канча* – күпме.
[2] *Кортарый* – коткар.
[3] *Байык* – лаек.
[4] *Мөргъ* – кош.
[5] *Гакыйблә* – соңыннан.
[6] *Рәмези* – ишарәне.
[7] *Гарь* – оят.
[8] *Кәнеҗ* – яшьлек.
[9] *Мар* – елан.
[10] *Әгъйар* – читләр.
[11] «Барысы да Аллаһы Тәгалә кулында» мәгънәсендә.
[12] *Гыйнайәт* – ярдәм.
[13] *Кауля* – бер авыз сүз.

## ***Мөнәҗәт № 12***

*Күңел дилбәрдәдүр[1] Әлхәмә Аллаһ,*
*һаман би бердәдер Әлхәмдә Аллаһ.*
*Нә гамь бик парә[2] булса ушбу җисем,*
*Чыга җан бирүрдәдер Әлхәмде Алаһ.*
*Күңелдә фикер, делдә зикер[3] – мәгани,*
*Мәхәббәт сердәдүр Әлхәмде Аллаһ.*
*Сиңа бәнем дәрдем дәвасы, синдәдер сер,*
*Бәнем кальбем[4] һавасы – синдер бисер[5].*
*Ничә йыл бу мират[6] галәмендә*
*Гизәрем дәм-бидәм һиҗран[7]гамендә.*
*Берадәр горрә[8] булма бу җиһанә*
*Каты мәкар[9] ирүр дәвер-заманә.*
*Ничә сәркәшләрнең[10] буйнын борды,*
*Бераз басылды, соңра йитерде.*
*Зәфун риза ирүр бу чәрех[11] гәрдән*
*Ничәне кыйлды йир куйнында мәсхүң*
*Илаһи әйлә куркулардан азат,*
*Илаһи әйлә ики шад – йиңил шад.*
*Дәмидә рәхәт ул – өммәт әйлә,*
*Рәсүлнең хөрмәтинә хөрмәт әйлә.*
*Ходайым сакла һич афәт,*
*Ходаның ....ы даим җанга рәхәт.*

---

[1] *Дилбәрдәдүр* – кыздадыр.
[2] *Парә* – кисәк.
[3] *Зикер* – искә алу.
[4] *Кальбем* – күңлем.
[5] *Бисер* – серсез.
[6] *Мират* – көзге.
[7] *Һиҗран* – сөйгән ярдан аерылу.
[8] *Горрә* – вакыт.
[9] *Мәкар* – мактау.
[10] *Сәркәшләрнең* – карышучыларның.
[11] *Чәрех* – тәгәрмәч.

(Бу шигырьнең дәвамы язылган бите югалган, аста төшерелгән кустод шуны күрсәтә).

*Әгәр талиб улурса – мөэмин шаб*[1],
*Сүвәр кем сүәр аны Раббы тораб*[2].
*Менеб дөнйа мәкамен*[3] *гайре мәгъмүр*[4],
*Булур зирәк, вәзиргә ибтидадыр*[5].
*Кеше кем булса – гыйшык эчендә садыйк*[6],
*Булыр ахыры аңа мәгъшукы*[7] *гашыйк.*
*Гыйнайәт*[8] *улмаса бер кауләсендән*[9],
*Кидәр дәүләт, йөзин чүәреб*[10] *андин.*
*Нә йирдә бетсә гол, анда бетәр харь*[11],
*Нә йирдә кәнеж*[12] *үлсә, анда ула мар*[13].

## ***Мөнәҗәт № 13***

*Ул хәбибе зәхме*[14] *безим дәрдемез йитмәдидүр,*
*Ул хәбибнең гыйшкы берлә күңлемез диванадур.*
*Бу сәбәбдин күзләремез йәш йиринә кан дүгәр,*
*Бу сәбәбдин кем һәмишә бәгъремез бер йанадур.*
*Бези хәйран әйләйин ул падишаһның шаукыйдур*[15],
*Бези сәкран*[16] *әйләйин ул хашир*[17] *имандур.*

---

[1] *Шаб* – яшь егет.
[2] *Тораб* – туфрак.
[3] *Мәкамен* – моңын.
[4] *Гайре мәгъмүр* – гадәттән тыш төзек.
[5] *Ибтидадыр* – башлаучыдыр.
[6] *Садыйк* – дуслык.
[7] *Мәгъшукы* – сөйгәне.
[8] *Гыйнайәт* – ярдәм.
[9] *Кауләсендән* – сүзеннән.
[10] *Чүәреб* – йөз чөереп.
[11] *Харь* – чәнечкеле үлән.
[12] *Кәнеж* – гөл.
[13] *Мар* – елан.
[14] *Зәхме* – ярасы.
[15] *Шаукыйдур* – теләгедер.
[16] *Сәкран* – исерткән.
[17] *Хашир* – туплаучы.

*Бакыйдарлыйк шул кешигә йарашур кем дөнйадур,*
*Йуг вафаны улубан ул бакый ишна йанадур.*
*Эстә Шәмсетдин аны кыйл син изгү эшне ихтыйар,*
*Андыйн үзгәсин фәкыйрә догада олулыкынадур.*

Искәрмә: шигырь текстыннан күренгәнчә, аны Шәмсетдин Зәки язганлыгы аңлашыла. Шигырь беренче мәртәбә басыла.

## *Мөнәҗәт № 14*

*Ничә ул шанның капусындин кидәрсен, и гидай,*
*Мостафа чүн ул капудан*
*Сәркәш убаш кыланның йире нар җәһим,*
*Габдә лайык, Нәгыйм рух илә рәйхан икән,*
*Вир, и сакый, җам мәгънидән шәраби зинһар,*
*Шул гарибә кем һәмишә үкдүке җанан*
*Нитә хәмрә гашыйк улмаздан чу гаташ энем һаман.*
*Бишнәи мескин ширәбәк гыйшык илә.*

## *Мөнәҗәт № 15*

*Ике галәмдә сүеклүк бер дорур,*
*Ике нәснәни сүгән кяфер дорур.*
*Ике сүеклү бер күңелгә сыгмайа,*
*Ике сүгән җан йукары агмайа.*
*Ике кыйбла кыйлмас чүн бердер йөз миннең,*
*Бер дорур, деләрсен бер кыйл үзең.*

# ЗАТЛЫ НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫЛАРЫ

*Нуридә Насыйбуллинаның Нил Рәмиев белән әңгәмәсе*

Безгә бөек бабаларыбыздан шанлы тарихыбыз, шәүкәтле телебез, мөкатдәс динебез, затлы мәдәниятебез мирас булып калган. Ләкин татар халкының XVI–XX йөзләрдәге тулы тарихы язылмаган әле. Билгеле булганча, халык язмышына кагылышлы тарихи вакыйгалар милләтнең аерым вәкилләрендә, нәсел-нәсәпләрендә төгәл гәүдәләнеш таба. Бу җәһәттән милләтне мәдәни-рухи яктан әйдәп баручы, иҗтимагый-милли тормышның үзәгендә торучы зыялы шәхесләрнең нәсел тарихы аеруча игътибарга лаек.

Татарның рухи мәдәниятен тәрәккый иттерү юлында берничә буын дәвамында хезмәт күрсәткән Рәмиевләр, Тукаевлар нәселе бар. Аларның нәсел тарихы – халык тарихының көзгесе. Рәмиевләр милли тарих, мәдәният, мәгариф, матбугат, иҗтимагый фикер, дин өлкәсендәге эшчәнлекләре, туган халкына намуслы хезмәт итүләре белән нәселләр тарихында үзенә генә хас лаеклы урын тота.

Татар шигъриятенең алтын баганасы булган нәселне дәвам иттерүчеләр Стәрлебаш төбәгендә халыкны аң-белемгә өндәп, ата-бабаларының эшен бүгенге көндә дә дәвам итә, яшь буынга нәселнең данлы эстафетасын тапшыра. Экспедиция вакытында аларның күбесе белән аралашып, тарихи вакыйгаларга күзәтү ясадык. XX гасыр башы татар милли тормышын яхшы белгән Стәрлебаш мәчете имамы Нил Әмирҗан улы Рәмиев (1937) үзенең истәлекләре белән ихластан уртаклашты.

*– Нил ага, мәгълүм булуынча, Стәрлебаш – шәхесләргә бай төбәк. Менә сез дә – шул зыялы кешеләрнең нәселен дәвам иттерүче. Үзегезнең тамырларыгыз турында сөйләсәгез иде. Белүебезчә, сезнең ата-бабаларыгыз укымышлы, югары белемле кешеләр булган, китап күчерү эше белән дә шөгыльләнгән. Ул китапларның күп өлеше яндырылган, безгә килеп җитә алмаган. Шулай да халыкта бик аз өлеше генә сакланып калган. Борынгы кульязмалар турында, аларны күчереп язучылар турында беләсебез килә.*

– Кайвакыт бер бәләкәй генә вакыйга бер зур эшнең башы булып чыга. Монда да шулай булды. Без, өч туган, әти йортына кайтып төштек. Әтиебез Әмирҗан (1891–1972) иске мал сараен сүттереп, бер сыерлык кына сарай салырга кушты, олыгайган иде инде. Аннан шуны да әйтергә кирәк, бу – Хрущев заманы, халык кулында малны бетерү – партиябезнең максаты иде.

Сарайның салам башын сүтәбез, искереп, тузып беткән саламны аска очырабыз. Бервакыт салам арасыннан бер кәгазь төргәге очып төшкән кебек булды. Арабыздан кайсыбыздыр аны актарып алды да: «Бу бит китап, карагыз әле!», – дип, гаҗәпсенү катыш тавыш белән безгә эндәште. «Китап» дигән сүзне ишетүгә, читтәрәк торган әтиебез тиз генә килеп, китапны кулына алды. Шул мәлдә аның йөзендәге сагыш тулы куанычны сөйләп аңлату мөмкин түгел иде. Бик кыйммәтле әйберен югалтып, озак еллардан соң тапканга, әтинең күзләре шатлык яшьләре белән тулды. Әйләндереп карый-карый, ул китапны күкрәгенә кысты. Зур кызыксыну белән без аның янына җыелдык. Китапның тышлыгы юк иде. Читләре дүрт яклап та черегән, шулай да урта өлешенең саргайган битләре сакланган иде әле. Салам арасыннан килеп чыккан китап бездә дә зур кызыксыну уятты. «Нинди китап?» – дип сорагач, әти: «Балалар авыруы турында китап», – диде. Аннары: «Әтидән мирас булып калган китаплардан бердәнбер китап бу. Ә бит алар бик күп иде. Нindиләре генә юк иде... И-и заман... Калганнарын саклый алмадым, үз кулларым белән яндырдым», – дип, кәефсезләнеп өйгә кереп китте.

Китап яндыру турыда ишеткәнем бар иде. Совет хакимияте урнашкач, ул илебездә яшәгән төрки халыкларның алфавитын

үзгәртүгә керешә. Башта латинга, аннан кириллицага күчерү сәясәте башлана. Соңыннан, язусыз халыкларга язу бирдек, дип, халыкның аңына сеңдерергә тырышалар. Бу сәясәткә каршы чыкканнар җәзага тартыла. Галимҗан Ибраһимов нәкъ шул сәясәтнең корбаны була. Безнең татар, башкорт халкы яңадан бер революция кичерә. Хакимиятнең төп максаты рус телендә генә укытып, милләтләрне урыслаштыру була. Бу процесс әле дә бара. Гасырлар буе җыелып килгән тарихи мирас юкка чыгарыла. Уйлап карагыз әле: инглизнең, французның яки урысның язуын кинәт кенә бетереп, кытай яки гарәп хәрефендә язуны таләп итсәләр, нәрсә булыр иде? Күз алдына китерү дә мөмкин түгел. Шулай итеп, татар гаиләсендә гарәп хәрефе белән язылган китап куркыныч нәрсәгә әйләнә. Бигрәк тә зыялылар өендә. Безнең әтиебез укытучы була. Аңа да шул авыр заманда җиде баланы калдырып, Себер китеп бару куркынычы яный. Җитмәсә, әтиебез – мулла баласы. Шуңа күрә өч кич буе мунча ягып, китап яндырган. Ул китапларның хөкүмәткә бер зыяны да булмаган, әмма аны кем тикшереп тора?! Китаплар мирас булып әтиебезгә аның әтисеннән – Сәүбән мулладан калган. Сәүбән бабай (?–1921) – Әхмәтҗан Рәмиевнең дүрт улының кечесе, 1921 елда холера авыруыннан үлгән, Тәтер-Арслан авылы зиратына җирләнгән.

Әхмәтҗан Рәмиев Сәүбәнне бер җиргә дә җибәрмичә үзе укыткан, муллалык вазифасын башкарырга һәм дарулар ясап, кешеләрне дәваларга да өйрәткән. Аны белгән картлар бик мактап, зурлап сөйлиләр иде. Кеше дәваларга һәвәс булуын сизеп, әтисе китапларын шушы Сәүбән улына калдырган. Әхмәтҗан бабайның алты кызы да булган, икесенең исемен беләм, башкаларыныкын хәтерләмим. Берсе Рәхимә, икенчесе Зөбәйдә – каһарманыбыз Муса Җәлилнең картәнисе, Сәүбәннең бертуган апасы Зөбәйдәнең кызы Рәхимә, әтием Әмирҗанның икенче буын апасы Рәхимәнең улы Муса Җәлил – минем өченче буын абыем.

*– Дамир Гарифуллинның «Җәлилнең нәсел агачы»*[1] *исемле мәкаләсендә Муса Җәлилнең әнисе мулла нәселеннән булуына иша-*

---

[1] *Гарифуллин Д.* Җәлилнең нәсел агачы // Мәдәни җомга. 2006. 1 сент. № 34. Б. 11

*рә ясала. Ләкин монда әле иң әһәмиятле фактлар күрсәтелми. Шуңа күрә, Нил абый, сезнең истәлекләр әдәбиятчылар, тарихчыларда кызыксыну уятмый калмас. Чөнки Рәмиевләр нәселе – ул татарның алтын баганасы. Моңа кадәр Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Акмулланың бер тамырдан икәнен белсәк, баксаң, Муса Җәлил дә шул сәйләннең бер мәрҗәне булып чыга бит.*

– Әйе, Зөбәйдә белән Сәүбәннең бертуганы Рәхимә Башкортстанның Айдарәле авылында яшәгән, Габдрахман белән Хәсән исемле уллары булган. Габдрахманның онык кызы – Нәсимә Әхмәтова. Ул да шигырьләр яза, гомере буе укытучы булып эшләде, бүгенге көндә лаеклы ялда, Стәрлебаш районының Карагыш авылында яши.

*– Зөбәйдә белән Сәүбәннең этисе Әхмәтҗан турында да бераз ачыклык кертеп үтсәгез иде? Ялгышмасам, Әхмәтҗан бабай Сәлим Ахунның улы булып чыга түгелме соң?*

– Шулай була. Башта мин аның фамилиясенең язылышына ачыклык кертеп китим. Әхмәтҗан бабайның этисе Сәлим (Сәлим ахун) дә ике төрле язылып йөртелгән. Сәлим ахун Стәрлетамак шәһәрендә яшәгән, аңа соңрак тукталырбыз. Әтиебез Әмирҗан бабайның 111 яшькә җитеп мәрхүм булуы турында сөйли иде. Кабер ташында аның туган елы бирелми, вафат булган елы итеп 1892 ел күрсәтелә. Минем фаразлавым буенча, монда вафат булган елы түгел, ә ташның язылу һәм куелу датасы күрсәтелгән. Чөнки Әхмәтҗан бабай вафат булган 1891 елны оныгы – минем эти Әмирҗан Сәүбән улы туган. Әхмәтҗан бабай 1780 елда Эстәрлетамакта дөньяга килә. Бу ел шунысы белән истәлекле – ул Русиядә Ислам дине рәсми кабул ителгәч, Стәрлетамакта тәүге мәчет салынып ачылган ел. Мәчет ачылганчыга кадәр халык аерым бер өйдә гыйбадәт кыла. Архив документлары буенча, Әхмәтҗанның этисе Сәлим мулла шул тантаналы җыелышта ахун итеп сайлана. Улы Әхмәтҗан бик зирәк бала булып үсә, улын сәүдәгәр итү максаты белән кибет ачып, аны сатучы итеп куя. Әмма Әхмәтҗанның хәлфәсе шәкертен котырта: «Бу башың белән шырпы, тоз сатып торма, укырга чыгып кит», – ди. Һәм Әхмәтҗан этисенең ризалыгыннан башка Кырымга бара. Аннары

Сарытауда[1] бер мишәр егете белән Төркиягә чыгарга булалар. Әмма чит илгә татарларга чыгарга рөхсәт бирелми. Әхмәтҗан үзбәк киеме киеп, урысча белмәгән кешегә салышып, паспорт биргән җиргә барып: «Пашпорт, пашпорт», – дип, ишектән кусалар тәрәзәгә, тәрәзәдән кусалар, ишеккә барып теңкәләрен корыта. Ниһаять, берничә көн инәлеп йөргәннән соң, ул максатына ирешә – ике паспорт ала. Соңыннан корабка утырып, Мисырга, Каһирә шәһәренә барып җитә. Дөрелфәнүнгә (Әл-Әзһәр университеты) табиблык бүлегенә укырга керәләр. Дүртенче, бишенче уку елларында ук китапханәдән медицина китапларын алып, аларны татар теленә тәрҗемә итеп, күчереп яза башлый. Моның өчен, билгеле, акча кирәк була һәм ул җирле байларның балаларын өйләренә барып укытырга яллана. Биш ел укыганнан соң, тагы ике ел китаплар күчерә, балалар укыта, кайтырга акча эшли. Шуннан күтәрә алган кадәр китаплар төяп, Багдад шәһәре аша туган якларына юл ала. Багдад аша кайтуының сәбәбе шунда: архив белән танышмакчы була. Чөнки әтисе сөйләве буенча, аның борынгы бабасы Багдадтан Болгарга ислам динен пропагандалау өчен җибәрелгән делегация составына кергән. Тикшерә торгач, Әхмәтҗан бабасын исеме буенча эзләп таба, чыннан да ул Болгарга ислам динен таратырга килүчеләр арасында була. Башкалар белән Әхмәтҗан бабабыз кызыксынмаган, күрәсең, аңа бабасының исемен генә белү кирәк булган.

*– Тарихта мәгълүм булуынча, Болгарга бер генә делегация килгән бит.*

– Әйе, Алмыш хан соравы буенча, 922 елны Ибн Фадлан җитәкчелегендәге делегация ул. Алар бер төркем тирән гыйлемле белгечләр-мөһәндисләр булган. Архивта мөһәндисләр – төрекләр, диелгән. Моны инде дөрес аңларга кирәк, төрек дип ул вакытта барча төрки халыкларны атап йөреткәннәр. Болары болгар, хәзәр булганнардыр дип уйласак дөресрәк булыр, чөнки җирле халыкның телен белү аларга шарт итеп куелган. 922 ел-

[1] Сарытау – Саратов шәһәре.

дан алып 1227 елга хәтле (Батый хан килгәнчегә кадәр) булган бабаларыбызның (Миргалидән башка) исемлеге юк.

*– «Шәхесләребез» сериясендә чыккан «Бертуган Рәмиевләр» китабында Рәмиевләр шәҗәрәсе Миргалидән башлана. Бу Ризаэддин бине Фәхретдин тарафыннан бәян ителгән. Язучы Мөһәммәт Мәһдиевнең 1989 елгы «Казан утлары» журналының соңгы санында басылган «Рәмиевләр нәселеннән берәү» дигән мәкаләсендә дә Исмәгыйль Рәмиев (1895–1969, Сәлим ахунның дүртенче буын оныгы) әдипкә үз кулы белән язып биргән шәҗәрәне урнаштырган. Шулай ук Рәмиевләр нәселен өйрәнүгә зур өлеш керткән Лирон абый Хәмидуллинның да бик күп мәкаләләре дөнья күрде. Нил ага, сез дә бик зур горурлану хисләре белән буыннарыгызны барлыйсыз, өзелеп калган җепне ялгау теләге белән янасыз. Ата-бабаларыгыздан сакланып калган шәҗәрә бармы?*

– Сәүбән картәтиебез этидән яздырып калдырырга өлгермәгән: революция еллары һәм 1921 елгы ачлык, җитмәсә ваба эпидемиясе халкыбызны кыйраткан. Картәтием Сәүбән һәм картәнием Сәрбиямал ике көн эчендә яткан да үлгән. Әмма бу исемлек булган, ул легенда түгел, бәлки берәр нәселдәшебездә сакланадыр, бәлки сезнең ярдәм белән килеп тә чыгар. Бу югалган исемнәрнең бер кешесе – Миргали мулла 1227 елны Батый хан килгәндә, (Риза Фәхретдин язганча) Зәй елгасы буенда яшәгән, хәзерге Татарстанның Әлмәт районы Тайсуган авылы җирләрендә.

*– Миргали, Батый хан дәвере хакында ниләр әйтер идегез?*

– 1222 елны Чыңгыз хан Урта Азиядән көнбатышка зур һөҗүм алдыннан разведка җибәрә. 20 мең кешедән торган гаскәр Кавказ аръягыннан Грузиягә кадәр бара, тарихчы Рахманалиев «Империя тюрков и Великая культура» дигән китабында язганча, алар гаскәрне фураж, халык белән тулыландырып торырлык җирләрне картада күрсәтеп кайтырга тиеш булалар. Грузия гаскәрен җиңәләр, әмма Кавказның төньягына Азәрбайҗан, Дагстан аша чыгалар, кыпчакларны һәм аланнарны тар-мар итәләр. Хәзерге Украинаның көньягында кышлыйлар. Язын кайтып китәләр. Урыс кенәзе Мстислав Удатныйның бик зур гаскәрен Калка елгасы

янында җиңәләр. Чыңгыз ханнан 10 мең гаскәр белән Тахучар дигән гаскәр башлыгы килә. Ул Чыңгыз ханнан илгә кайтырга кушкан хат китерә. Шунда алар 30 мең гаскәр белән Болгарга һөҗүм итеп, хәзергечә әйтсәк, «разведка боем» ясарга булалар. Чыңгыз ханның өч якын гаскәр башлыклары: Субүтай, Тохучар, өченчесе урысча «Джебе» дип язылa, тәрҗемәсе – «стрела», «ук» дип бирелә. Бу кеше турында бер-ике сүз әйтми булмый, чөнки аның Болгар сәяхәтенә бәйле урыны бар. Чыннан да аның исеме Ук түгел – Җәя. Бу Җәя найман дигән бер төрки милләтенең хан улы була. Чыңгыз хан басып алырга килгәч, алар бик нык каршы тора, җәядән Чыңгызның атын атып үтерә. Бу сугыш җиңүсез тукталып тора һәм найманнар Чыңгыз ханның көчен аңлап, аңа кушыла. Чыңгыз хан бу яшь егетне, ягъни Җәяне 10 меңлек гаскәр башлыгы итеп куя һәм үзенең иң яраткан кече улы Тулыйны сугышка өйрәтергә аңа тапшыра. Үзләренә кушылган илгә Чыңгыз хан да, Батый да зыян китермәгән. Русия ул заманда ике зур кенәзлектән тора, Владимир һәм Киев. Владимир Батый ханга 4 көндә, Киев 5 көндә бирелгән. Кенәзләр илләрен, халыкларын саклап алып калган, ә безнең болгар ханнары, 1239 елга хәтле сугышып, илләрен харап иткән. Рим католикларының Батый хан янындагы илчесе Плано Карпини язып калдыруынча, 1239 елны Болгар җиңелеп бетте дигән, ә ул вакытта Батый ханның гаскәре ярты Европаны алган була.

– Бу сугышның башлануына каршы кешеләр дә булган бит. Шуларның берсе – тарихыбызда мәгълүм шәхес Миргали мулла. Аның нәселе турында ниләр беләсез?

– Ул үзенең улы Ихсанны хәрби юлга бастырган. Ихсанның улы Рәми морза булып китә. Миргали мулла кыпчак морзалары белән кодалашып һәм аның нәселе 6–7 буын морзалар (генерал) булган. Менә аларның исемнәре: Рәмиевнең улы Тимери, Сөләйман, Колай, Түләй, Кабкай, Урман, Рәхимкол, Сәлим, Габделкәрим, Мөхәммәтҗан. Исемнәре кыпчак, башкорт исемнәренә охшаган, күрәсең, әнкә ягы алардан булып, улларына исемне кыпчак картәтиләре кушкандыр. Тимери морза дигәне Мәскәү кенәзе Иван III янында хезмәттә була. Н. Загоскинның китабында

тылмач диелгән. Бәлки, алай гына булмагандыр, ни дисәң дә Алтын Урда морзасы бит. Әмма ул хезмәт иткән җирендә хөрмәтле булган, аны зурлап Митрий Рамиев дип йөрткәннәр. Безнең Рамиев, Ремеев фамилиясе шул заманнан килә. Ислам дине тыелган заманда Тимеринең Сөләйман, Рәхимколларга зыяны тимәгән. Әби патша, мөселман халкын Емельян Пугачевлардан аерып алу өчен, ислам диненә ирек бирергә була, тәүге «эксперименталь» мулла итеп шушы Рәхимколның улы Сәлим Рәмиевне куярга карар чыгара. Стәрлетамак, Уфа җирләрендә мөселман диненә ирек бирелүнең тагын бер сәбәбе була. Русия патшалыгы казакъ җиренә ныклап урнашырга һәм Урта Азиягә керергә максат куя. Бер яктан, корал көче белән, икенче яктан, җирле халыкның үз дине белән империяне киңәйтү күздә тотыла. Шуңа күрә хөкүмәт ислам диненә күтәрелеп китәргә ирек бирә. Бу дәвер Русия өчен дә, ислам дине өчен дә, халкыбыз өчен дә бер эпоха булып тора. Бер яктан, хөкүмәт динне үзенә корал итеп файдаланырга тырыша, икенче яктан, мөселманнарның югары аңлы дәрәҗәле кешеләре Рәмиевләр, Нагаевлар, Г. Тукайның бабалары, Муса Җәлилнең картәтисе ягыннан абзалары, Госмановлар, Хөсәеновлар, Тукаевлар һәм башкалар бу хәлләрдән файдаланып, үз халкының аңын, гыйлемен, байлыгын үстереп калырга тели һәм зур уңышларга ирешә. Мисал өчен, шуны гына әйтергә була: революциягә кадәрге статистика буенча Русиядә мануфактура сәүдәсенең 50 проценты татарлар кулында була.

– *Югары да телгә алынган Хөсәеновларга карата фикерегез нинди?*

– Өч бертуган Хөсәеновлар 1914 елны сугыш башлангач: «Оренбург төбәгеннән киткән гаскәрне тәэмин итеп җибәрүне үз өстебезгә алабыз», – дип, патша Николай II гә мөрәҗәгать итә. Рәмиевләр хөкүмәткә елына 5 тонна алтын һәм мәдрәсәләр өчен 10 мең сум акча бирә. Илебездә күпләп мәчет-мәдрәсәләр калкып чыга. Академик Әбрар Кәримуллин язганча, һәр шәһәрдә гәзит-журналлар нәшер ителә, басмаларның күп булуы укучыларның күплеге белән аңлатыла. В.И. Ленинның V томындагы Бухаринга язган хатында: «Казан татарларының ир һәм кыз балаларының

мәдрәсәләре урысларның приходская школаларыннан 30 мәртәбә артык», – дигән сүзләр бар.

*– Нил абый, халкыбызның революциягә кадәр нинди уңышларга ирешүен бәйнә-бәйнә сөйләп бирдегез.Сәлим ахун шушы алгарышны тәэмин итү өчен көч салган кешеләрнең тәүгеләреннән берсе булып чыга түгелме?*

– Сәлим ахун Рәмиевне телгә алмый мөмкин түгел. Артык та тырышып куйган булса кирәк, 1807 елны ул эшеннән дә алына. Архивта сакланган документларның берсендә: «По прошению тептярского муллы Бикбулата Биккинина», – диелгән. Башка бер сүз дә юк. Ләкин архив материалыннан күренгәнчә, соңыннан аның оныгы Бәхтегәрәй Габделкәрим улы Ремеев беренче мәхәлләдә ахун булып торган, аның бертуганы Ибраһим азанчы булган. Димәк, Сәлим ахунның бер улы Габделкәрим булып чыга. Безнең әтиебез сөйләгәнчә, Әхмәтҗан бабабыз Төркиягә чыгып киткәч, Сәлим бабай кибет эшенә Габделкәримне куя, аның улы Мөхәммәтсадыйк Җиргәндә сәүдә итеп, Урал аръягында ташландык приискалары белән җир сатып ала. Аннан алтын чыгаралар, Мөхәммәдсадыйкның уллары Мөхәммәтшакир һәм Мөхәммәтзакир бу эшне югары дәрәҗәгә җиткерә. Әтинең сөйләве дөрес булса, Мөхәммәтзакир (Дәрдемәнд) – Муса Җәлилнең өченче буын абзасы. Ә Риза Фәхретдин язуынча, Габделкәрим – Сәлимнең энесе Исмәгыйльнең улы. Шулай булгач, Дәрдемәнд Мусаның дүртенче буын абзасы килеп чыга. Моның өчен Сәлимнең дә, Исмәгыйльнең дә Габделкәрим дигән уллары булу кирәк була. Алай булды микән? Инде Р. Фәхретдин кебек олуг гыйлем ияләре белән бәхәскә керергә куркам. Ничек булса да, кан белән дә, җан белән дә туганнар, сыйфатлары, максатлары бер. Әгәр Муса Җәлил Дәрдемәнд урынында булса, ул да алтын байлыгын халкына сарыф итәр иде, җанын да сарыф иткән бит. Дәрдемәнд Муса Җәлил урынында булса, ул да милләтен дөньяга танытыр иде. Хәер, шулай иткән дә инде, шул кадәр байлыгы белән читкә чыгып китсә дә булыр иде бит, юк, китмәгән, халкы ни күргән, ул да шуны күргән, фәкыйрьлектә, бөлгенлектә үлгән. Нәрсә буласын алдан белгән һәм язып та калдырган:

Җитәр инде, Дәрдемәнд,
сүзне озайтма,
Каткан, туңган күңелләргә боз атма.
Динең өчен булсын телең тозаклы,
Йөз аклыгың өчен булсын
авызың йозаклы.

Дәрдемәнднең абыйсы Шакирның кызы Кәмилә ире Садри Максуди белән читкә чыгып китә, кызы Адиләне Париждагы иң борынгы һәм атаклы Сорбонна университетында укыта. Адилә дипломат, зур галимә, Төркиянең Италиядәге илчесе булып эшли. Рим шәһәренә нигез салган этрускларның «турсак» дип аталган төрки кавемнән икәнлеген тикшереп исбат итә. Үзе инде вафат, ике кызы – Гөлнур һәм Гөньюл Төркиядә яши.

*– Татар җәмгыятенең халәтен, бигрәк тә XIX–XX гасырлардагы яңарышын, милли үсеш тарихын алганда да, аны дистәләгән галимнәр, мәгърифәтчеләр, руханилар нәселенең иҗади эшчәнлеге җирлегендә күз алдына китерергә мөмкин. Безгә эзләнергә, уйланырга тагын бер зур этәргеч бирүегез өчен зур рәхмәт!*

# ХӘЛЕКӘЙ АВЫЛЫ ТАРИХЫНА КАГЫЛЫШЛЫ МӘГЪЛҮМАТЛАР

*Венер Усманов*

Бу язмада Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районы Хәлекәй авылының тарихына кагылышлы мәгълүматлар, төгәлрәк әйткәндә, җанисәп язмалары һәм метрикә дәфтәрләреннән күчермәләр, биредә яшәүче аерым бер гаиләләрнең нәсел шәҗәрәләре (шул исәптән авылга нигез салган Хәлекәй бабай шәҗәрәсе), мәчетләр тарихына, аларда төрле чорларда хезмәт куйган имам-мөдәррисләренә кагылышлы хәбәрләр һәм сакланып калган кайбер борынгы ташъязмаларның текстлары укучылар игътибарына тәкъдим ителә[1].

## Беренче мишәр кантонының бишенче йортына караган Хәлекәй авылы кешеләренең исемлеге

1. Указлы имам **Габдерәфыйк** (1786–1850) бине Габдеррәшид бине Муса (Мусиннар)

1.1. Гатаулла (1823–?) бине Габдеррәфыйк

1.2. Гыйсмәтулла (1828–?) бине Габдеррәфыйк

1.2.1. Гыйззәтулла бине Гыйсмәтулла

1.2.2. Гайшә (1880–?) бинте Гыйсмәтулла

[1] Тулырак мәгълүматны түбәндәге чыганактан карарга мөмкин: *Усманов В.М.* Исторические памятники. 11-ая книга (д. Халикеево. Родословные древа). Стерлитамак, 2015. 30 с.

1.3. Гыйзетдин (1841–?) бине Габдеррәфыйк

1.4. Хафизетдин (1843–?) бине Габдеррәфыйк

1.5. Гайнетдин (1848–1898) бине Габдеррәфыйк

1.6. Фазлыйәхмәд (1849–?) бине Габдеррәфыйк

2. Указлы имам **Лотфулла** (1820–?) бине Габдеррәфыйк (Габдрафиков) бине Габдеррәшид бине Муса

3. Указлы имам **Сагман** (Сәһман – ?) Буляков, 1803–?

Беренче хатыныннан:

3.1. Әхмәдгали (1842–?) бине Сагман

4. Зауряд сотник **Габделмәгъҗан** Гобәйдуллин (1798–?) бине азанчы Гобәйдулла (1773–1831) бине Габделҗәмил

4.1. Гомәр (1827–?) бине Габделмәгъҗан

4.2. Фәхретдин (1836–?) бине Габделмәгъҗан

Оныгы:

4. Гыйләҗетдин Гобәйдуллин (1828–?).

5. «Отставной зауряд хорунжий» **Мөхәммәдьяр** (1793–?) бине Искәндәр Илмәтов

Беренче хатыны Җомгабикә («Зюмабика») Курамшина (1794–?)

Икенче хатыны – Хафиза Гобәйдуллина (1800–?)

5.1. Шәмсенәһәр, Хафиза кызы (1837–?)

5.2. Садретдин (1828–?) бине Мөхәммәдьяр

Хатыны – Хөснежиһан Сәйфетдинова, 1830–?

5.3. Хабибетдин (1834–1840) бине Мөхәммәдьяр

5.4. Сахибетдин (1841–?) бине Мөхәммәдьяр

6. Отставной урядник **Әсфәндияр** (1795–?) бине Искәндәр бине Илмәт

7. Урядник **Габделвахид** (1795–?) бине Хәсән бине Хәлекәй (Халикеев)

Беренче хатыннан:

7.1. Габдессәлам (1828–?) бине Габделвахид

7.2. Габделмәннаф (1830–?) бине Габделвахид

7.3. Габделхәннан (1849–?) бине Габделвахид

Икенче хатыныннан:

7.1. Габделфәттах (1850–?) бине Габделвахид

7-А. **Габделгазиз** (1783–1845) бине Хәсән бине Хәлекәй

8. **Сәлимҗан** (1811–?) бине Байганә бине Мулласәлим бине Хәлекәй[1]

Беренче хатыныннан:

8.1. Әхмәдҗан (1832–?) бине Сәлимҗан

8.2. Искәндәр (1836–?) бине Сәлимҗан

8.3. Гыйрфан (1842–?) бине Сәлимҗан

Сахибҗәмал бинте Байгана бине Мулласәлим бине Хәлекәй балалары:

8-А.1. Сәлимҗәгъфәр (1827–1847) бине Нариман

8-А.2. Сөләйман (1829–185) бине Нариман

9. **Заһидулла** Исламмуратов (1802–?) бине Сәйфулла (1769–1832) бине Исламморад

Беренче хатыныннан:

9.1. Мифтахетдин (1828–1850) бине Заһидулла

9.1.1. Шәмсетдин (1850–1850) бине Мифтахетдин

Икенче хатыныннан:

9.1. Җәмалетдин (1830–?) бине Заһидулла

9.2. Фәхретдин (1836–?) бине Заһидулла

10. **Фәрехшад** (1815–?) бине Ходайбирде бине Ибраһим бине Хәлекәй

10.1. Шаһиморад (1844–?) бине Фәрехшад;

10.2. Шаһиәхмәд (1848–?) бине Фәрехшад;

10.2.1. Нуриәхмәд (1894–1895) бине Шаһиәхмәд;

10.3. Нурмөхәммәд (1850–?) бине Фәрехшад.

10.4. Мирсаяф (1820–1846) бине Ходайбирде.

11. **Сәгыдетдин** (1803–?) бине Әсадулла (1780–?) бине Рафик (?–1813) бине Мәсгуд бине Хәлекәй

Беренче хатыныннан:

11.1. Әхмәдулла (1823–?) бине Сәгыдетдин

11.2. Фәхретдин (1833–?) бине Сәгыдетдин

11.3. Хисаметдин (1835–?) бине Сәгыдетдин

11.4. Гыймадетдин (1849–?) бине Сәгыдетдин

---

[1] Хәлекәй (Хәлилулла) морзалар нәселеннән булган имеш.

11-А.**Мифтахетдин** (1822–?) бине Әсадулла (1780–?) бине Рәфыйк бине Мәсгуд бине Хәлекәй

11-А.1. Галәветдин (1848–1898) бине Мифтахетдин

12. **Әхмәджан (1811**–?) бине Монасыйб бине (Рәфыйк Хәлекәев – ?)

12.1. Әхмәдләтыйф (1835–?) бине Әхмәджан

12.2. Әхмәдгали (1848–?) бине Әхмәджан

12-А. **Мөхәммәджан** (1800–1838) бине Монасыйб

13. **Камалетдин** бине Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим бине Исламморад (1818–?)

13-А. Баһаветдин бине Мөхәммәдкәрим

13-А.1. Төхфәтулла (1849–?) бине Баһаветдин

14. **Шәрәфетдин** (1814–?) бине Мөхәммәдкәрим (1790–1831) бине Мөхәммәдрәхим (1762–?) бине Исламморад

14.1. Зыятдин (1840–?) бине Шәрәфетдин

15. **Тимерҗан** (1808–?) бине Сәйфелмөлек (?–1812)

15.1. Мөхәммәджан (1841–?) бине Тимерҗан

15.2. Әхмәдулла (1849–?) бине Тимерҗан

16. **Ишмөхәммәд** (1809–?) бине Ходайбирде

16.1. Җиһангир (1827–1834) бине Ишмөхәммәд

16.2. Солтангир (1837–?) бине Ишмөхәммәд

16.3. Арыслангир (1841–?) бине Ишмөхәммәд

16-А. Ходайдат (1804–1834) бине Ходайбирде

16-А.1. Габделкаһир (1833–1835) бине Ходайдат

17. **Хәмидулла** (1810–?) бине Сәйфулла (1769–1832) бине Исламморад

17.1. Лотфулла (1849–?) бине Хәмидулла

17.2. Гыймадетдин (1829–?) бине Сәйфулла

17.3. Госаметдин (1832–1835) бине Сәйфулла

18. **Салих** (1799–?) бине Рәфыйк бине Хәлиулла Хәлекәев

18.1. Шәрәфетдин Салихов (1822–?) бине Салих

18.2. Арыслангали (1841–?) бине Салих

19. **Мөхәммәдшәриф** (1810–1848) бине Рәфыйк

19.1. Госаметдин Шәрипов (1836–?) бине Мөхәммәдшәриф

19.2. Сахибетдин Шәрипов (1842–?) бине Мөхәммәдшәриф

20. **Җәләлетдин** Габделмәгъҗанов (1817–?) бине Габделмахьян (1798–?) бине Гобәйдулла (азанчы) бине Габделҗәмил (Җәләлетдин – мәзин (азанчы), Габделмәгъҗан – зауряд сотник)

20.1. Фазлетдин (1847–?) бине Җәләлетдин

20.2. Әхмәдшаһ (1849–?) бине Җәләлетдин

21. **Сиражетдин** (1821–?) бине Гобәйдулла (1769–1831) бине Габделҗәлил

22. **Габдрахман** (1814–?) бине Габдулла (1781–?) бине Байгана бине Мулласәлим бине Хәлекәй

23. **Ахунҗан** (1815–?) бине Монасыйб

23.1. Гыйзетдин (1843–?) бине Ахунҗан

24. **Хөсәен** (1772–1839) бине Рәфыйк бине Мәсгуд

24.1. Хисаметдин (1799–?) бине Хөсәен бине Рәфыйк

  24.1.1. Мөхәммәдхәсән (1821–?) бине Хисаметдин

24.1.1. Гыймадетдин (1824–?) бине Хисаметдин

25. **Ибраһим** (1801–?) бине («указной мулла» Габбас (1747–1826) бине Хәсән

Беренче хатынынннан:

25.1. Шаһимәрдан (1834–?) бине Ибраһим

26. **Фәтхулла** (1785–1836) бине Габбас (1751–?) бине Хәсән

Аның балалары:

26.1. Шәйхелислам (1832–1835) бине Фәтхулла

26.2. Садрислам (1833–?) бине Фәтхулла

27. **Исхак** (1799–1845) бине Габбас бине Хәсән

27.1. Хәбибулла (1829–?) бине Исхак

27.2. Гайфулла (1839–?) бине Исхак

28. **Ходайбирде** (1799–1848) бине Ибраһим бине Хәлекәй. Тамгасы 

28.1. Әюб (1823–?) бине Ходайбирде

  28.1.1. Шаһвәли (1843–?) бине Әюб

  28.1.2. Шаһгали

28.2. Таһир (1829–?) бине Ходайбирде

28.3. Шаһингәрәй (1839–?) бине Ходайбирде

29. **Фәйрүз** Илмәтов (1814–?) бине (зауряд хорунжий) Мөхәммәдьяр (1793–?) бине Искәндәр бине Мәсгуд бине Илмәт

29.1. Гыйрфан (1837–?) бине Фәйрүз

30. **Әбелхәсән** (1823–?) бине Габдессаттар бине Искәндәр бине Мәсгуд бине Илмәт

30-А. Фәхрислам (1829–?) бине Габдессаттар бине Искәндәр

31. **Мөслим** (1789–1850) бине Мөхсин (1763–?) бине Мәхмүд

31.1. Сәмигулла (1813–?) бине Мөслим

31.1.1. Галиулла (1832–?) бине Сәмигулла

31.2. Шаһимәрдан (1820–1850) бине Мөслим

32. **Мөхәммәдҗан** (1821–?) бине Габденнасыйр (1870–1832) бине Габделмәннаф

32.1. Мөхәммәдзариф (1839–?) бине Мөхәммәдҗан

32-А. Мөхәммәдгариф (1832–1835) бине Габденнасыйр

33. **Габделвахид (1814**–?) бине Габделгаффар (1784–?) бине Габделмәннаф

33.1. Габдессалих (1841–?) бине Габделвахид

33.2. Габделҗәмал (1848–?) бине Габделвахид

33.3. Хәбибулла бине Габделвахид

33.3.1. Мәгъфия бинте Хәбибулла,1894–?

33-А. Габделләтыйф (1821–?) бине Габделгаффар

34. **Салих** (1788–1848) бине Габделмәннаф

34.1. Вәлиулла (1826–?) бине Салих

34.1.1. Нәбиулла (1839–?) бине Вәлиулла

34.2. Хәбибулла (1828–?) бине Салих

34.3. Хәлилулла бине Салих

34.3.1. Хуҗагали (1834–?) бине Хәлилулла

35. **Мөхәммәдҗан** (1815–?) бине (зауряд сотник) Мозаффар (1783–?) бине Сәйфелмөлек бине Юлдаш.

35.1. Мөхәммәдшәфигъ (1843–?) бине Мөхәммәдҗан

35.2. Корбангали (1849–?) бине Мөхәммәдҗан

36. **Хаммат** Бакиров (1813–?) бине Сәйфелмөлеков (1754–1818) бине Әбү Бәкер

36.1. Шәрәфетдин (1834–?) бине Хәммад (Хаммат)

36.2. Гайнетдин (1836–?) бине Хәммад (Хаммат)

36.3. Салихетдин (1846–?) бине Хәммад (Хаммат)

Бертуган карендәшенең улы – Сәйфетдин (1832–?) бине Сәгадәтдинов (1797–1832) бине Сәйфелмөлек бине Бакир

37. **Мөхәммәдвәли** (1813–?) бине Мөхәммәдгали (1779–?) бине Йосыф Хәлекәев

37.1. Шаһингәрәй (1841–?) бине Мөхәммәдвәли

37.2. Шаһвәли (1849–?) бине Мөхәммәдвәли

38. **Хөснетдин** (1797–?) бине Сәгыйть

39. **Фәхретдин** (1809–1848) бине Габделхәким, Якупов – ?

39.1. Биктимер (1831–?) бине Фәхретдин

Бертуганының улы: Гыйлаҗетдин (1822–?) бине Хәйретдин (1798–1823) бине Габделхәким бине Ягъкуб

39-А.1. Хисаметдин (1848–?) бине Гыйлаҗетдин

40. **Зөбәир** (1813–?) бине Гозәир (1787–?) бине Зөлкарнәй бине Сәгыйть

40.1. Фазлетдин (1837–?) бине Зөбәир

40.2. Әмир (1844–?) бине Зөбәир

40.3. Габделкәбир (1843–?) бине Зөбәир

41. **Мәхмүд** (1807–?) бине Мәкъсуд (1771–?) бине Мәсгуд

Икенче хатыныннан:

41.1. Вәлиәхмәд (1849–?) бине Мәхмүд

42. **Зәбир** Максютов (1795–1839) бине Мәкъсуд бине Мәсгуд

42.1. Зөбәйдулла (1823–?) бине Зәбир бине Мәкъсуд (1771–?)

42.2. Гобәйдулла (1828–?) бине Зәбир

42.3. Нәзир (1832–?) бине Зәбир

43. **Галиулла** (1814–?) бине Фәйзулла (1771–1823) бине Сәидборһан

43.1. Хәйрулла (1845–?) бине Галиулла

43-А. Сафиулла (1811–1841) бине Фәйзулла

43-Б. Вәлиулла (1822–1848) бине Фәйзулла

44. **Хәбибулла** (1803–?) бине Фәйзулла (1771–?) бине Сәидборһан

44.1. Тимергали (1836–?) бине Хәбибулла

44.2. Нургали (1849–?) бине Хәбибулла

45. **Габделхәлим** (1815–?) бине (юртовой есаул) Габделхәким бине Ягъкуб

Беренче хатынынннан:

45.1. Габдеррәхим (1844–?) бине Габделхәлим

46. **Габделмөэмин** (1783–1848) Яфиев. Тамгасы: 

46.1. Тимербулат (1834–?) бине Габделмөэмин

46.1.1. Гатифә (1868–?) бине Тимербулат

46.2. Тимергали (1838–?) бине Габделмөэмин

46.3. Габделхәким (1848–?) бине Габделмөэмин

46-А. Бәхтияр (1831–?) бине Галиәкбәр бине Гаффан

47. **Рамазан** (1805–1841) бине Миңлебай бине Әмирхан

47-А. Исмәгыйль бине Миңлебай бине Әмирхан, 1810–?

48. **Ибраһим** (1784–1848) бине Сәгыйть

48.1. Исхак бине Ибраһим, 1823–?

48.1.1. Яхъя бине Исхак

48.1.1.1. Миңлежиһан (1894–?) бине Яхъя

49. **Әсфәндияр** (1790–?) бине Сәйфелмөлек (1752–?) бине Юлдаш

49.1. Әхмәдьяр (1827–?) бине Әсфәндияр

49.2. Әхмәдшаһ (1831–?) бине Әсфәндияр

49.3. Муса (1833–1835) бине Әсфәндияр

49.4. Мөхәммәдшаһ (1835–?) бине Әсфәндияр

50. **Мохтасар** (1891–?) бине Әсфәндияр бине Сәйфелмөлек бине Юлдаш

50.1. Җиһаншаһ (1847–?) бине Мохтасар (1819–?) бине Әсфәндияр бине Сәфелмөлек бине Юлдаш

50-А. Мөхәммәдьяр (1822–?) бине Әсфәндияр бине Сәйфелмөлек бине Юлдаш

50-А.1. Муллаяр (1848–?) бине Мөхәммәдьяр

50-А.2. Мозаффар бине Мөхәммәдьяр

50-А.2.1. Хөббихуҗа (1894–?) бине Мозаффар

50-А.3. Сәид-Җәгъфәр (?–1908) бине Мөхәммәдьяр

50-А.4. Бәхтегәрәй (1862–1922) бине Мөхәммәдьяр

51. **Гозәир** (1787–?) бине Зөлкарнәй (1759–1834) бине Сәгыйть

51.1. Нәзир (1822–?) бине Гозәир

51.2. Зөбәйдулла (1829–?) бине Гозәир

51.2.1. Гыйззәтулла бине Зөбәйдулла

51.2.1. Тимербулат (1894–?) бине Гыйззәтулла

51.3. Заһидулла (1834–?) бине Гозәир

52. **Зәйнулла** (1794–1845) бине Мөхсин (1763–1820) бине Мәхмүд

Беренче хатыныннан:

52.1. Габдулла (1830–1835) бине Зәйнулла

52.2. Шәйхелислам (1832–1899) бине Зәйнулла

52.3. Хәмидулла (1817–?) бине Зәйнулла

52.4. Гобәйдулла (1838–?) бине Зәйнулла

52.5. Габдулла (1842–?) бине Зәйнулла

Икенче хатыныннан:

52.1. Газизулла (1842–?) бине Зәйнулла

53. **Зәйнулла** Курамшин (1795–?) бине Хурамшаһ

53.1. Фәйзулла (1831–?) бине Зәйнулла

Бертуган карендәшенең улы: Мөхәррәм Мөхәммәдрәхимов (1810–1844)

54. **Кәлимулла** Курамшин (1798–?) бине Хурамшаһ

54.1. Сәйфулла (1844–?) бине Кәлимулла

54.2. Хәлилулла (1846–?) бине Кәлимулла

55. **Фәтхулла** (1815–?) бине Мөхсин (1763–?) бине Мәхмүд

55.1. Лотфулла (1840–?) бине Фәтхулла

55.2. Гатаулла (1840–?) бине Фәтхулла

56. **Мифтахетдин** бине Габделхәкимов бине Ягъкуб (1800–?)

56.1. Минһаҗетдин (1833–?) бине Мифтахетдин

57. **Мөэмин** (1787–?) бине Мөхсин (1763–1820) бине Мәхмүд

57.1. Хәррас (1821–?) бине Мөэмин

57.1.1. Галяветдин (1847–?) бине Хәррас

57.2. Шаммас (1829–?) бине Мөэмин

58. **Зөлкарнәй** Сәгыйтов (1759–1834) бине Сәгыйть

58.1. Зәйнетдин (1802–?) бине Зөлкарнәй

58.1.1. Гайнетдин (1831–?) бине Зәйнетдин

58.1.2. Әхмәдетдин (1834–1834) бине Зәйнетдин

58.1.3. Зәйнигабетдин (1843–?) бине Зәйнетдин

58.2. Хисаметдин (1827–1846) бине Зөлкарнәй

59. **Халит** (1789–?) бине Ихсан (1762–?) бине Мәхмүд
59.1. Хәмидулла (1822–?) бине Халит
59.1.1. Хәйрулла (1841–?) бине Хәмидулла
59.1.2. Габдулла (1845–?) бине Хәмидулла
59.1.3. Гайфулла (1849–?) бине Хәмидулла
60. **Мозаһид** Ихсанов бине Мәхмут (1802–?)
Беренче хатыныннан:
60.1. Камалетдин (1832–?) бине Мозаһид
60.1.1. Галләметдин бине Камалетдин
60.1.1.1. Фәгыйлә (1894–?) бине Галләметдин
60.2. Җәләлетдин (1838–?) бине Мозаһид
Икенче хатыныннан:
60.3.1. Җәмалетдин (1849–?) бине Мозаһид
61. ?
62. **Хәмзә** (1777–1850) бине Мәхмүд, азанчы
62.1. Хәсән (1813–1848) бине Хәмзә
62.2. Мөхәммәдсабир (1821–?) бине Хәмзә
62.2.1. Мөхәммәдзариф (1849–?) бине Мөхәммәдсабир
62.2.2. Мөхәммәдләтыйф бине Мөхәммәдсабир
62-А. Мөхәммәдкәрим (1878–1895)
62.3. Мөхәммәдсадыйк (1827–?) бине азанчы Хәмзә
63. **Мәүдүд** (1806–?) бине Мәкъсуд (1765–?) бине Мәхмүд
63.1. Газизулла (1837–?) бине (Мәүдүд–?)
63.2. Мөхәммәдхафиз (1842–?) бине (Мәүдүд-?)
63-А. Мәсгуд (1840–?) бине Мәкъсуд
63-А.1. Мәхмүд (1842–?) бине Мәсгуд
63-Б. Госман (1815–?) бине Мәкъсуд
64. **Мөхәммәдрәхим** (1791–?) бине Җәгъфәр (Җәлиловларның туганы)
64.1. Мөхәммәджан (1840–?) бине Мөхәммәдрәхим
65. **Габделхаликъ** (1811–?) бине Габделхәким (1766–1833) бине Ягъкуб
65-А. Габделкадыйр (1828–?) бине Габделхәким
66. **Габделхаликъ** (1810–?) бине Габделхәмид бине Габделгазиз

66.1. Габделвахид (1849–?) бине Габделхаликъ

67. **Мөхәммәдәмин** (1779–1851) Яфиев

67.1. Габделмогыйн (1828–1844) бине Мөхәммәдәмин

67.2. Мөхәммәди (1833–?) бине Мөхәммәдәмин

67.3. Әхмәди (1837–?) бине Мөхәммәдәмин

67.4. Әхмәдулла (1847–?) бине Мөхәммәдәмин

68. **Сәүбән** (1811–?) бине Юлдаш (1758–?) бине Габделгазиз

68.1. Локман (1849–?) бине Сәүбән

68-А. Салман (1801–1841) бине Юлдаш

68-Б. Юлкотлы (1818–?) бине Юлдаш

69. **Рәхимкол** (1779–1850) бине Габделгазиз

69.1. Габид (1820–1846) бине Рәхимкол

69.1.1. Гобәйдулла (1845–?) бине Габид

69.2. Сабит (1825–?) бине Рәхимкол бин Габделгазиз

69.2.1. Гыйниятулла (1834–?) бине Сабит

69.3. Хәмид (1829–?) бине Рәхимкол бине Габделгазиз

70. **Каһарман** (1811–?) бине Рәхимкол (1779–1850) бине Габделгазиз

70.1. Хәйрулла (1841–?) бине Каһарман бине Габделгазиз

70-А. Ильяс (1818–1838) бине Рәхимкол бине Габделгазиз

71. **Могаттар** (1791–1848) бине Сәйфелмөлек бине Юлдаш

71.1. Мөхәммәдсадыйк (1831–1843) бине Могаттар

71.2. Габделдаян (1826–?) бине Могаттар

71.3. Габденнасыйр (1846–?) бине Могаттар

72. Зауряд сотник **Мозаффар** Юлдашев (1783–1847) бине Сәйфелмөлек бине Юлдаш

72.1. Галиәкбәр (1810–?) бине Мозаффар

72.1.1. Шаһиәкбәр (1846–?) бине Галиәкбәр

72.2. Мөхәммәдшәфыйк (1834–1838) бине Мозаффар

73. **Зәйнулла** (1790–?) бине Таһир

73-А. Зәйнетдин (1793–?) бине Таһир

73-А.1. Габделхафиз (1828–1845) бине Зәйнетдин

74) **Мөхәммәдкәрим** (1797–?) бине Әмин бине Йосыф бине Хәлекәй

74.1. Мөхәммәдхәсән (1835–?) бине Мөхәммәдкәрим

74.2. Мөхәммәдшәриф (1838–?) бине Мөхәммәдкәрим

74-А. Хәйретдин (1802–?) бине Әмин

74-Б. Хөснетдин (1812–?) бине Әмин

75. **Фәхретдин** (1809–?) бине Әмин бине Йосыф бине Хәлекәй

75.1. Фәттахетдин (1837–?) бине Фәхретдин

76. **Мөхәммәдгали** (1779–1849) бине Йосыф бине Хәлекәй

76.1. Мөхәммәдхәсән (1815–?) бине Мөхәммәдгали

76.1.1. Әхсән (1896–?) бине Мөхәммәдхәсән

77. **Габделбәшир** (1771–1847) бине Йосыф бине Хәлекәй

77.1. Насретдин (1809–1848) бине Габделбәшир

77.2. Баһаветдин (1824–?) бине Габделбәшир

77.3. Сиражетдин (1830–1898) бине Габделбәшир

78. **Гайнулла** (1783–?) бине Таһир

Бертуган кардәшнең улы: Мөхәммәдшаһ (1805–1844) бине Мөхәммәдхәнәфи (1763–1822)

78.1. Сәхәбетдин (1833–?) бине Мөхәммәдхәнәфи

79. **Хәбибнаҗар** (1796–1843) бине Юлдаш (1764–1835) бине Бакир. Тамгасы Δ

79.1. Әхмәдҗан (1823–?) бине Хәбибнаҗар

79.1.1. Һәдия бинте Әхмәдҗан (1873–?)

79.2. Гыймадетдин (1825–?) бине Хәбибнаҗар

79.3. Гайнетдин (1828–?) бине Хәбибнаҗар

79.4. Фәттахетдин (1832–1898) бине Хәбибнаҗар.

Тамгасы: 

79.5. Тәмимдар (1838–?) бине Хәбибнаҗар.

Тамгасы: 

80. **Габделбакый** Габдуллин (1817–?) бине Габдулла бине Байгана (Баеган–?) бине Мулласәлим бинеХәлекәй

Беренче хатыныннан:

80.1. Габдеррәхим (1849–?) бине Габделбакый

Икенче хатыныннан:

80.1. Габделхәннан (1849–?) бине Габделбакый

81. **Габделдаян** (1810–?) бине Габдулла (1781–?) бине Байгана бине Мулласәлим бине Хәлекәй

82. **Мөхәммәдгали** (1791–?) бине Юлдаш (1764–1835) бине Бакир

Беренче хатыныннан:

82.1. Дәүләтшаһ (1820–?) бине Мөхәммәдгали

82.1.1. Әхмәдулла бине Дәүләтшаһ

82.1.1.1. Зыятдин бине Әхмәдулла

82.1.2. Әхмәдшаһ (1843–?) бине Дәүләтшаһ

82.1.3. Әфләтун (1849–?) бине Дәүләтшаһ

Икенче хатыныннан

82.1. Вәлишаһ (1824–?) бине Мөхәммәдгали бине Юлдаш бине Әбүбәкер

82.1.1. Фазлыйәхмәд бине Вәлишаһ

82.1.1.1. Котлыәхмәд (1894–?) бине Фазлыйәхмәд

82.2. Батыршаһ (1830–?) бине Мөхәммәдгали

83. **Габделгалләм** (1792–?) бине Габделваһһаб (1775–?) бине Байгана бине Мулласәлим бине Хәлекәй

83.1. Габделхалид (1821–?) бине Габделгалләм

83.1.1 Габделлатыйф (1847–?) бине Габделхалид

83.1.2. Әбүбәкер (1849–?) бине Габделхалид

84. **Габделкаһир** (1793–?) бине Габделвәһһаб (1775–?) бине Байгана бине Мулласәлим бине Хәлекәй

84.1. Габделкаюм (1824–1843) бине Габделкаһир

84.2. Каһарман (1828–1898) бине Габделкаһир

84.3. Габделкадыйр (1832–?) бине Габделкаһир

85. **Юлдаш** Бакиров (176–1835) бине Әбүбәкер

85.1. Габдулла (1815–?) бине Юлдаш

85.1.1. Гайфулла (1844–?) бине Габдулла

85.1.2. Габденнәфыйк (1850–?) бине Габдулла

86. **Габдессаттар** (1771–1843) бине Уразгилде бине Госман бине Юныс. Тамгасы: 

86.1. Мөхәммәдәмин (1792–?) бине Габдессаттар

86.1.1. Мөхәммәди (1825–?) бине Мөхәммәдәмин. Тамгасы: 

86.1.2.Әхмәди (1829–?) бине Мөхәммәдәмин

86.1.2.1. Бибигайшә (1877–?) бинте Әхмәди

86.1.2.2. Гайфулла бине Әхмәди

86.1.3. Әхмәджан (1832–1835) бине Мөхәммәдәмин

86.1.4. Указлы мәзин Мөхәммәдхәсән (1834–30.12.1895) бине Мөхәммәдәмин

86.2. Габдулла (1806–?) бине Габдессаттар бине Уразгилде

86.2.1. Габделҗәббар (1835–?) бине Габдулла бине Габдессаттар бине Уразгилде бине Госман бине Юныс

87. **Фәхретдин** (1813–?) бине Хисаметдин бине Низаметдин (1758–?) бине Солтангали

87.1 Шәрәфетдин (1839–?) бине Фәхретдин

87.2. Шәмсетдин (1843–1898) бине Фәхретдин

87.3. Гайнетдин (1850–?) бине Фәхретдин

88. **Хөснетдин** (1809–?) бине Хисаметдин (1784–1810) бине Низаметдин (1758–?) бине Солтангали

88.1. Фәттахетдин (1842–?) бине Хөснетдин

89. **Шиһабетдин** (1815–?) бине Сәйфетдин (1788–?) бине Низаметдин бине Солтангали

90. **Рәхмәтулла** (1782–1837) бине Мөрсәлим

90.1. Рәхимкол (1819–?) бине Рәхмәтулла

90.2. Ризван (1833–1835) бине Рәхмәтулла

91. **Мөхәммәдләтыйф** (1811–?) бине Мөхәммәдгали (1791–?) бине Юлдаш (1764–1835) бине Әбүбәкер

91.1. Мөхәммәдсадыйк (1846–?) бине Мөхәммәдләтыйф

91.2. Мөхәммәдхәбиб (1847–?) бине Мөхәммәдләтыйф

91-А. Мөхәммәдшаһ (1816–?) бине Мөхәммәдгали бине Юлдаш бине Әбүбәкер

91-А.1. Гаделшаһ (1843–?) бине Мөхәммәдшаһ

91-А.2. Җиһаншаһ (1846–?) бине Мөхәммәдшаһ

91-А. Фәйрузшаһ (1849–?) бине Мөхәммәдшаһ

92. **Рахманкол** (1815–?) бине Рәхмәтулла (1782–1837) бине Мөрсәлим

92.1. Гобәйдулла (1838–?) бине Рахманкол

93. **Габделгафур** (1781–1850) бине Уразгилде (1747–1812) бине Госман бине Юныс. Тамгасы: ┬

93.1. Габделләтыйф (1810–?) бине Габделгафур

93.1.1. Камалетдин (1831–?) бине Габделләтыйф

93.2. Госман (1822–?) бине Габделгафур

93.2.1. Әбүбәкер (1848–?) бине Госман

94. **Мөхәммәдсадыйк** (1808–?) бине Габделмофазалов (1785–1822) бине Уразгилде (1747–1812)

94.1. Мөхәммәдшәриф (1829–?) бине Мөхәммәдсадыйк

94.2. Шәрәфетдин (1849–?) бине (Мөхәммәдсадыйк– ?)

Бертуганының уллары:

1. Габдеррәшид (1825–1840) бине Габделфәиз (1802–1827) бине Габделҗәббар

2. Сәидбаттал (1814–?) бине Габделмофазал (1785–1822) бине Уразгилде

95. **Хөсәен** (1787–1849) бине Габделҗәлил

95.1. Бәдретдин (1814–1848) бине Хөсәен

95.1.1. Садретдин (1843–?) бине Бәдретдин

95.2. Фәретдин (1819–?) бине Хөсәен

95.3. Фәсхетдин (1834–?) бине Хөсәен

96. Азанчы **Нигъмәтулла** (1773–1847) бине Исламморад

96.1. Төхфәтулла (1804–?) бине Нигъмәтулла

Беренче хатыныннан:

96.1.1. Шәйхелислам (1833–1838) бине Төхфәтулла

96.1.2. Гыйзетдин (1846–?) бине Төхфәтулла

96.1.3. Лотфулла (1850–?) бине Төхфәтулла

Икенче хатыныннан:

96.1.1. Караметдин (1848–?) бине Төхфәтулла

97. **Гомәр** (1817–?) бине азанчы Хәмзә (1781–?) бине Мәхмүд

97.1. Әбүбәкер (1848–?) бине Гомәр

97.2. Габдрәхим (1850–?) бине Гомәр

98. **Заһидулла** (1831–?) бине Әһлиулла (1792–1832) бине Сәидборһан

99. **Мөхәммәдвәли** (1819–?) бине Габделвәли (1784–1831) бине Әмирбай, «1836 елда чукындырылган»

100. **Мөхәммәдрәхим** (1762–1840) бине Исламморад

100.1. Дәүләтшаһ (1811–?) бине Мөхәммәдрәхим

100.1.1. Мөхәммәдшаһ (1842–?) бине Дәүләтшаһ

100.2. Җиһаншаһ (1816–?) бине Мөхәммәдрәхим

100.2.1. Әхмәдшаһ (1843–?) бине Җиһаншаһ

100.2.2. Әхмәдетдин (1846–?) бине Җиһаншаһ

## Хәлекәй бабай шәҗәрәсе

| | | |
|---|---|---|
| | *1 нче буын* | |
| 1. | Хәлекәй | |
| | *2 нче буын* | |
| 2. | Мулласәлим | 1 |
| 3. | Йосыф | 1 |
| 4. | Мөхәммәдхәсән | 1 |
| 5. | Ибраһим | 1 |
| | *3 нче буын* | |
| 6. | Байгана | 2 |
| 7. | Габделбәшир Хәлекәев (1771–1847) | 3 |
| 8. | Мөхәммәдәмин | 3 |
| 9. | Мөхәммәдгали | 3 |
| 10. | Габделгазиз (1784–1845) | 4 |
| 11. | Габделвахид Хәлекәев[1] (1795–?), урядник | 4 |
| 12. | Габделкәрим | 4 |
| 13. | Хөсәен (солдат) | 4 |
| 14. | Ходайбирде (1799–1848. Тамгасы:  | 5 |
| | *4 нче буын* | |
| 15. | Габделвәһһаб (1769–?) | 6 |
| 16. | Габдулла (1781–?) | 6 |
| 17. | Кәримҗан (1808–?) | 6 |
| 18. | Сәлимҗан Хәлекәев (1811–1897. Тамгасы: + | 6 |
| 19. | Гафифә (1820–?) | 6 |
| 20. | Ибраһим (1799–1818) | 7 |
| 21. | Насретдин (1809–1848) | 7 |
| 22. | Баһаветдин (1824–?) | 7 |
| 23. | Сиражетдин Хәлекәев (1830–1898) | 7 |
| 24. | Мөхәммәдкәрим (1797–1838) | 8 |

[1] Габделвахид Хәлекәев – 1812 елгы Ватан сугышында катнашкан.

25. Хәйретдин (1802) 8
26. Фәхретдин (1809–?) 8
27. Хөснетдин (1812–?) 8
28. Мөхәммәдвәли (1813–?) 9
29. Габдессәлам (1828–?) 11
30. Габделмәннаф (1830–?) 11
31. Габделхәннан (1849–?) 11
32. Габделфәттах (1850–?) 11
33. Миңлекәмал (1895–?) 12
34. Габдеррәфыйк (1895–?) 13
35. Ходайдат (1804–1834) 14
36. Ишмөхәммәд (1803–?) 14
37. Фәрухшат (1815–?) 14
38. Мирсаяф (1820–1846) 14
39. Әюб (1823–?) 14
40. Таһир (1829–?) 14
41. Шәһингәрәй (1839–?) 14

*5 нче буын*

42. Габделгалим (1792–?) 15
43. Габделкәрим (1793–?) 15
44. Габделкаһир (1793–?) 15
45. Габделдаян (1810–?) 16
46. Габдрахман (1814–?) 16
47. Габделһади (1815–?) 16
48. Вилдан, солдат 18
49. Сөләйман 18
50. Гыйрфан (1841–1893) 18
51. Гыйльман 18
52. Хәлилулла Әхмәров (1848–?) 19
53. Мөхәммәдхәсән (1835–?) 24
54. Мөхәммәдшәриф (1838–?) 24
55. Фәттахетдин (1837–?) 26
56. Шәһингәрәй (1841–?) 28
57. Шаһвәли (1849–?) 28

58. Габдеррәхим (1853–?) 29
59. Габделкаһир (1833–1835) 35
60. Җиһангир (1821–1834) 36
61. Солтангир (1837–?) 36
62. Арыслангир (1841–?) 36
63. Шаһиморад (1844–?) 37
64. Шаһиәхмәд (1848–?) 37
65. Нурмөхәммәд (1850–?) 37
66. Шаһвәли (1843–?) 39
67. Шаһгали Хәлекәев. Тамгасы:  39
*6 нчы буын*
68. Габделхалит (1821–?) 42
69. Габделкаюм (1824–1843) 44
70. Каһарман (1828–1898) 44
71. Габделкадыйр (1832–?) 44
72. Гөлйөзем 48
73. Әхмәдҗан 50
74. Гөлйөзем 50
75. Хәбибҗан (1897–?) 51
76. Гыйльмиҗиһан 51
77. Хәдичә Әхмәрова 52
*7 нче буын*
78. Габделләтыйф (1847–?) 68
79. Әбүбәкер (1849–?) 68
80. Мөхәммәдйосыф (1897–?) 76
81. Фатыйма Муллагали кызы Латыйпова, Әмир авылы (1909–1987) 77
*8 нче буын*
82. Мөдәррис Лотфрахман улы Усманов (1931–2011), Бакча авылы 81
*9 нчы буын*
83. Венер Мөдәррис улы Усманов, Бакча авылы 85

## Илмәт шәҗәрәсе

Тамгалары: 

| | | |
|---|---|---|
| | *1 нче буын* | |
| 1. | Илмәт | |
| | *2 нче буын* | |
| 2. | Мәсгуд | 1 |
| | *3 нче буын* | |
| 3. | Искәндәр, «старшина ярдәмчесе» (1761–?)<br>Хатыннары:<br>1) Салифа (1764–?)<br>2) Хәят (1772–?) | 2 |
| | *4 нче буын* | |
| 4. | Габдессаттар (1793–?) | 3 |
| 5. | Мөхәммәдьяр (1793–?), «Отставной зауряд хорунжий» | 3 |
| 6. | Әсфәндияр (әнисе – Салифа), «җаваплы урядник» (1795–?) | 3 |
| 7. | Габделхәннан (1799–?) | 3 |
| | *5 нче буын* | |
| 8. | Габделхәсән (1823–?) | 4 |
| 9. | Фәхрелислам (1829–?) | 4 |
| 10. | Фәйруз (1814–?) | 5 |
| 11. | Садретдин, «Садрый», аның ике хатыны булган | 5 |
| 12. | Хәбибетдин (?–1840) | 5 |
| 13. | Сахибетдин (1841–?) | 5 |
| | *6 нчы буын* | |
| 14. | Шәрфеҗиһан | 9 |
| 15. | Гыйрфан (1837–?) | 10 |
| 16. | Арыслангали, «солдат» (1857–?). Тамгасы: . аның ике хатыны булган, икенчесе – Гөлниса Яушева | |
| 17. | Бәдриҗәмал (1868–?) | 11 |
| 18. | Миңлегали | 11 |
| 19. | Сәгыйтьдин, «солдат» | 13 |

20. Вәлиәхмәд 13
21. Хәбибрахман 13
22. Хафиза (1865–?) 13

*7 нче буын*

23. Хаҗигали, Бөек Ватан сугышында һәлак булган 16
24. Әхмәдгали (1896–1979), Бөек Ватан сугышында катнашкан 16
25. Хәмдия 16
26. Мөхәммәдгали (1877–?) 16
27. Миңлеҗан 16
28. Бибикамал (1895–?) 18
29. Мөхәммәдзакир 19
30. Фәрһиҗиһан 20

*8 нче буын*

31. Хәбибулла (1895–?) 23
32. Бибинур 23
33. Алим 23
34. Мөхәммәдгали, Чуакай утарында яшәгән, сугышта һәлак булган 24
35. Сәетгали (1936–?), Чуакайда яшәгән 24
36. Зөлхәбирә, Чуакайда туган 24
37. Хәйдәр (1931–2006), Хәлекәйдә яшәгән 24
38. Ракыя (1928–21.06.2011) 25
39. Гали Шабаев, Карагыш авылы 25
40. Зәйтүнә 27
41. Зөбәйдулла 27
42. Фәния Гайфулла кызы Фәйзуллина (1933–2016) 27

*9 нчы буын*

43. Миңлегөл Хәсәнова 35
44. Зөһрә 35
45. Сөнәгать 35
46. Самат 35
47. Сәлим, Хәлекәйдә… 37
48. Хәлил 37

| | | |
|---|---|---|
| 49. | Минзәлә | 37 |
| 50. | Рәмзилә Перова | 37 |
| 51. | Әнвәрҗан | 38 |
| 52. | Тәзкирә | 39 |
| 53. | Галим | 39 |
| 54. | Вәрис | 39 |
| 55. | Роза | 39 |
| 56. | Зәкия | 40 |
| 57. | Мәүсилә | 40 |
| 58. | Хәлил | 40 |
| 59. | Хәлим | 40 |
| 60. | Зәйнулла | 41 |
| 61. | Фәйзулла | 41 |
| 62. | Гөлнәфис | 41 |
| 63. | Гөлнур | 41 |
| 64. | Гөлнәзирә | 41 |
| 65. | Мәрзия | 41 |
| 66. | Фәһим | 41 |
| 67. | Фәһимә Макашева | 42 |
| 68. | Минзия Рысаева | 42 |
| 69. | Мөнир | 42 |
| 70. | Венер Мөдәррис улы Усманов | 42 |
| | *10 нчы буын* | |
| 71. | Руслан | 67 |
| 72. | Шамил | 67 |
| 73. | Ренат | 68 |
| 74. | Азат | 68 |
| 75. | Азалия | 68 |
| 76. | Рәсүл | 68 |

## Алтынбәк шәҗәрәсе

| | | |
|---|---|---|
| | *1 нче буын* | |
| 1. | Алтынбәк (кайсы дәвердә яшәве мәгълүм түгел) | |
| | *2 нче буын* | |
| 2. | Юныс (≈1679–?) | |
| | *3 нче буын* | |
| 3. | Госман (≈1708–?) | 2 |
| | *4 нче буын* | |
| 4. | Уразгилде (1737–1812) | 3 |
| 5. | Габделҗәббар (Габделзәбир) | 3 |
| | *5 нче буын* | |
| 6. | Габдессаттар (1770–?). Тамгасы: ╤ | 4 |
| 7. | Габделгафур (1781–1851). Тамгасы: ┬ | 4 |
| 8. | Габделмофаззал (1785–1822) | 4 |
| 9. | Габделфәиз (1802–1827) | 5 |
| | *6 нчы буын* | |
| 10. | Мөхәммәдәмин (1792–?) | 6 |
| 11. | Габдулла (1806–1840) | 6 |
| 12. | Габделләтыйф (1810–?) | 7 |
| 13. | Бәхтияр (1815–1829) | 7 |
| 14. | Госман (1822–?) | 7 |
| 15. | Мөхәммәдсадыйк (1808–?) | 8 |
| 16. | Сәитбаттал (1814–?) | 8 |
| 17. | Габдеррәшид (1825–?) | 9 |
| | *7 нче буын* | |
| 18. | Әхмәдулла | 10 |
| 19. | Мөхәммәди (1825–?). Тамгасы: ┼ | 10 |
| 20. | Әхмәдетдин, (Әхмәди?) (1829–?) | 10 |
| 21. | Әхмәдҗан (1832–1835) | 10 |
| 22. | Мөхәммәдхәсән Алтынбәков, кятиб вә мәзин (1834–3895, кабере билгеле, ташъязмасы бар | 10 |
| 23. | Габделҗәббар Абдулов | 11 |
| 24. | Камалетдин (1831–?) | 12 |
| 25. | Әбүбәкер (1848–?) | 14 |

| | | |
|---|---|---|
| 26. | Гомәр «солдат» | 14 |
| 27. | Мөхәммәдшәриф (1829–?) | 15 |
| 28. | Биби Гайшә (1877–?) | 20 |
| 29. | Гайфулла | 20 |

## **Муса (Мусиннар) шәҗәрәсе**

*1 нче буын*

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Муса | |

*2 нче буын*

| | | |
|---|---|---|
| 2. | Габдеррәшид (≈1757–?) | |

*3 нче буын*

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Габдеррәфыйк мулла (1786–1850) | 2 |

*4 нче буын*

| | | |
|---|---|---|
| 4. | Гатаулла мулла (1223–?) | 3 |
| 5. | Гыйсмәтулла (1828–?) | 3 |
| 6. | Гайнетдин (1848–1898) | 3 |
| 7. | Лотфулла, имам-хатыйб вә мөгаллим | 3 |
| 8. | Гыйзетдин (1841–?) | 3 |
| 9. | Хафизетдин (1843–?) | 3 |
| 10. | Фазлыйәхмәд (1849–?) | 3 |

*5 нче буын*

| | | |
|---|---|---|
| 11. | Гыйниятулла | 4 |
| 12. | Һибәтулла | 4 |
| 13. | Габдулла, «солдат» | 4 |
| 14. | Барый (≈1818–?), топограф, сугышта һәлак булган | 4 |
| 15. | Фәйзрахман | 4 |
| 16. | Сафура | 4 |
| 17. | Гыйззәтулла | 5 |
| 18. | Гайшә (1880–?) | 5 |
| 19. | Гобәйдулла | 7 |

*6 нчы буын*

| | | |
|---|---|---|
| 20. | Саман | 13 |
| 21. | Әхмәд | 13 |
| 22. | Фәйзулла (1897–?) | 15 |

| | | |
|---|---|---|
| 23. | Флюра Хәлиуллина-Сәлимова | 16 |

**Габдеррәфыйк – Рәфик шәҗәрәсе**
**(Салихов һәм Шәриповлар)**

Бу нәсел Илмәт һәм Хәлекәй бабайларга барып тоташа имеш.

*1 нче буын*

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Габдеррәфыйк (Рәфыйк) (?–1813) | |

*2 нче буын*

| | | |
|---|---|---|
| 2. | Монасыйб (1769–1823) | 1 |
| 3. | Хөсәен Рафиков (1772–1839), ике хатыны булган | 1 |
| 4. | Әсәдулла (1776–1831) | 1 |
| 5. | Салих Рафиков (1799–?) | 1 |
| 6. | Сәгыйть (1804–?) | 1 |
| 7. | Мөхәммәдшәриф (1810–1848) | 1 |

*3 нче буын*

| | | |
|---|---|---|
| 8. | Әхмәдҗан (1811–?) | 2 |
| 9. | Мөхәммәдҗан (1800–1838) | 2 |
| 10 | Ахунҗан (1815–?) | 2 |
| 11. | Хисаметдин (1799–?) | 3 |
| 12. | Мөхәммәдвәли (1809–1830) | 3 |
| 13. | Сәгадәтдин (1803–?), ике хатыны булган | 4 |
| 14. | Мифтахетдин (1822–?) | 4 |
| 15. | Шәрәфетдин (1832–?) | 5 |
| 16. | Арыслангали (1841–?) | 5 |
| 17. | Вәлиәхмәд | 7 |
| 18. | Гали | 7 |
| 19. | Гайнетдин | 7 |
| 20. | Госаметдин (1836–?) | 7 |
| 21. | Сахибетдин (1842–?) | 7 |
| 22. | Сәгыйдетдин | 7 |

*4 нче буын*

| | | |
|---|---|---|
| 23. | Әхмәдләтыйф (1835–?) | 8 |
Тау Мөхәммәдкә бармаса, Мөхәммәд тауга бара.

* * *

Сыер дуласа аттан уздыра.

* * *

Агач күрке – яфрак, кеше күрке – чүпрәк.

* * *

Авызы пешкән өреп кабар.

* * *

Яман сыер ярда бозаулый.

* * *

Яхшы ашыңны кияү ашар,
Яман сүзеңне кияү сөйләр.

* * *

Тавык чүп чыгара,
Килен сүз чыгара.

* * *

Олы сөйләгәнче, олы телем икмәгеңне аша.

* * *

Олы сүзен тотмаган,
Гомер буе игелек күрмәгән.

* * *

Хөрмәтләсәң яхшы кешене,
Хөрмәтләрләр үзеңне.

* * *

Кешегә ун йомырка тәгәрәткәнче,
Үзеңә берне тәгәрәт.

* * *

Танау астыңны күрмичә,
Урман астына үрелмә.

* * *

Кабергә китсәң дә әзерләп кит.

* * *

Эт күңеле бер сөяк.

*Бузат авылында*
*Ганиева Тәкыя Нигъмәт кызыннан (40 яшь)*
*язып алынган*

* * *

Убыр китте, урыны калды,
Ябынырга туны калды.

* * *

Юләрне чәчеп үстермиләр, үзе үсә.

* * *

Мал иясенә ошый.

* * *

Туган илдән киткән,
Җиде ел кат йоткан.

* * *

Карга күзен карга чокый.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Арсланов Шамилдән (72 яшь)*
*язып алынган*

* * *

Каенананың иң юашыннан да козгын тавышы чыга.

* * *

Сыйларга сыең булмаса,
Сыйпамага телең булсын.

* * *

Ирле кеше Идел кичкән.

* * *

Ир ир булсын, идәне җир булсын.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Кәримова Рабигадан (64 яшь)*
*язып алынган*

* * *

Алтмыштагын ашасаң да, алтыдагын ашама.
Алтыдагы юлда килсә,
Алтмыштагы хәл белергә килә.

* * *

Күршегә кыз бирмә, авылга ат сатма.

* * *

Уйламый сөйләшсәң, авырмый үләрсең.

* * *

Әкрен эшен бетерер,
Дуамал үзен бетерер.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Актуганова Заһидәдән (57 яшь)*
*язып алынган*

* * *

Олыны олы итсәң, үзеңә хөрмәт булыр.

* * *

Олы сөйләгәнче, олы телем икмәк аша.

* * *

Күп сүз бозау имезә, башын таяк тигезә.

* * *

Авызы кыек булса да, бай баласы сөйләсен.

* * *

Аш хуҗасы белән татлы.

* * *

Эт чаба дип бет чаба.

*Яңгырчы авылында*
*Мингазова Банудан (59 яшь)*
*язып алынган*

* * *

Әниле бала – яфрак, әнисез бала –туфрак.

* * *

Утыз улым булганчы, гарип ирем булсачы.

* * *

Акылсыз белем тапма да, сөйләшмә дә.

* * *

Ят ярлыкамый, үз үтерми.

* * *

Кеше сүзен тыңла, үзеңчә эшлә.

* * *

Алама тайның бете әче, алама кешенең сүзе әче.

* * *

Үзең белсәң дә, олыларга киңәш ит.

*Яңгырчы авылында*
*Кәримова Заһидәдән (58 яшь)*
*язып алынган*

* * *

Шайтан шайтанны Мәскәүдән эзләп тапкан.

* * *

Тамыр тарткан тарлыкмый.

* * *

Ир икмәге ирекле.

* * *

Атай аркасы, кала аркасы.

* * *

Күңелсезгә күлмәк кидермиләр.

* * *

Такта чәең – якты чыраең.

* * *

Ачу алдан, акыл арттан йөри.

* * *

Тулган ай, тураган ит.

* * *

Ач тамагым, тыныч колагым.

* * *

Сабырлыклар солтан,
Сабырсызлык шайтан.

* * *

Сабырлыклар кирәк һәр эштә.

*Яңгырчы авылында*
*Батыршина Миңнисадан (56 яшь)*
*язып алынган*

* * *

Картлык шатлык түгел.

* * *

Яхшылык җирдә ятмас.

* * *

Мәрхәмәтле булсаң, дәүләткә ирешерсең.

* * *

Яман дус ашка – башта, ә эшкә – юк.

* * *

Көчең җитмәгәнгә көчәнмә.

* * *

Башта эшеңне, аннан атыңны китер.

* * *

Малың барда дусларны куалап та җибәрә алмассың.

* * *

Чебенне рәнҗетмә, аның да тәне авырта.

* * *

Күп шаярсаң – еларсың.

* * *

Никадәре күп сөйләсәң, шулкадәре хата җибәрерсең.

* * *

Булыр булмас эшкә омтылма.

* * *

Ике дошман бөтен җир йөзенә дә сыймас,
Ә ике дус бер аршын җиргә дә сыяр.

* * *

Кешегә яхшылык эшләү – гүзәл эш.

* * *

Тамак таптыра, азаккы атыңны чаптыра.

* * *

Уйлаганнан берни килми, уйламаганнан килә.

* * *

Үлсәң дә үтә, торсаң да үтә.

* * *

Насыйп булмаганны ашап булмый.

* * *

Кеше сөйләшеп таныша, ат кешнәшеп табыша.

* * *

Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә.

* * *

Мокытны кырык ел укыт.

* * *

Аш иясе аш ясый, кемгә насыйп – шул ашый.

* * *

Берәү тал җыя, берәү тун тегә, әйбер киенчегә кала.

* * *

Берәүдә мал кайгысы, икенчедә җан кайгысы.

* * *

Авыру үлми, сау калмый.

* * *

Ашы бар, кашыгы юк.

* * *

Ат азгыны тайга иярер.

* * *

Аерым тору рәхәт булса, ул безгә тимәс иде.

*Яңгырчы авылында*
*Хисмәтуллина Рабигадан (70 яшь)*
*язып алынган*

**Аракы эчү, исертү**

Аракы – иблис төкереге.

* * *

Аракының бер рәхәте ун михнәте белән чыгар.

* * *

Аракының йөз граммлысы кыйбат,
Йөздән соң меңгә дә юмарт.

* * *

Аракы бар хәтерне бетерә,
Юк хәтерне китерә.

* * *

Аракы эчсәң, эчеңә – рак, йортың харап;
Өстәвенә үз кесәңә үзең карак.

* * *

Аракы эчтем – хушландым,
Һушым китеп буш калдым.

* * *

Башта акчамны алды,
Аннан акылымны алды.

* * *

Башта көлдерә, аннан бөлдерә.

* * *

Бәләкәй шешәдә шайтан баласы,
Чыгарма, килер анасы.

* * *

Бәхетсезлек эчүдән,
Эчең-бавырың шешүдән.

* * *

Булышма исереккә – авызыңа алырсың.

* * *

Бурычка эчкән ике исергән.

* * *

Аракы аздыра,
Я төрмәгә салдыра,
Я хатыннан яздыра.

* * *

Әүвәлгесе сиңа каршыга,
Икенчесе сиңа каргына,
Өченчесе төлке итә,
Дүртенчесе егып көл итә.

* * *

Сатып алган авыру,
Теләп эчкән агу.

* * *

Теләсәң озын гомерне,
Авызыңа алма хәмерне.

* * *

Төнлә исерек, көндез мәлҗерек.

* * *

Ул үзе күп, һич бетмәс,
Никадәр эчсәң дә җитмәс,
Гадәтләнсәң син аны эштән чыгармый китмәс.

* * *

Эчеп бөләсең килсә,
Шешенеп үләсең килсә.

* * *

Тартма – беләсең килсә,
Коммунизм күрәсең килсә.

* * *

Эчкән – кадерсез,
Китkәне күп – каберсез.

* * *

Эчкәннең эче шешәр,
Сугышып теше төшәр.

* * *

Эчкә эчке керсә, тышка бер чыга.

* * *

Эчмәгәндә – шамакай Шаһи,
Эчкәч булган Шаһиәхмәт даһи.

* * *

Эчмә юләр, үлгәч сине кем күмәр.

* * *

Эчсәң акча күп бетә,
Икенче– сырхау итә.
Өченче – акыл китә,
Дүртенче – разбой итә.

* * *

Эчтем, шешәсен ташка бәрдем,
Карасам, ул минем башка бәргән.

* * *

Эчтем шәраб,
Булдым харап.

* * *

Эчү белән эчүнең аермасы бар,
Эчү бер кайгыны баса,
Ун кайгының ишеген ача.

* * *

Ирләр эчсә – ярты йорт яна,
Хатыннар эчсә – бөтен квартал.

* * *

Ир эчәр, ир эчәр,
Ир эчә дип хатын эчәр.

* * *

Исеректә хатын тормас,
Торса да бергә кунмас.

* * *

Исерекне исерек мактар,
Мактавы беткәч, өстенә менеп таптар.

*Хәлекәй авылында*
*Мусин Мәҗит Гыйният улыннан (70 яшь)*
*язып алынган*

**ТАБЫШМАКЛАР**

Бәләкәй генә телде,
Миңа карап көлде. *(Көзге)*

* * *

Аңа килә алып,
Ике җиңен салып,
Куш икән йөрәге,
Тимер икән күрәге. *(Бүре)*

* * *

Кара каз килә калдыр-калдыр,
Канат очы ялтыр-йолтыр.
Баласы елый вәр-вәр,
Бармагы каный шар-шар. *(Яшенле яңгыр)*

* * *

Бәләкәй генә чүлмәгем,
Тәмле булды чуарым. *(Чикләвек)*

* * *

Аккошлар арыш суга,
Әндри көлтә әйләндерә. *(Авыз һәм тешләр)*

* * *

Бәләкәй әби тау шуа. *(Чәч тарау)*

* * *

Читән аша эт тартыла. *(Сүс эрләү)*

* * *

Бәләкәй әби ерак төкерә. *(Мылтык)*

* * *

Дыр-дыр дырмани кәтәк,
Дырманикәни-кәтәк.
Дырмани кәчтери-пәчтери кәтәк. *(Тегү машинасы)*

* * *

Эче куыш, тышы таш,
Мәгънәсе – орчыкбаш.

*Ногманова Гарифәдән (60 яшь)*
*язып алынган*

* * *

Әфти келәткә бара,
Ачкычы төшеп кала,
Ай күрә, кояш төшеп кала. *(Кырау төшү)*

* * *

Ак тун кигән,
Түбә түшәмгә тигән. *(Морҗа)*

* * *

Бәләкәй генә бөкре,
Бөтен кырны бетерде. *(Урак)*

* * *

Мич тулы пәрәмәч,
Уртасында бер калач. *(Ай)*

* * *

Дыңгыр-дыңгыр дыңгырчык,
Өч йөз алтмыш сыерчык. *(12 ак каз, ике аккош)*

*Хәлекәй авылында*
*Локманова Мөкәррәмә Гариф кызыннан (63 яшь)*
*Р. Халикова язып алган*

* * *

Мөгезе-мөгезе мөгезәли,
Мөгезе күккә терәли.
Акбур белән буялый,
Көмеш белән сырланый. *(Мәчет)*

* * *

Ары да лап-лап,
Бире дә лап-лап.
Сөңге сатлап,
Киез катлап. *(Чабагач белән ашлык сугу)*

* * *

Ята куяндай,
Торса дөядәй. *(Чыбылдык)*

*Хәлекәй авылында*
*Әминева Гөлзәлинә Миңнеәхмәт кызыннан (55 яшь)*
*Р. Халикова язып алган*

* * *

Җәй җәйли, кыш кышлый,
Яшел тунын тышлый. *(Арыш)*

* * *

Келәтеннән бастырыгы озын. *(Саескан)*

* * *

Сөрелмәгән җир өстеннән
Тумаган куян баласы йөгерә. *(Алдау)*

* * *

Уклау, уклау,
Башы чуклау.
Җир йот, тамыр йот,
70 агач ботагы. *(Колмак)*

* * *

И әмри мак, әмри мак,
Әмри макта биш бармак.
5 ботакка кар яуган,
Кар өстенә кан тамган. *(Бармак һәм тырнаклар)*

* * *

Җиз сарайның эчендә
Җизнәм аты кешнидер. *(Кыңгырау)*

* * *

Аркылы да, торкылы
Зәкиләрнең ындыры. *(Тәрәзә рамы)*

*Хәлекәй авылында*
*Сабитов Әхмәт Нигъматулла улыннан (82 яшь)*
*Р. Халикова язып алган*

* * *

Уклау, уклау,
Башы чуклау.
Җир йот, тамыр йот,
70 агач ботагы. *(Колмак)*

* * *

Улы аяк киеме кигәнче
Атасы Мәскәүгә барып кайта. *(Төтен чыгу)*

*Хәлекәй авылында*
*Шәрипова Гөлҗиян Ихсан кызыннан (69 яшь)*
*Р. Халикова язып алган*

* * *

Иртән 4 аяктан йөри,
Өйләдә 2 аяклап йөри,
Кич 3 аяклап йөри. *(Кеше)*

* * *

И Әмри мак, Әмри мак
Әмри макта биш бармак.
5 ботакка кар яуган,
Кар өстенә кан тамган. *(Бармак һәм тырнаклар)*

* * *

Җәй дә яшел, кыш та яшел. *(Чыршы)*

*Хәлекәй авылында*
*Хөснетдинова Маһикамал Хафиз кызыннан (78 яшь)*
*Р. Халикова язып алган*

* * *

Аттан биек, эттән тәбәнәк. *(Ыңгырчак)*.

* * *

Җиз сарайның эчендә,
Җиңгәм аты кешни иде. *(Кыңгырау)*

* * *

Аркылы-торкылы,
Зәкиләрнең ындыры. *(Тәрәзә рамы)*

* * *

Килделәр осталар балтасыз,
Салдылар күпер тактасыз. *(Суык)*

* * *

Ак сыер торып китте,
Кара сыер ятып калды. *(Кар һәм җир)*

* * *

Урманда бар, өйдә юк,
Мунчада бар, кырда юк. *(«М» хәрефе)*

* * *

Аяксыз-кулсыз капка ача. *(Җил)*

* * *

Өрми килми, беркемне дә кертми. *(Йозак)*

* * *

Бер түбә астында дүрт туган. *(Өстәл һәм аяклары)*

*Хәлекәй авылында*
*Халимов Гариф Гомәр улыннан (72 яшь)*
*Р. Халикова язып алган*

* * *

Тимер чыпчык, сүс койрык. *(Инә белән җеп)*

* * *

Зыр-зыр катык,
Зырмалы катык,
Тырастыра, бастыра. *(Комбайн)*

* * *

Нечкә билле марҗасы,
Йөгерә-йөгерә су ташый. *(Бал корты)*

*Тәтер-Арслан авылында*
*Ишмөхәммәтова Мәүсиләдән (39 яшь)*
*Н. Абдуллина һәм Ф. Шакирова язып алган*

* * *

Салпы колак киң битле,
Сөйләшергә бик ипле. *(Самавыр)*

* * *

Башы бар, күзе юк,
Койрыгы бар, йоны юк. *(Чабата)*

* * *

Кара каз калтор-колтыр,
Канат очы ялтыр-йолтыр. *(Яшен)*

* * *

365 тупычык, 48 сыерчык, 12 каз, 1 торна. *(Көн, атна, айлар, ел)*

*Тәтер-Арслан авылында*
*Ханнанова Фәкыядән (69 яшь)*
*язып алынган*

* * *

Таба-таба табалама,
Таба артыннан юргалама.
Кеше күрсәң – кешнәмә,
Үлән башын тешләмә. *(Чалгы белән печән чабу)*

* * *

Өчпочмаклы келәт салдым,
Керергә ишеге юк. *(Карабодай)*

* * *

Бер капчыкта ике карчык. *(Борай)*

* * *

Тоз чиләгендә тратай тарту. *(Күз)*

* * *

Кара тай, тоягы май. *(Таба сөртү)*

* * *

И Ходайның кодрәте,
Су өстендә мәлләте.
Агачтан заты, тимердән каты. *(Күпер)*

* * *

Аягы юк, кулы юк,
Корсагында кендеге. *(Комган)*

*Яңгырчы авылында*
*Садриева Хәмдидәдән*
*И. Бәхтиярова язып алган*

## МӘЗӘКЛӘР ҺӘМ МӘЗӘК ХӘЛЛӘР

### Ат караучының бригадир белән сөйләшүе

Сугыш елларында була бу хәл. Атлар дворына ат караучы итеп 12 яшьлек Рәсүлне алалар. Сүз шуның хакында.

*Беренче сөйләшү.*

Баш ат караучы. Гафиянең малае Рәсүлне әйтәм, бик юньле икән, ай-һай, кемгә ошаган, ә? Бик уңган.

Бригадир. Ата-анасы да яхшы кешеләр бит.

*Икенче сөйләшү.*

Баш ат караучы. Рәсүлне әйтәм, ну оятсыз икән!..

Бригадир. Соң, абзый, үзең кичә генә бик тыйнак, юньле дигән идең, бүген килеп, оятсыз дисең. Ничек аңларга инде сине?

Баш ат караучы. Юньлесен юньле дә ул. Ну оятсыз инде. Тайларга дигән печәнне атларга ашаткан.

## Бер абзыйның сөйләвеннән

Утыз кадаклы бидрә белән 80 бидрә бәрәңге алдык. Ким дигәндә дә 100 пот булыр әле.

* * *

Туксан биш пәрәмәч пешергән идек, берсе дә калмаган. Әйттем Рәшиткә, ач йөретмә, Рәшит, дидем, кунакларны. Болай ач йөртү бер дә килешми, дидем. Соң үзегез уйлагыз инде; үзем санадым, 95 пәрәмәч иде, ялт иттереп кенә калдылар.

*Яңгырчы авылында*
*Батыршина Миңнисадан (56 яшь)*
*И. Бәхтиярова язып алган*

## ЮРАМЫШЛАР

Эт аунаса, буран күтелә.

* * *

Песи аунаса, ил-буран була.

* * *

Песи колак артын кашый, кунак килә.

* * *

Мендәр төште, кунак килә.

* * *

Кара тавык кытыкласа, каза килә.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Ишмөхәммәтов Мөхәммәдиярдән (1900 елгы)*
*язып алынган*

## АРБАУ

*(Баланы мунча чапканда әйтелә)*

Зур үс,
Зур укы,
Ата-инәле бул,
Алтын канатлы бул.
Итагатьле бул.
Һәрвакыт яхшы укы.
Олыны олыла.
Кечене мәртәбәгә үрәт.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Мирзаева Закирәдән (70 яшь)*
*язып алынган*

## ЛЕГЕНДА

### Аракы килеп чыгуның легендасы

Иблис адәмгә дошманлыгыннан аны ничек тә мәсхәрә итәсе килгән. Ул шайтанны каршысына китергән дә, ничек итсәң ит, кешеләрне кешелектән чыгара торган бер нәрсә уйлап чыгар, шуның белән алар минем колым булсыннар, дип бойрык биргән, ди. Шуннан шайтан авылга килеп бер игенчегә ялланып, иген чәчешкән, аннары көзен ашлыктан аракы кайнатып хуҗасына тәкъдим иткән, ди. Хуҗага бу нәрсә охшап, кардәш-ыруын җыеп эчке мәҗлесе ясаган була. Шайтан шул мәҗлескә остазы иблисне чакырып, аның боерыгын башкарып чыккан икәнлеген үз күзе белән карап, сынап торырга үтенгән, ди. Табындагылар бар да югарыда әйткән хәлләргә көлгәннәр. Шуннан иблис, ләгънәт төшкере, бу шайтанны бик мактап, мондый аракыны башлап ничек ясавын сорагач, шайтан аңа югарыдыгыча әйтеп, җавап биргән имеш. Иблис бу эшне бик хуп күргән, моңа тагы минем төкерегем генә җитми, башкасы бар да булган дип, килеп, аракыга лач иттереп бер төкергән икән. Табындагылар аны да эчкәч, араларында адәмлек тә, туганлык та калмаган имеш.

Мифларга бәйләнгән бу легенда төрле төрләнешендә, халыклар арасында мең еллар буенда йөри. Шуңа охшаган бер легенда Лев Толстойда китерелгән.

## СЫНАМЫШЛАР

Барыс елы – байлык,
Куй елы – кытлык,
Куян елы – йотлык.

*Хәлекәй авылында*
*Мусин Мәҗит Гыйният улыннан (70 яшь)*
*язып алынган*

## БӘЕТЛӘР

### Гөлнаһар бәете

Гөлнаһарны кызганам мин
Чын бәхетсез калган ул.
Әнкәсе чирләп вафат булган,
Урынында калган ул.

Әллә нинди чит кешеләрнең
Кулында калган ул.
Үсеп кеше булгач, чит инде,
Һич ашарга бирмиләр.
Монда торма, кайдан килсәң,
Шунда кит, дип тиргиләр.
Кыш көне салкын буранда
Ач тора алмый, аптырап
Бара күрше хатынына
Бер телем икмәк сорап.
Күлмәге ертык, аягы ялан,
Чәче тузгыган аның.
Барды, керде шул көенчә
Күршесенә аптырап.
Алланың үксезләренчә,

Кызганучы бер хатын
Булган өчен Гөлнаһарга
Кызганып килде якын.
Ул сорый Гөлнаһардан,
Монда нишләп килгәнен.
Ни йомыш белән йөргәнен,
Монда нишләп килгәнен.
Гөлнаһар елап сөйләде,
Хатын тыңлап торды.
Аһ, бичара Гөлнаһар, дип
Ач тамагын туйдырды.
Ашады-эчте, җылынды,
Китте йөзләре ялтырап.
Өстенә күлмәк тә бирде,
Инде тормый калтырап.
Туйдыру белән дә куймый,
Көн саен кил безгә, ди.
Гөлнаһар да шатлыгыннан,
Рәхмәт инде Сезгә, ди.
Бер дә килә, ике килә,
Өч тә килә, дүрт килә.
Күпме килсә дә хатын
Тормый салкын йөз белән.
Беркөнне теге хатын
И Гөлнаһар, ди
Бездә тор, бездә аша,
Һәм дә мәктәпкә дә бар, ди.
Гөлнаһарга хатын шулай дип,
Җавап ташлады.
Гөлнаһар ярар, диде,
Шундук укырга башлады.

*Айтуган авылында*
*Галиева Оркыядан (63 яшьтә)*
*язып алынган*

**Зөфәр бәете**

Утын алып кайтырга дип
Киткән иде урманга.
Әҗәлләре тартып аны
Алып баргандыр анда.
Утын алып кайтырга дип,
Киткән иде урманга.
Зөфәр үлгән икән, диеп
Халык тулган урамга.
Беларусь дигән машина,
Тау башына менеп китә.
Иптәшләрем, дус-ишләрем,
Якыннарым килеп җитә.
Алар килгән яннарыма,
Авыр булды тәннәремә.
Ул гәүдәләре кайтса да,
Таммады күз яшьләрем.
Шул урынга барабыз, дип
Өйдә чакта сөйләштеләр.
Аталары үлеп кайткач,
Балалары җылаштылар.
Үле гәүдәләре кайткач,
Җыелышып туганнары,
Башка авылда булсалар да,
Җыелышып килгәннәр барсы да.
Терелер дип өмет иттем,
Җылынмады тәннәрем.
Иртәнге сәгать унга
Кадерле гәүдәләрем катты.
Иптәшләре, дус ишләре,
Каберләрен читләделәр.
Бер чыккач кабат кермәде,
Аның тәненә җаннары.
Мөнәҗәт итеп язарга,
Минем караларым җитмәс,

Икенче йозаклар белән
Магазинын бикләделәр.
Су агадыр гөлдер-гөлдер,
Су өсте кызыл гөлдер.
Сине миннән аерганга
Бер Ходайның тәкъдиредер.
Газизем, газиз Алла
Авыр кайгы салды миңа.
Һич дару, дәрман тапмыйм,
Мин газиз булдым аңа.
И Ходаем, и Хода кәрим,
Синең рәхмәтеңә карыйм.
Ялгыз калдым, кая барыйм,
Шәфкать яра сылулла.
Илаһым хак Кәримулла;
Догаларым кабул әйлә,
Гөнаһым күр, гафу әйлә,
Шәфәгать яра сылулла.

*Муллаянова Миңзифадан (70 яшь)*
*язып алынган*

**Мәрьям бәете**

*(Гариф хатыны Мәрьям, тамагына шеш чыгып, тиз вакыт эчендә дөнья куя. Бу хәл 1955 елларда була)*

Ач, Мәрьям, ач, Мәрьям
Ач, Мәрьям, күзеңне.
Ачмасаң, Мәрьям, күзеңне
Һәлак итәм үзеңне.
Ач, Мәрьям, ач, Мәрьям
Ач, Мәрьям, битеңне.
Әгәр ачмасаң битеңне,
Ашыйм йөрәк итемне.
Больницадан чыккан чакта,
Башына марля ураган.

Мәрьям апа үлгән чакта,
Гариф өйдә булмаган.
Җиксәң, җик син атның
Җирән кашка аласын.
Мәрьям мескен үлеп китте,
Калды ике баласы.

*Хәлекәй авылында*
*Латыйпова Рәйханә Гатаулла кызыннан (58 яшь)*
*язып алынган*

**Төрмәдә яткан бәндәнең бәете**

Ничә еллар буена,
Утыра ялгыз башым.
Бер савыт су, бер телем икмәк –
Минем ашаган ашым.
Ике күзем якты күрмичә,
Яши башым.
Көне-төне елый-елый
Бетте инде күз яшем.
Хәсрәт утының сөреме,
Каплады күзләремне.
Ут кабынган йөрәгемә,
Тышка да чыкты инде.
Хәтфә кебек яшел булып,
Тора микән җир йөзе.
Әллә аларны да көйдереп,
Бетте микән күз яшем.
Кайда китте яшь вакытым,
Назлы үскән чакларым.
Йоклаганда төштә күрәм,
Уйнап үскән чакларым.
Бакчаларда сандугачлар
Сайрый микән әле дә.
Әллә аларны да тоткын
Итте микән дошманым.

## Әнисеннән яшьли калган 8 яшьлек бер бала бәете

Әрни мескенкәем, яшен түгә
Башкынаен куеп тезенә.
Мәңгелек йортка күчәм, балам, диеп
Зәгыйфь кулын куя йөзенә.
Каласың, кызым, бер ялгызың,
Күчә синнән шәфкать диңгезе.
Синең күзләреңнән яшь өзелми,
Кап-караңгы булыр җир йөзе.
Сиңа көлгән якты өйләр,
Хәзер булыр кап-караңгы.
Барысы да елаган чагында
Юатырга газиз әнкәең булмас каршыңда.

*Хәлекәй авылында*
*Могаттарова Өммикамал Гомәр кызыннан (73 яшь)*
*язып алынган*

## Хәсәнов Вәли бәете

*(Бәет поездга тапталып аяксыз калган Вәли турында)*

Их, син Ташкент, җылы як,
Бүген сиңа кар яуган.
Аяксыз калып, елый-елый
Йөрәгемә кан сауган.

Алдым билет, утырдым,
Килү дигән вагонга.
Ушсыз булып 10 көн яттым,
Аяктан кан агуга.

Бүген бер ай дигәндә,
Тоттым кулга таякны.
Ике якка сөяп куеп,
Карап тордым аякны.

Их, син култык таягы,
Нихәл, исән килүеңме?

Гомергә миңа хезмәт итүең
Төшләреңә кердеме.

Ташкент шәһәре зур икән,
Уртасында кар тавы.
Сабый чакта төште микән
Атаң-анаң каргавы.

Трамвайга утырсагыз,
Утырмагыз билетсыз.
Туганнарым, илемә кайтсам,
Мине аяксыз күрерсез.

Әмма кайтып күрәсе иде
Карагайның яланын.
Матур иде, рәхәт иде,
Бар чагында аягым.

Кара карлыган пешәдер,
Күндерәк буйларында.
Миңа шатлык булмас инде,
Булыр дип уйламыйм да.

* * *

Хатын, быел ашлык чәчсәң,
Икәүләшеп утарбыз.
Исән йөреп, саулар кайтсам,
Мәңге дөнья көтәрбез.

Фәрит улым, чана шуыйк
Биек тауның үрендә.
Очып барып кайтыйм микән
Син улымны күрергә.

Минем балам икәү булса,
Аның берсе – Илмардыр,
Газиз әткәсен уйласа,
Кичләрендә елыйдыр.

Балдызкаем, бик яшь идең,
Атаң кебек үстердем.
Барыгызны да бер тиң күреп,
Исләремә төшердем.

Кара урманда кар сай булса,
Төлке эзен таптырмас.
Совет власте яшәсә,
Безне озак яткырмас.

*Шәрипова Мәрхәбә Әһлетдин кызыннан (59 яшь)*
*язып алынган*

**Ибраһим бәете**

66 нчы ел башында
Моны яза башладым.
Яңа ел башлары белән
Яшьләрем түгә башладым.
Балакаем, ел башында
Яшьләр түгә башладым.
Эчләремә сыймаганга,
Моны яза башладым.
Балакаем плен төшеп,
Күпме зарларны күрде.
Балакаемның башына
Күпме авырлыклар килде.
44 яшьләргә җитте,
Балакаем яшьләре.
44 яшь өсләрендә
Гүргә керде яшьләре.
Иртәнге сәгать алтыда,
Чыгып китте уянып.
Кичке сәгать алтыда
Яткан карга күмелеп.
Поезд кычкырып килгәндә,
Юл бирәм диде микән.

Әләктереп алып киткәч,
Ушлары китте микән.
Эзләргә дип барган чакта,
Халык торган тезелеп.
Кар асларында калган ул,
Аяк кулы өзелеп.
Тапкач, дәшеп караганнар,
Бер сүз дә эндәшмәгән.
Шулай итеп, газиз балам
Бу дөньяны ташлаган.
Җиһан гизеп эзләсәм дә,
Табалмамын эзләрен.
Гомеремдә дә онытмамын
Аның әйткән сүзләрен.
Йөрәгемне яндырадыр
Шул баламның кайгысы.
Төшмәсен безнең хәлләргә
Бәндәнең һич кайсысы.
Аяк-кулларың өзелеп,
Каберләрдә ятасың.
Никадәре еласам да
Инде кире кайтмассың.
Балакаем, ал янына
Сине алмыймын, димә.
Бергә ятыйк гүр эчендә
Бергә ятыйк мәңгегә.

**Бәхетсез ананың зары**

Тугыз ай күтәреп йөрдем,
Ак сөтләремне имездем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Баладан катылык күрдем.

Аналар утыра түрдә,
Вакытсыз кермиләр гүргә.

Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Ананы сөймиләр бер дә.

Бала анага бик татлы,
Тугач та тәннәрен пакьли.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Бала өзелми ана хәтле.

Балаларның нурлы йөзен,
Күреп туймый ике күзем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Бары ялган минем сүзем.

Ана күңеле балада,
Бала күңелләре далада.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Миһербанлык юк балада.

Тугыз ай күтәреп йөргән,
Ике ел сөтен имезгән.
Төнге йокыларын бүлгән
Синең анаң түгел мени?

Ничә еллар сезнең өчен
Кайгы эчләрендә йөзгән.
Сабырлыклар сорап түзгән
Синең анаң түгел мени?

Өс башларыңны аклаган,
Ялган эшләрдән саклаган,
Газиз балакаем, дигән,
Синең анаң түгел мени?

Яманга күзләрең салма,
Дөнья малына алданма.
Ахирәттән мәхрүм калма,
Шуны балам яхшы аңла!

Дөнья шатлыгы күрмәгән,
Тигезлек гомер сөрмәгән.

Күп авырлыкларга түзгән,
Синең анаң түгел мени?

Кулымнан эшләрем китте,
Тәнемнең көчләре бетте.
Озакламый кара гүргә
Керер вакытларым җитте.

Әйтә алмый сүзләремне,
Ходай алды күзләремне.
Сары баскан йөзләремне
Синең өчен түгел мени?

Балалар риза булса,
Китәм ерак сәфәрләргә.
Бер киткәч кайта алмабыз,
Күрешербез алдагы көннәрдә.

Йөземнең нурлары сүнде,
Күземнең нурлары китте.
Озакламый кара гүргә,
Керер вакытларым җитте.

Сүләр идем сүзләремне,
Кан яшь ала күзләремне.
Сары басты йөзләремне,
Сезнең өчен түгел мени?

Сабыр итәм, сабыр итәм,
Сабыр итми нихәл итәм.
Сабырлыкның дәрәҗәсен,
Үзең бирче, газиз Аллам.

Агач башындагы кошлар,
Басып сайрый ботагына.
Исәпләсәм исем китә,
Бу дөньяның исәбенә.

*Шәрипова Мәхупҗамал Әһлетдин кызыннан (66 яшь)язып алынган*

**Галиулла улы Әхтәм бәете**

Бүген төнлә төшләремдә
Тау астында уйнадым.
Тау астында уйнавымны
Үләрмен дип уйладым.
Җәй көнендә ат тышаулыйм
Каршы тау башларында.
Минем тәннәрем муртая
Салкын кар асларында.
Миннән калган яшел дуга,
Агым суга салмассыз.
Хәзер минем тәннәремне
Язсыз таба алмассыз.
Сандугачның балаларын
Тотсам үтермәс идем.
Җылы урыннарда үлсәм,
Һич тә үкенмәс идем.
Адашканда күралмадым,
Көчегән авыл мәчетен.
Сабый чакта үлгән булсам,
Калмас иде Виленың.
Кожаным белән билбавым
Төшеп калды билемнән.
Болай үләремне белсәм,
Чыкмас идем илемнән.
Кызганмады дөнья мине,
Җәфа салды башыма.
Алып китте, кызганмады
Егерме ике яшемдә.
Алтын алдым, көмеш салдым,
Җилфердәгән камышка.
Йоклаганнар уянгандыр
Мин кычкырган тавышка.
Якшәмбе көн бардым мин
Ак куяннар атарга.

Ходаем насыйп итмәде
Туган илгә кайтырга.
Миннән калган күлмәгемне
Әткәй үзең киярсең.
Миннән калган Рәшитемне
Бер мирас диеп сөярсең.
Ай-һай туры аткаем,
Адаштык бит, малкаем.
Кычкырганны ишеткәнсең,
Муләхсән туганкаем.
Адашып йөргән чагымда
Ачы буран, караңгы.
Коры Күл тавын менгәндә
Ике күзем кан алды.
Әхтәм каләм алган икән,
Балам, хатлар язарга.
Әхтәм мескен барган икән
Үләр өчен базарга.
Беразга хәтле кычкырдым
Каршы килерләр диеп.
Хәлем беткәч, мин утырдым
Күрәсең, үләм диеп.

*Өч-Әсән авылында*
*Нугуманова Мәгъзифә Нигъмәтулла кызыннан*
*язып алынган*

### Хәдичә әбинең кызы Рәкыйга өчен чыгарган бәете

Кая барыйм, кемгә сөйлим
Хәлемнең авырлыгын.
Ходай насыйп итсен миңа
Пәйгамбәр сабырлыгын.
Тәрәзәмне ачып куйсам,
Чәчәк атадыр гөлләрем.
Газиз анаңны ташладың,
Таштыйн каты күңелләрең.

Күп авырдым, ышанмадың,
Хәлләремне сорамадың,
Сарайда тилмереп яттым,
Шуны күреп кызганмадың.
Сез ашап эчкән вакытта,
Мин егълап утырдым читтә.
Карыным бик ач булса да
Сабырлар иттем ничек тә.
Мин сине табып үстердем,
Авырлыкка түзә-түзә.
И бәбкәем, йөрәк парәм,
Анасыннан кемнәр бизә?
Эчендә булган сереңне,
Бер дә миңа киңәшмәдең,
Якты чырай күрсәтмәдең,
Әнием, дип эндәшмәдең.
Фикер кылсам бу хәлләрне,
Хыял баса, йөрәк таша.
Шәфкатьле сүзләре белән,
Йөрәгемне кемнәр баса.
Бик артык җәберләдегез,
Түздем мин ниләр күрсәм дә.
Мәңге әрнеп ятармын мин
Караңгы гүргә керсәм дә.
Йөрәк бәгърем, газиз балам,
Мин бит синең газиз анаң.
Сине тапкач, бик шат булдым,
Хезмәт итәр, диеп балам.
Авызымнан яным чыккач,
Еларсың яшең агызып.
Дошман әниең күмелгәч,
Яшәрсең инде ялгызың.
Аягыма басалмагач,
Чыгарып ташладың сарайга.

Күршеләрем ташламады,
Чиксез шөкер бер Ходайга.
Кайталмаслык сәфәр китәм,
Бәхиллегем алалмадың.
Төне буе кычкырып чыктым,
Авыруыма түзәлмичә,
Тынычлап ятып йокладың,
Урыныңнан кузгалмыйча.
Фәридәңне дә багам бит,
Көчем җиткән эшең эшлим.
Кайтасың да җәберлисең,
Кая барыйм, инде нишлим.
Газиз балам хурланганга,
Каным таша, яшьләр урынына,
Шул яшьләрем күздән китмәенчә,
Китәм ахры кабер юлына.
Чылтыр-чылтыр су акканда,
Мин егълыймын таңнар атканда.
Оныта алмам балам хурлавыңны,
Салкын кабердә ятканда да.

*Карамалы-Бузат авылында*
*Гыйльманова Хәдичә Ибраһим кызыннан (67 яшь)*
*язып алынган*

**Мәхәббәт нишләтә**

Авыл җире бигрәк матур була
Җәй көнендә күңел ачарга.
Суы матур, урманнары була
Йөрәк әрнегәнне басарга.
Шундый бер авылда кече яшьтән
Ике бала уйнап үстеләр.
Рәхәтен дә, кыенын да,
Барысын да бергә кичтеләр.
Кызы Алсу, матур йөзле,
Басынкы да, җырчы-биюче.

Тик нигәдер үзе аз сүзле.
Зәңгәр күзләр кара керфекләре аша,
Еракларга карап торалар.
Унбиш яшьтәге авыл егетләре
Бу яшь кызга гашыйк булалар.
Бүген бәйрәм, бөтен халык
Әзерләнеп бәйрәм көтәләр.
Кич җиткәчтен, безнең Алсуны да
Бәйрәмгә дип алып китәләр.
Көндәгечә җәйдем сеңлемә урын,
Кояш батып, караңгы төшә,
Түзеп булмый йөрәк әрнүгә.
Кояш бата моңсу офыкта,
Уенга дип яшьләр киләләр.
Алсу да бит кайнап-көлеп йөри,
Ә егетләр нидер уйлыйлар.
Алсу башта биеп китә,
Ә Таһиры гармун уйната.
Моңсу караш ташлап еракларга,
Акрын гына аны күзәтә.
Шул чак бер лейтенант килеп,
Алып китә танцы итәргә.
Алар бу кич озак сөйләштеләр,
Сәгать уникене сукканчы.
Сөйгән егете гүзәл Таһирның
Күзләреннән яшьләр чыкканчы.
Уен бетте, таралдылар,
Таралдылар, кайтып киттеләр.
Зифа буйлы матур кызлар
Сөйгән егетләрен көттеләр.
Таһир кайтты, куйды гармунын,
Үзе ятты койга өстенә.
Күз алдына килде сөйгән яры,
Кайнар яшьләр килде күзенә.

Кесәсеннән алды кинжалын,
Белмим хәзер нәрсә эшләргә!
Болытлы көн, караңгы төн булды,
Бер гөнаһсыз үскән Таһирга.
Чәнчелде Таһир кинжалына
Ул уйлады утта янарга.
Үләргә берничә сәгать калды,
Хат язарга кызга теләде.
«Алсу бәгърем, ничек сөям сине,
Шулай янам учак утында.
Рәхәт яшә лейтенантың белән
Ертып ташла, алып укы да...»
Урманнарда гөлләр чәчәк атты,
Кошлар сайрый урман буенда.
Җан бирәчәк Таһир шушы таңда,
Көчле сөю кала Алсуда.
Шулай итеп, Таһир көлгә калды,
Ә Алсуы сары яфракка.
Көн елады Алсу, төн елады,
Йөзен сөреп, көл һәм туфракка.
Эх син, былбыл, ник әйтмәдең?!
Бүген төнлә Таһир үлә, дип.
Ике көннән Алсу хыялланды,
Я туктый ул, елый, моңлана.
Я булмаса әйтеп ул куя:
«Шул сүзеңне Таһир куйсана».
Бер көн шулай иртән торып,
Алсу барган ялгыз каенга.
Кулъяулыгын бүләк итеп куйган,
Җан сөйгәне Таһир кулына.
Хыялланган гүзәл Алсу
Асылынган бөдрә каенга.
Кесәсендә язган хаты калган:
«Китәм, Таһир, синең яныңа».

Кызганыч итеп кәккүк чакыра,
Ике гашыйк дөнья куйды,
Юк бит алар, диеп дөньяда.
Төн авышкач иптәшләре
Әкрен генә кабер казыдылар.
Ике яшь йөрәкне, мәхәббәтне
Бер кабергә күмеп куйдылар.
Йолкынмаслык булсын беренче мәхәббәт,
Йөрәктә бит аның тамыры.
Беренче мәхәбәт бит ул газапның
Иң авыры.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Рысаева Зәһибәдән (42 яшь)*
*язып алынган*

**Маһира бәете**

Төзегәннәр шәһәр уртасына,
Түбәсенә чыккан сөреме.
Кайберәүләр көтә Яңа елны,
Кайберәүләр көтә үлемне.
Кайберәүләр сорап кайтып киткән,
Яңа елны өйдә үткәрә.
Кайтмаганнар башын түбән иеп,
Отбой минутларын җиткерә.
Бүген бәйрәм, бар да бәйрәм итә,
Бәйрәм котлап бокал күтәрә.
Ә авырулар бүген бәйрәм көннең
Соңгы минутларын санап үткәрә.
Җиңелрәк булган авырулар
Үзләренчә бәйрәм үткәрә.
Үзләренә салган даруларны
Чәкештергән булып эчәләр.
Ак халатлы шәфкать туташлары
Сөйли яңа бәхет турында:
«Кайгырмагыз, тиздән кайтырсыз», – ди,

Шприцын тоткан кулына.
Бикле ишек, ябык тәрәзәгә
Карап үтә бәйрәм көннәре.
Җитәр микән шушы авыруларның
Сау бул, больнис, дигән көннәре.
Һәр тәрәздә утлар кабынганнар,
Сәгать унбер, Яңа ел да җитә,
Күзен йомып ак койкага яткан
Авыру кеше үзенә ни көтә?
Яңа елның таңы үзе белән
Бик күпләргә бәхет китерә.
Безнең кебек яткан авыруларга
Явыз үлем бәлки китерә.

**Нәзирә бәете**

Көз бик суык, өшерсең дип,
Әнием шәлләр яба башыма.
Энҗе бөртегедәй яшьләр тама,
Ә уйларым сыймый башыма.
Ул бит мине озата больнисларга,
Түгел бит ул курорт, кунакка.
Больнис сүзен ишетү бик кыен ул,
Аның тәмен белгән йөрәккә.
Хәлем авыр минем, шуңа күрә
Әнием уйлый мине үләр дип.
Яңакларым буйлап ага күз яшьләре,
Тотып торма, мине җибәр дип.
Үз аягым белән атлап тышка чыктым,
Тышта тормыш шундый күңелле.
Ничек бер Аллага әрнешмисең,
Шул тормыштан өзсә гомереңне.
Сау булыгыз, газиз туганнарым,
Тәтер буйларын башка күралмам.
Бер карыймын борылып-борылып,
Әҗәл белән тоташ уйларым.

Тагын бер кат борылып йортка карыйм:
Кызым тора капка төбендә.
Сабый, күңеле белән елый-елый,
Озата ул мине бүген дә.
Күзләремне текәп шул балага,
Әрним бәхетләре юклыкка.
Сары чәчен җилләр тарый,
Хуш, әнием, диеп кул селкә.
Аның чәчләреннән үткән җилләр
Исеп килеп минем яныма.
Үтә кереп минем йөрәгемә,
Әрнер өчен гомер буена.
Аның өчен шушы минутларда
Калмагандыр дөнья кирәге.
Синңа калдырмыйча, тагын кемгә
Калдырыйм соң, әнием, баламны.
Бәлки ул да сине шулай сөяр,
Мин сөйгәндәй газиз анамны.
Әни, минем хакка син дә ярат,
Кагучылар булса, кактырма.
Мин балаңны салкын каберләрдә,
Кайгы эчләрендә яткырма.

**Бүләк бәете**

Мин хисләнеп уйлап утырам бүген,
Туган көне нәни кызымның.
Кара каләм шигырь юлын сыза,
Кайнар яше тама күземнең.
Кулыма алып тәү кат сөйгән идем,
Карый-карый зәңгәр күзеңә.
Шатлык белән кысып күкрәгемә,
Шатлык иде үзе ана булу.
Бала булгач минем кулымда
Башта уйламыйча шатланганмын,
Ни булсын тормыш юлында.

Елмаештык, битен ачып карап,
Беребез – ата, беребез – ана, дип.
Менә бүген биш яшь булган аңа,
Нигә йөзгә карап көлмәсен.
Ата ташлап киткәч оныткандыр,
Калмагандыр канында.
Ана больницада – бик еракта,
Бала зур әбисе янында.
Ата каршыламый туган көнен,
Ана каршылап та тотканда.
Кызым, сине туган көнең белән,
Берни бүләк итә алмыймын.
Ә шулай да сиңа бер кечкенә
Бүләксез дә торып калмадым.
Хатка салам шушы бүләгемне,
Кысам, кызым, нәни кулыңны.
Менә, кызым, сиңа әниең йөрәге,
Бүләк ит шигырь юлларын.

*Бәетләр Абдуллина Сәрбиямал әбинең*
*дәфтәреннән күчереп алынган.*
*Аларны Маһирә әбигә кызы Нәзирә*
*җибәргән*

**Зөмәрә турында бәет**

Уфаларга барам диеп,
Өсләренә киядер.
Аерылып каласың дип, газиз улын сөядер.
Машиналарга утыргач, бер карады каерылып.
Карамас иде каерылып, улы калды аерылып.
Больнисларга киткәненә инде хәзер ел булды.
Сигез бала арасында бәхетсезе ул булды.
Исән йөргән чакларында Уфа буен буйлыйдыр,
Операция ясагач, терелермен дип уйлыйдыр.
Өсләремә кара күлмәк, кисәң иде алып, ди.
Әрнемәс идем, шул чакта яннарымда булсаң, ди.

Ике метр тасма алдым чәчләремне үрергә.
Ходай миңа шулай язган, гелән хәсрәт күрергә.
Больнисларга барып кергәч, ак халатын киядер.
Операциягә кергәч, улым кала диядер.
Операция ясыйлар, ак халатларын киеп,
Өстәлләрдә ята микән, инде ни булыр диеп.
Уфаларга барган чакта
Өсләренә киенә,
Телеграммасы килгәч,
Туганнары сөенә.

**Шәкүр бәете**

Аклы яулык юып элдем,
Аны җилләр киптерә.
Үле хәбәрләре килгәч,
Дежурныйлар китерә.
Кичләр булгач, Уфаларда
Утлары кабынадыр.
Больнисларда яткан чакта
Улларым сагынадыр.
Сандугачның балалары,
Басып сайрый талларга.
Операция ясагач,
Буялгандыр каннарга.
Кайтырмын, дип йөрәгендә,
Больнисларга салдылар.
Рөхсәтләр сорамыйча,
Алып кереп ярдылар.
Кулымдагы балдагымның
Исеме Бибисара,
Ярган чакта «Алла» диеп
Кычкыргандыр бичара.
Уфаларга барган чакта
Уйлата барганнар,
Бер урыннан бер урынга

Алып барып ярганнар.
Уфа таулары биек.
Туганнарына сөйләгән
Өйгә кайтамын диеп.
Кара чалбарларын кисә,
Кысып тора билләрен,
Больнисларда үлеп калды
Күрәлмәде илләрен.
Уфаларга барган чакта
Иртән торып киенә.
Әтиебез кайта диеп,
Балалары сөенә.
Биек тауның башларында
Матур Уфа каласы.
Әрнеп үлде, үлгән чакта
Булмады бер баласы.
Аклы ситсы күлмәккәең
Кояшта уңмагандыр.
Сигез баланы үстереп,
Берсе дә булмагандыр.
Сугышлардан сау-сәламәт
Йөреп кайтты илләргә.
Илле җиде яшьлегендә
Керде кара гүрләргә.
Больнисларга барып кергәч,
Киемнәрен элгәндер,
Болай әрнешеп үлүе,
Төшләренә кергәндер.
Уйламыйча барды микән,
Уфаларга барганда.
Кайталмасын белде микән,
Врач кереп ярганда.
Уфаларга киткән чакта
Карагандыр каерылып,
Ул караса да каерылып,

Йорты калды аерылып.
Больнисларның ишегенә
Вывескалар эленгән.
Телеграммалар килде,
Үлде, диеп әйтелгән.
Атлар кешнәде микән,
Врачлар җыелып кергәч,
Бахыр нишләде икән?
Машиналарга утыргач,
Карап бара юлларга.
Үлде, әрнүләре калды
Гомер буе еларга.
Кошлар сайрый гөлләрдә.
Ничек итеп түзде икән,
Шундый авыр көннәрдә.
Уфа дигән зур кала.
Уфаларда үлеп калды,
Җыен бәхетсез бала.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Абдуллина Сәрбиямалның (60 яшь)*
*үзе язган бәетләр дәфтәреннән күчереп алынган*

**Ятим әби бәете**

9 ай күтәреп йөрдем,
Тугач та ак сөтем бирдем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хикмәт,
Баладан катылык күрдем.
Анага бала бик татлы,
Тугач та тәннәрен пакьли.
Бу ни гаҗәп, бу ни хикмәт,
Ана күңелен бала тапмый.
Ананы үлми дисәләр дә,
Вакытсыз кермисең гүргә.
Бу ни гаҗәп, бу ни хикмәт,
Ананы сөймиләр бер дә.

Ананы күп ашый диеп,
Авырсыналар тамагын.
Җитәр, күп ашама, диеп.
Алып куйдылар табагын.
Җыеп куйсыннар табаны,
Аларга да килеп җитәр.
Карый булган көннәремдә
Исләренә килеп төшәр.
Мин белгәннәр, мин күргәннәр,
И мөселман хәрендәшләр.
Карый булган көннәремдә
Ни күрмәде бу башларым.
Балаларымны үстердем,
Бәхет-шәфкатьләрен көтеп.
Шушы хәлләргә ирештем,
60 яшьләремә җитеп.
Бер ир бала үстергәчтен,
Башым калды кадерсезгә.
Гаеп итмәгез, дусларым,
Хәлемне сөйлим сезгә.
Өмет итеп үстердем мин,
Балаларым кадерле итеп.
Карый булган көннәремдә
Кадер-хөрмәт итәр диеп.
Рәхәт күрмәде бу башым,
Күземнән туктамый яшем,
Кайда минем кайнар ашым,
Сабырлык бир үзең, Алла.
Баламның күзенә карыйм,
Ике күземне тутырып.
Йөзләре караңгы булгач,
Җылыйм күзләрем тутырып.
Үлем ачылары күреп,
Балам, сине китердем.

Авыр-фәкыйрь вакытларда
Балам, сине үстердем.
Балам ачка үлмәсен дип
Ризыклар таба идем.
Балам, өши күрмә, диеп,
Өсләреңә яба идем.
Ни чәчсәң, шуны урырсың, дип
Әйткән өчен борынгылар,
Озакламыйча килеп җитәр
Миңа күрсәткән «яхшылыклар».
Бу бәет гаеп булмасын,
Гыйбрәт өчен – мин белгәннәр,
Ясин укып, дога кылып,
Яшьләр белән тулган күзем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хикмәт,
Бар да ялган минем сүзем.
Кемнәр ясин укыр микән,
Төн урталарында үлсәм.
Йортларымнан чыкмас идем,
Болай буласымны белсәм.
Кайтыр идем өйләремә,
Озатучым булыр микән.
Үлгән чакта авызыма
Су салучы булыр микән.
Юлларга чыгып үлсәм,
Сөягемне кемнәр җыяр.
И Ходаем, ни кылаем?
Җеназа укып кемнәр куяр?!
Бәхетле булган ата-ана
Баласыннан рәхәт күрә.
Тәүфыйклы булган балалар
Ата-ананың кадерен белә.
Шулай тәрбияләр белән
Үстердем мин балаларны.

Түлке яратмыйлар икән
Картайгачтын аналарны.
Атасы чакырды үләр чакта,
Янына килмәде балам.
Бала бәгыре каты икән,
Бәхиллек сорамады балам.
Торган җирдән, туган җирдән
Кемнәр генә ташлап китә.
Эчәсе су, ашыйсы аш
Үзе җитәкләп алып китә.
Әнкә күңеле балада,
Бала күңелләре далада.
Ничә еллар синең өчен
Кайгы эчләрендә йөргән,
Салкын сулышларга түзгән
Синең анаң мин түгелме?
Өс-башыңны аклаган,
Яман эшләрдән саклаган
Газиз анаң мин түгелме?
Яманга күзеңне салма,
Дөнья малына алданма.
Ахирәттән мәхрүм калма,
Газиз балам, шуны аңла.
Дөнья шатлыгын күрмәгән,
Тәңре-Алла гомер сөрмәгән,
Күп авырлыкларга түзгән
Газиз анаң мин түгелме?
Кулымнан эшләрем китте,
Тәнемнең куәте бетте.
Озакламый кара гүргә
Керер вакытларым җитте.
Әйтә алмыйм,
Канлы яшь алды күземне,
Яра басты йөземне.
Синең анаң мин түгелме?

Үләр идем, үләр хәл юк,
Бу кайгыга түзәр хәл юк.
Ходаның кушкан хәлләрен
Көн элгәре белеп булмый.
Күккә баксам, күзем тала,
Йөзем сары, кайгы баса,
Синең анаң мин түгелме?

*Бузат авылында*
*Әсфәндиярова Әминәдән (1903 елгы)*
*язып алынган*

**Бәет**

Кала минем якты дөньяларым,
Кала минем газиз балаларым.
Торып калса да, ташлап китәм,
Ямьлек кызы яр-яланнарын.
Асылындым каен ботагына,
Каен ботакларын талдырдым,
Ачуланма мине, Зөһрә кызым,
Йөрәгеңә утлар калдырдым.
Көн дә торып чыгып киттем
Көтүләр көтәргә далага.
Каен төпләрендә эз калдырдым
Ике бөртек газиз балама.
Йөрәгемдә ниләр барын,
Зөһрә кызым, белмәдең.
Соңгы тапкыр күрергә дип,
Чакырганда килмәдең.
Ничә еллар буе йөрәгемдә
Нинди генә серләр йөрделәр,
Каберемне ерак казымагыз,
Вәрис улым белән Зөһрә кызым
Үткән саен кереп күрерләр.
Туганнарым җыелышып килеп,
Күмгәннәрдер мине гүрләргә,

Якты дөньяларда кайгылардан
Бушый алмадым мин бер дә.
Зөһрә кызым, Вәрис улым,
Уйларымны сез дә беләсез,
Бәйрәм көннәрендә каберемә,
Икәү җитәкләшеп килегез.
Туганнарым минем йөрәгемне
Күргәнсездер инде ярганда,
Нинди ут эчләрендә яндыгыз,
Мине каберләргә салганда.

*Айтуган авылында*
*Камалова Сәриядән (35 яшь)*
*язып алынган*

**Күгәрчен**

Ай күгәрчен, син гөрлисең,
Хәлләремне белмисең.
Өзелеп-өзелеп син гөрлисең,
Мин җылыймын, күрмисең.
Кай илләрдән очып килдең,
Безнең илдән түгелме?
Синең матур гүләүләрең,
Юата күңелемне.
Синең кебек оча белсәм,
Җаныңа кайтыр идем,
Төн йокыларым йокламый,
Сөйләшеп ятыр идем.
Күгәрченем, сиңа әйтәм,
Тыңлачы сүзләремне.
Ерак китте балаларым,
Саргайтты йөзләремне.
Безнең илдән очар булсаң,
Күрсәң балакаемны,
Минем хәлне сөйлә аңа,
Ничек торганнарымны.

Минем баламны күрер булсаң,
Сәламемне әйтсәнә.
Белеп ни хәлдә торганын
Кире урап кайтсана.
Очып китте күгәрченем,
Очып килмәде безгә.
Көтеп торам, очып килми,
Кан сауды ике күзгә.
Көтә торган күгәрченем,
Очып килде кыекка.
Миңа гөрли, миңа сөйли,
Минем күңелем боекка.
Ай күгәрчен, кайдан килдең,
Канатларың талдырып.
Балаларым ташлап китте,
Мине ятим калдырып.
Тамагым ач, ашау үтми,
Көн буена уйлыйм мин.
Кич ятсам да, йокларга дип,
Йоклый алмый уйлыйм мин.

*Кызылъяр авылында*
*Галиева Оркыядан (67 яшьтә)*
*язып алынган*

### ***Борынгы солдатлар бәете***

Бисмилла дип башладым
Бу мөнәҗәт башларын.
Бу михнәткә дучар булды
Минем газиз башларым.

Безнең яткан казарманың
Асты кирпеч, өсте таш.
Кошлар очып җитмәс җиргә
Китте безнең газиз баш.

Иртә торып, сәхрәләргә чыгып,
Киттем сәфәргә.
Сәфәрләрдә озак юл,
Туганнарым, бәхил бул.

Безнең ризыкка язды микән,
Әткәй чәчкән бодаең.
Туып-үскән илләремнән,
Аерды бит Ходаем.

Авыр мылтык күтәреп,
Талды минем беләгем.
«Смирно!» дип кычкырганда,
Калтырый минем йөрәгем.

Телеграмм килеп төште,
Сәгать биштә китәргә.
Бер уйлыймын, бер елыймын,
Белмим нихәл итәргә.

Без мескеннең тамагын,
Туйдырмыйлар ашарга.
Хак Тәгалә ни язды икән,
Безнең башларга.

Без чыгабыз уенга,
Таш казарма буена.
Үзем патша кулында,
Күзем кайту юлында.

Ырымбурдан чыкканда,
Сулга таба аерма.
Дошманнарга гаеп булдым,
Иманымнан аерма.

Утырдым да яздым мин,
Ак кәгазьләрне буяп,
Кызыл йөзем сары булды
Туган илләрне уйлап.

Ырымбурдан чыккачтын,
Күрдем Самар каласын.
И туганнар, ышанмагыз,
Кош та онытмый баласын.

Сандугачлар килгән безгә,
Китәрләр микән көзгә.
Исән йөреп, саулар кайтсын дип,
Дога кылыгыз безгә.

Өстемдәге бишмәтем,
Үз өстемдә тузмады.
Егет булып үсеп җиткәч,
Үз илемдә узмады.

Башымдагы фуражкам,
Очып барган кош кебек,
Үзем көфер кулында,
Канаты сынган кош кебек.

Биек тауның башында,
Чәчәк ата көнбагыш,
Эчем тулы хәсрәт уты,
Кемгә сөйлим мин башлап.

Иртә томан, кич тә томан,
Кавказ тавы буйлары.
Эчем тулы учак уты,
Басмый дәрья сулары.

Зәек – Сакмар арасында
Калды Ырымбур даласы.
Кайда йөрми,ниләр күрми
Газиз ата баласы.

Бу бәетне яздым,
Өстәлләргә таянып.
Көне-төне елаганга,
Бетте яшем коелып.

Бәнем чәчкән ашлыкларны,
Әткәм, инде кем җыяр,
Бу сугышта вафат булсак,
Җеназа укып кем куяр.

Без торабыз часовойда,
Тар шинельләр ябынып.
Торган җирдә кошлар күрәм,
Торам туган җирне сагынып.

Әткәй елый ат җиккәч,
Кайтмас, диеп, бер киткәч.
Елама, әткәй, түкмә яшең,
Кайтырбыз вакыт җиткәч.

Утыртып алып киттеләр
Безне атсыз арбага.
Елый-елый зекер әйтеп,
Согынабыз Аллага.

Ырымбурдан чыккач та
Барып кердем Самарга,
480 полковник
Тезеп куйдым санарга.

*Шәрипова Мәхупҗамал Әһлетдин кызыннан (66 яшьтә) язып алынган.*

**Хода Кәрим**

*(Бәдәвам көенә җырлана)*

Хода Кәрим, Хода Кәрим,
Синең рәхмәтеңә карыйм,
Синең рәхмәтең дип башка
Югыйсә мин кая барыйм.

Илаһи хак Кәрим Алла,
Гөнаһымны кабул әйлә.
Гөнаһымны кабул әйләп,
Бәхетле кыл, Тәгалә Алла.

Кеше хәлен кеше белми,
Янар бәгырь уты сүнми,
Бу дөньяда кеше үлми,
Әҗәлләргә ирешмичә.

*Рысаева Зарифа Лотфрахман*
*кызыннан (76 яшь) язып алынган*

### 1917–1918 елларда шахтада үлгән кеше турында бәет

Кайтып күрергә насыйп булмады,
Ике күзем карасы.
Газиз балакаем вафат булды,
Калды ятим ике баласы.

Яман хәбәр килеп төште
Кайтып күрәм, диеп торганда.
Нинди төшләр күреп ятыйм икән,
Балакаем янын[1] биргәндә.

Күзләремнән югалганчы,
Истә кул болгаулары.
Эчләремне шунысы өзә,
Киткәндә елаулары.

Исә җилләр, үсә гөлләр,
Өзә гөлнең чәчәген.
Алга килми, һичкем белми
Башы ни күрәчәген.

Күңелләре тартмаса да,
Кергәндер шахта эченә.
Балакаем болай буласы
Кереп торды минем төшемә.

---

[1] Янын – җанын.

Өй эчендә үстергән
Зәгафрән гөл исе.
Гөлгә кунып сайраган
Көн дә былбылым иде.

Яз булгач та чәчәк ата,
Балам чәчкән гөлләре.
Азакы минутларында
Шахта булган гүрләре.

## Әткәй сугышта, әнкәй тормышта

*(бәет)*

Әткәйнең хаты мин тугач килгән,
Исемен Наил куегыз, дигән.

Әткәй киткәндә, тумаган идем,
Әткәй киткәндә, йоклаган идем.

Китәсе көнне кочаклап ятты,
Чыгып киткәндә өстемә япты.

И балам, диде, күз нурым, диде,
Каласың инде, бәгырем, диде.

Әткәй сине эзлим – табалмыйм,
Йөгереп йөрим түр дип почмакка.

Әнкәй үстерде бишеккә салып,
Мәхрүм итте, китмәде алып.

Итек эчендә туңды аягым,
Кайгыларга барыйм инде, Ходаем.

Газиз әнкәем, бер сүз әйтәем,
Сабыр ит, әнкәй, кайтыр әткәем.

Бергә торырбыз, бергә йөрербез,
Тигезлек белән рәхәт күрербез.

Иптәшләремнең аналары бар,
Аналарының җылы куены бар.

Газиз әткәем көйгәндер инде,
Каласың, балам, дигәндер инде.

Утырып җырлыйм
Ике кулымны битемә куеп,
Башымны салып утырам як-якка,
Яшьләрем ага башым якка.

Ятып йокладым, үксеп еладым,
Җылый аналар, җылый аталар,
Җылама җаным, диеп мине юаталар.

Нихәл итәем, калдым чын ятим,
Әти-әни, дип кемнәргә әйтим.

Анам булмагач, читен шулчаклы,
Өйләргә кайтсам, ишеге бикле.
Буйларым җитми минем ачкычка,
Ятып йокладым салкын баскычка.

Канатым сынды, бер дә алалмыйм,
Газиз әнкәемне бер дә оныта алмыйм.

Анага бала кадерле була,
Көннәрдән беркөн мәхрүм була.

Имән агачы, каты күмере,
Минем анамның каты күңеле.

Итекләрем юк минем киярגә,
Атам-анам юк минем сөяргә.

Яма әле, әнкәй, минем чалбарны,
Килмидер әнкәй белергә хәлемне.

Ятим калырга һич тә белмәдем,
Анамның йөзен һич тә күрмәдем.

Яма әле, әнкәй, бишмәтләремне,
Белергә килми һич тә хәлемне.

Кечкенәдән үк юктыр бәхетем,
Ата-анамның күрмим рәхәтен.

Минем кебекләр ятим калмасын,
Елама, әнкәй, үзең ташладың.
Тилмереп йөрим, төшәр яшьләрем,
Кайларда яшәр газиз башларым.

Зәңгәрле иде әнкәй күлмәге,
Ташлап китсә дә рәхәт күрмәде.

Иптәш булганы чыгара куып,
Йөри әнкәй кешедә кунып.
Ул да елады, мин дә еладым,
Ходай язгандыр, диеп уйладым.

Су буйларында каз бәбкәләре,
Җыеп йөретә үз әнкәләре.

Иптәшем белән уйнаган булам,
Үземне юатып, җырлаган булам.

Атам сугышта, әнкәй тормышта,
Газиз башларым каты сагышта.

Әнкәем, кайда синең эзләрең,
Күреп туймады минем күзләрем.

Әнкәем, сиңа кем ата булды,
Мине ташлавың нык хата булды.

Әнкәй, син мине нигә соң таптың,
Газиз башыма утларың яктың.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Галиева Зөбәрҗәттән (1911 елгы)*
*язып алынган*

**Муса Җәлилнең әнисенең балаларына язган мөнәҗәте**

Бик нык авырдым, балам.
Үлсәм күрәлми калам.
Зарланып бер хат язам,
Уйлап карагыз, балам.
Бик сагындым сезләрне,
Бигрәк тә кызларны.
Иртән торсам да көтәм,
Кичен ятсам да көтәм.
Синең өчен ут йотам,
Уйлап карагыз, балам.
Читтә йөргән балалар
Күп кайгылар салалар.
Ахры җанымны алалар,
Уйлап карагыз, балалар.
Ана күңеле балада,
Бала күңеле далада.
Шул сүз рас чамада,
Уйлап карагыз, балам.
Дөньяда бар дүрт балам,
Берсен дә күрми калам,
Шулай язгандыр, Аллам,
Уйлап карагыз, балам.
Төшемдә күреп уянам,
Аны сөйләп куанам.
Кайтырлар, дип юанам,
Уйлап карагыз, балам.
Чит илдә сез үзегез,
Хәтта килә сүзегез.
Үзәгемне өзәсез,
Уйлап карагыз, балам.
Халыклар иртә торалар,
Бер-берсен күрәләр.
Хәлләремне күрәләр,
Уйлап карашыгыз, балам.

Мин дә иртә торамын,
Хатыгызны күтәмен.
Юксынып, аһ итәмен,
Уйлап карагыз, балам.
Казаннарга да бардым,
Оренбургта да тордым.
Ахыр аерылып үләмен,
Уйлап карагыз, балам.
Мине больнис алмады,
Духтырлар күз салмады.
Барыр җирем калмады,
Уйлап карагыз, балам.
Монда яздым сүземне,
Күрә алмассыз үземне.
Саргайттыгыз йөземне,
Уйлап карагыз, балам.
Кече кызым Хәдичә,
Сөя идем һәр кичә.
Үлеп китәм күрмичә,
Сагынган идем, балам.
Үлем хәле каты икән,
Аны һәркем татый икән.
Үлгәч кеше кайтмый икән,
Хафил булмагыз, балам.
Олы улым Ибраһим,
Көтә идем һәр аем.
Миннән васыять шул сиңа,
Искә ал һәр җомгада.
Ибраһим балакаем,
Тыңла минем әйткәнне.
Мине искә алган чакта,
Калдырма әткәеңне.
Зәйнәп белән Хәдичәне
Бүләк итеп калдырам.
Яшь көйгә калалар алар,

Шуңа бигрәк кайгырам.
Сезгә кайгы көннәре,
Сезнең өчен янганнарым
Көйдерәчәк гөлләрне.
Муса улым, сиңа әйтәм,
Туганнарыңны кара.
Миңа үлем вакыты җитте,
Кылып булмый бер чара.
Кара туфрак астында,
Калачак бу тәннәрем.
Берегезне күрә алмадым,
Шуңа әрни җаннарым.
Зәйнәп кызым, сиңа әйтәм,
Тырыш яхшы булырга.
Туганнарың белән бергә,
Тырыш матур торырга.
Зәйнәп, юлда адашмагыз,
Начарлыкны ташлагыз.
Ходай өчен шуны әйтәм,
Начар юлга басмагыз.
Кулыгызда бар вакытта,
Әзрәк хәер бирегез.
Миннән фатиха шул сезгә,
Мәңге игелек күрегез.
Кече кызым Хәдичә,
Йөзләреңнән нур чәчә.
Никадәр үкенсәм дә
Үлеп китәм күрмичә.
Белмәдегез кадеремне,
Күрмәдегез каберемне.
Барыгыз да ташлап китеп,
Яндырдыгыз бәгъремне.
Әҗәл авыруы тиде,
Минем газиз башыма.
Инде хәзер мин барамын

Бер Ходайның каршына.
Нинди тилмереп көтсәм дә,
Килмәдегез каршыма.
Нинди бәхетсезлек килде,
Минем моңлы башыма.
Бер Ходайның тәкъдире,
Безне шулай аерды.
Дүрт балам, дүрт ботак иде,
Бары да миннән аерылды.
Аерылу тиз дә икән,
Аерылгач өмет аз икән.
Аерылуның хәлләренә
Теләсәң ничек түз икән.
И, сөекле кызларым,
Бу минем соңгы сүзләрем
Мәхшәр көне җитмәенчә,
Күрә алмассыз йөзләрем.
Мин китәм ерак сәфәргә,
Ходай хәерле кылсын.
Моны укыган адәмнәр,
Миңа хәерлек кылсын.
Бик күп сүзләр сөйләдем,
Кемнәр тотар сөягем.
Никадәр сагынсам да,
Сабырлыклар теләдем.
Кара җирнең астында
Черәячәк тәннәрем.
Ахры алып китәм инде
Әчемә җыйган гамьнәрем.
Ибраһим, Муса, Хәдичә, Зәйнәп,
Хуш, сау булыгыз.
Исән вакытта дөньяда
Бергә матур торыгыз.

*Хәбибуллина Әминә әби*
*Оренбургтан язып алып кайткан*

## Совет власте турында мөнәҗәт

Мин үтенәм сез яшьләргә,
Рәхмәт әйтеп картларга.
Җиң сызганып, без эшләдек
Колхоз чыккан чакларда.

Үзе ура, үзе суга,
Үзе хәзер комбайн.
Иртә таңнан урак тотып,
Китә идек көн саен.

Сырттан сыртка җәяү йөрдек,
Утырмадык атларга.
Җиң сызганып, без эшләдек
Колхоз чыккан чакларда.

Машиналар аз булгачтын,
Җитешмәде атлар да.
Сыер җигеп тырмый идек,
Ашлык чәчкән чакларда.

Эш күп булгач, без дә йөрдек
Тырмада да, сабанда.
Эш хакына бер чүмеч аш,
Төшә иде яланда.

Безнең басу матур була,
Үлән чәчәк атканда!
Без эшләрдән кайта идек,
Төндә шәфәкъ батканда.

Элегрәк без яшәдек
Тула чикмән, тун киеп,
Без колхозда күп эшләдек,
Ярты кадак он диеп.

Хөкүмәткә тырышып эшләп,
Бирә идек яхшысын.
Совет иле яшәсен диеп,
Ашый идек көрпәсен.

Колхоз чыккач, без укыдык,
Картларский класста,
Көне-төне тырышып эшләп,
Без төзедек властьне.

Үзе сөрә, үзе яра
Колхозларның зур аты.
Без яшәдек михнәтендә,
Менә хәзер рәхәте.

Иркенлектә-иркенлектә,
Ашамакта-эчмәктә,
Николай патша чагында
Без яшәдек михнәттә.

Кызарып пешкән алманы,
Җәй көнендә ашыйбыз,
Яшәсен совет власте
Иркенлектә яшибез.

Элек киндер кия идек,
Хәзер атлас киябез.
Яшәсен совет власте,
Яшәсен партиябез.

Мондый шатлык, мондый байлык
Килмәде бер заманда,
Безгә якты тормыш бирде,
Рәхмәт Ленин бабайга.

Җәй көнендә күбәләкләр
Очып йөри чәчәктә.
Совет иле тыныч булгач,
Без яшибез рәхәттә.

Шушы эшләр барысы да
Үтте безнең башлардан.
Алдыйлар дип уйламагыз,
Сорашыгыз картлардан.

Көлтәләрдән сала идек
Зур-зур итеп кибәннәр.
Эшләгәннәр бар да белер,
Белмәс эшләмәгәннәр.

*Йосыпова Зәлифә Айдарәле кызыннан (71 яшь)*
*язып алынган.*

## МӨНӘҖӘТЛӘР

Бу гомерләр үтеп китәр,
Үлем вакытлары килеп җитәр,
Бу гомернең үтүе бар,
Безгә ул да килеп җитәр.

Озакламый үлем килер,
Аерылыр җаным тәннән,
Беркемгә дә мөмкин түгел,
Качып калу бу үлемдин.

Ахрый киемем – кәфен,
Ахрый урыным – ләхет.
Тәнем озак кортлар өчен,
Юлдаш илә иманымны.

*Тәтер-Арслан авылында*
*Мирзаева Закирәдән (70 яшь)*
*язып алынган*

## Әҗәл ширбәте

Әҗәл ширбәтен дә бер мин эчәрмен,
Якты дөньядан да бер мин күчәрмен.
Якты дөньяны күреп туймадым,
Күреп туймасам да, мәңге тормадым.

Әҗәлем җитте, тыннарым бетте,
Ясин укырга вакытым җитте.
Укый алмыймын, бик тар сулышым,
Булсын минем дога кылучым.
Килер газраил, җанымны алыр,
Кызыл йөзләрем сарыга калыр.
Яхшы дөньяны ташлап китәрбез,
Караңгы гүрдә нихәл итәрбез.
Караңгы гүрдә булыр бу башым,
Газиз иманым булыр юлдашым.
Мөшкел хәл икән җан бирүләре,
Авыр хәл икән гүргә керүләре.
Шатланыр идем, атнакич үлсәм,
Җомгага хәтле гүремә керсәм.
Җанымны алсын атнакичендә,
Җан кылмаем каберем эчендә.
Килер дусларым, җыела башларлар,
Күлмәкләремне алып ташларлар,
Кабыкка салып тәнемне юарлар,
Тәнемне пакьлагач кәфенгә салырлар.
Зифа буемны каты юмагыз,
Кире кайтмамын, ашыктырмагыз.
Тордым дөньяда бераз вакытлар,
Салкын туфраклы безгә ястыклар.
Каберем өстенә гөлләр чәчегез,
Агач утырдып, нурландырыгыз.
Яфраклар ярсын, кошлар сайрасын,
Рухым шат булсын, догалар барсын.
Үләннәр үссен каберем өстендә,
Матур нур булсын каберем эчендә.
Бу дөньяларда йөреп туймадым,
Туймасам да мәңге тормадым.
Сезгә, дусларым, актык сүзләрем,
Бу дөньяда рәхәт күрмәдем.
Күзләрем йомсам, күзләрем тала,

Барча дусларым дөньяда кала.
Зифа буемны үлгәч алыгыз,
Юып пакьлагыз, кәфенгә салыгыз.
Тәннәрем зәгыйфь, каты юмагыз.
Кире кайтмамын, ашыктырмагыз.
Җаным чыкканда, янымда торыгыз,
Шаһит булсын дип, дога кылыгыз.
Күкрәгем кыса, тыннарым бетә,
Ясин чыгыгыз, вакытым җитә.
Җаным чыкканда, килегез каршыма,
Борып салыгыз кыйбла каршына.
Искә төшкәндә укып карагыз,
Укып карагач, дога кылыгыз.
Догалар барса, гүрем яктырыр,
Дога кылсагыз, рухым шат булыр.
Барырбыз бергә караңгы гүргә,
Бер кайтмаслык мәңгелек йортка.
Озын төннәрдә, салкын гүрләрдә
Яндыра безне үлем хәлләре.
Якты дөньяда калыр исмебез,
Исәпләсәгез калыр исегез.
Күңелем төшмәде, кулым бармады,
Исәпләр-уйлар миннән калмады.
Каршы басып сайрый бер тургай,
Ризыклар беткәч, тәкъдирләр шулай.
Йокым килмәде азакка төннәрдә,
Ризык җыймадым азакка көннәрдә.
Яткан урыным бик рәхәт иде,
Үлемем каты, телләрем талды.
Кулымны суздым, күңелемне боздым,
Куып киткәннәр, мин ни хәл түздем.
Уйлар уйлыймын чыгып китәргә,
Чыгып булмый бит ни хәл итәргә?
Йөзем уелган, нуры коелган.
Сөйләшә алмыйм, телем уелган.

Иптәш калмаган, ялгыз кош кебек,
Уянып китсәм, йоклаган кебек.
Үлгән кешенең хәбәре килми,
Яхшы-яманны һичкем дә белми.
Бигрәк юксынам иптәшем юкка,
Куеп киткәннәр мәңгелек йортка.
Ялгыз калганмын, исән булыгыз,
Атнакичләрдә дога кылыгыз.

*Бузат авылында*
*Әсфәндиярова Әминәдән (1903 елгы)*
*язып алынган.*

**Мөнәҗәт**

Яфасы күп бу дөньяның
Рәхәтен тапмадым һәргиз.
Гаҗәп, күңелем нигә яна,
Буламын инде дивана.

Фирак утында пәрвана булып,
Күңелем кибеп яна.
Фиракның хәсрәте мөшкел,
Ходай һичкемгә язмасын.

Догада булыгыз зинһар,
Ходаем акылымны алмасын.
Минем эчемдәге нарым,
Җиһанга салсалар барын,
Көйдерер суларын, карын,
Идәрсез барчасын аерым.
Кеше хәлен кеше белми,
Үзенең башына килми.

Күп кайгыда кеше үлми,
Әҗәлләре, Ходаем, җитми.
Ходаем, сәнкари собхан,
Сабыр бир безләргә һәрчак.

Сабыр иткәч, Йосыф киткән
Мисыр эчрә солтан булып.

И Ходаем, сабыр биргел,
Сабырлы бәндәдән кыйлгыл.
Ходай сөя сабырларны,
Сабырлык бир, Илаһым.
Сабырсыз бичара булдым,
Җәрәхәтле күңелләрем,
Бу хәсрәткә дәва тапмый,
Үтә минем гомерләрем.

Бу хәсрәтнең авырлыгын,
Башына килми белми.
Эчендә утлары сүнми,
Кара җирләргә керми.

Бу дөнья фанидыр фани,
Кем үткәргән рәхәт аны.
Җәрәхәтле күңелләрем
Чыдый бит акмагач каны.
Ходай тәкъдиредер инде,
Тумас борын язылгандыр,
Гүрстаным – туфрагым,
Минем каян алынгандыр?

*Мусина Зәйнәптән (79 яшь)*
*язып алынган*

Яшь чагымда чиктем ятимлек,
Бигрәк каты, эче яфасын.
Күргән михнәтемне сөйләп бирсәм,
Бертуктамый агар күз яшең.

Әткәй белән әнкәй мин яшь чакта
Бу дөньяда булып үткәннәр.
Яннарыдай күргән балаларын
Ут эченә салып киткәннәр.

Бер рәхимле бәндә мине алып
Асраса да болай йөргәнче.
Булмады язмыш шулай булгач,
Әче тормышларны күрмичә.

Булды минем шулай көннәр буе ач,
Икмәк тапмый торган көннәрем.
Ятарга да урын табалмыйча,
Урамнарда кунган көннәрем.

Көннәр буе елап йөргәнем бар,
Әткәй-әнкәй төшеп исемә.
Кайда миңа мәктәп һәм тәрбия,
Кермәделәр минем төшемә.

Өзгәләнеп кичтем бу тормышымны
Канатларым сынган былбылдай.
Бигрәк кыен икән бу ятимлек,
Дучар итмәсен лә бу Ходай.

Хәсрәт дәрьяларында йөзәмен,
Өзелеп-өзелеп тала беләгем.
Газап күлләреннән сулар эчтем
Ут эчендә яна йөрәгем.

Җырлар язам тауның күкрәгенә
Зинһар димен, җилкәй, тими тор.
Моңлы былбылкаем, куй, сайрама,
Сайрап бәгыремне өзми тор.

Һаваларда төрле кошлар,
Уйный күләгәсе, аның җирдә уйный.
Ата-аналы баланың кулы уйный,
Ата-анасыз баланың күзе уйный.

Ике күзем яшьле, тамагым ач,
Ашар-эчәремә булмагач,
Кем баласын кемнәр кызгансыннар,
Ата-анасына булмагач.

Ялгыз башыкаем, юк юлдашым,
Хәсрәтләремне әйтер моңдамын.
Ата-аналарым үлеп китеп,
Агыздылар минем күз яшем.

Нихәл генә итим мин бичара,
Кайгы хәсрәт йөрәгемне яра.
Үзәгемә михнәт үтеп бара,
Бер ананың эшенә юк чара.

Өзелә генә үзәгем, яна йөрәгем,
Хәсрәт уты эчтә янганга.
Ул көннәремне мин дә күрмәс идем,
Күрешәмендер Ходай кушканча.

Байлар асрый баланы симертеп,
Алма, кәнфит, прәннек кимертеп.
Минем әткәй-әнкәй үлеп китте,
Ике күзләремне тилмертеп.

Ятимлектән күргән күп михнәтләр,
Йөрәгемне суырып киптерде.
Рәхимсезлек итеп күп адәмнәр
Күз яшемне күлдәй түктерде.

Бигрәк кыен икән бу дөньяда
Ата-анадан яшьли калуы.
Авыр михнәт күреп йөдәп беттем,
Күкрәгемне кайгы алуы.

*Хәлекәй авылында*
*Латыйпова Фатыйма Абдулла кызыннан (62 яшь)*
*Р. Халикова язып алган*

## ӘКИЯТЛӘР

### Патша

Борын заманда булган, ди, бер патша. Аның бала-чагасы булмаган. Бер генә хатыны булган. Ул хатын белән киңәш итә. Нишлим мин, ди. Җыялар болар карт-карчыкларны. Мәҗлескә киңәшкә. Арадан бер карчык әйтә. Сиңа, ди, бала бар, ди. Алдындар бер кыз бар. Шул кызны алсаң, бер кыз бала белән ир бала туа, ди. Игез бала. Бүтәнгә бала юк, ди. Шул яшь кызны ала. Шул мәҗлестә инде. Никах укытып, туй ясап. Яшь хатынлыкка инде. 4–5 ай торалар. Хәзер моның белән, алгач. Бу авырга кала. Бу әйтә хәзер хатынга. Мин обходка чыгып китәм, ди. Патша чыгып киткәч, бу кыз чирли хәзер. Чакырта бер колдун дигән хатынны. Бу бала туса, олы хатынга почут бетә. Нәрсә телисең, шуны бирәм, ди олы хатын теге карчыкка, колдунга. Түлке бу балаларны алырга кирәк, ди. Как раз эт балалый. Ике эте бар икән сарайда. Теге карчык йортка ике эт баласы алып керә. Бер ананы, бер атаны. Теге кызның баланы как раз дөньяга китергән вакыты була. Теге ике баланы ала да, кызның куенына теге ике эт баласын сала. Хәзер теге ике балага ящик ясата патшаның карт хатыны. Төнлә ящиктагы балаларны илтә дә суга сала. Бу балалар шул суда китә. Күпме баралар, кая китәләр, пока беркем дә белми бу балалар турында. Олы хатын хәзер хәбәр бирә патшага. Хатының ике эт баласы тапты, ди. Шәһәргә чыгарга оялам, ди. Ни кылсаң да кыл, ди патша хатынына. Ихтыярың үзеңдә, ди. Патша хатыны аны-моны уйламый хәзер. Йорт салдыра 7 юл чатына, бәләкәй генә бер тәрәзәсе була. Шул тәрәзәдән тегеләргә әз генә продукт бирә, үлмәслек кенә. Теге этләр белән хатынга үткән бер, сүткән бер кеше төкереп китә йөзенә. Патша кайта күпмедер вакытлардан соң. Олы хатынга рәхмәт, ди. Ике эт баласы килгәндә күзгә төшә имчәкләре. Хәзер бу патша шул көенә торып тора инде. Теге балалар су белән алып барып, су буена тукталалар. Болар телгә киләләр, аңлый башлыйлар. Нәрсә теләсәләр, шул бар. Су төбенә туктыйлар болар. Малай була Абдулла исемле, тегесе була Фатыйма исемле. 14–15 яшькә җитәләр болар. Үзләренә үзләре укыйлар

болар. Бөтен әйбер бар, ди кыз абыйсына. Абыйсы әйтә охотага чыгар идем. Җәнлек табар идем, ди. Шуннан абыйсы бер көнне чыгып китә. Судан чыга. Чыкса, бер зур күпер була. Моңарга бер карт очрый. Күперне чыкканчы, бабай белән исәнләшә бу. Бабай, кая барасың? – дип сорый малай. Мин, улым, ярминкәгә барам, ди. Вәт миңа шул кирәк иде, ди Абдулла. Миңа ат кирәк иде, ди, охотага йөрергә. Чтобы дөньяда беренче булсын. 3 ат кирәк, өчесе өч төрле булсын. Боларга бик күп акча кирәк бит, ди бабай. Бабай, мең атлык акча бирәм, ди. Әнә шунда торып тор, хәзер алып чыгам акча, ди. Үзе күтәрә алганчы капчык белән алтын чыгара да бирә бабайга. Менә сиңа алтын, ди. Бабай китә үзенә куанып. Малай китә үзенә куанып. Фәлән көнне кайтырмын дип китә бабай. Шулай итеп бабайны көтеп тора бу. Бабай егермеләп ат алып кайта. Бу Абдуллага охшаган икәү генә була. Берсе күк, берсе кара була. Калганын бабай үзенә бирә. Абдулла хәзер теге айгырны иярли дә охотага китә. Коралын-ниен киеп. Чыккач та моңа патша очрый, тоже охотада икән. Абдулла тегенең җәнлеген алып китә сугып. Икенче көнне тагын чыга. Теге патша тагын очрый. Шулай итеп, бер атнага якын йөриләр болар, бер-берсенә очрашып. Патша аптырый бу егеткә. Нинди бала бу, ди. Ничә еллар торып мондый баланы күргәнем юк иде, ди. Патша икенче көнне тагын чыгып китә охотага, түлке шул малайны күрер өчен. Теге олы хатын хәзер колдовканы чакыра. Әби, ди, теге балалар исән, ди, нишлибез. Патша төнлә йоклый алмый хәзер. Әби икенче көнне теге балаларны эзләп чыгып китә. Барып теге кызны таба. Абдулла охотада. Нинди балалар сез, дип сораша карчык. Әти, әниегез кая? Минем абыем гына бар, ди кыз. Кайда тугангыз, кайда үскәнбез, белмибез, ди. Фатыйма әбине кунак итә. Үзе күтәрә алган кадәр алтын-көмеш биреп җибәрә. Дөнья йөзендә бөтен дөньяны яктыртып торган көзге бар, ди. Абыең охотада, ди. Менә көзге булса, үзеңне карап утырыр идең, ди. Әби килгән иде, әби әйтте дип әйтерсең, ди, абыеңа. Төшемдә күрдем дип әйт, ди.

Абдулла кайта охотадан. Утыралар ашарга, эчәргә. Фатыйма төшен сөйли, мин төшемдә бер көзге күрдем, ди. Бөтен дөньяны яктыртып тора, ди. Менә шуны алып кайтып бирсәң икән, ди.

Ярар, әле арада төн бар, иртән уйлашырбыз, ди Абдулла. Йоклап торалар, ашыйлар. Шул көенә Абдулла хәзер бер атны иярли дә, юлга чыга көзге эзләп. Көн бара, төн бара. Кая барганын белми һич тә. Барып керә бер йортка. Анда утыра бер карчык. Исәнлек-саулык сораша. Әби әйтә, кая барасың, нәрсә эзлисең. Әби мин юкны эзләп чыктым, ди Абдулла. Дөнья йөзендә бер көзге бар икән, мин шуны эзләп чыктым. Их, улым, юкка чыккансың, ди әби. Синең кебек патша малайлары күп китте эзләп, ди әби. Кайтып китсәң, лутчы булыр, ди. Әби, ди, миңа каршы төшмә, ди Абдулла. Егетмен дип әйткән егет кире борылырга тиеш түгел. Шулай булса да бер тарак бирим, ди карчык, чәч тарагы. Бер кирәк булыр, ди. Күп баргач, тагын икенче апага барып керә бу. Апа тагы каршы ала. Ашата-эчертә моны. Бер полотенце бирә. Бер кирәк булыр, ди. Алда апа бар, ди, шуңа керерсең, ди. Ул апага барып керә. Анда кунак була. Бу карчык весь сөйләп бирә моңа, точнасы белән. Ул көзге – җен патшасының көзгесе, ди. Ул көзге бакча эчендә агач башында, ди. Агачның һәр яфрагында колокол. Шул яфракларга тимичә кереп ала аласың, ди. Бер яфрагына тисәң дә, бөтен бакча яңгырый, ди. Егет бара, бакчага кереп китә, көзге төбенә. Агач башына менеп көзгене ала. Чыгып киттем дигәндә генә бүрекнең бавы яфракка тия. Моның артыннан ничәмә мең диюләр чыга куып. Килеп җиттем дигән вакытта теге тарагын ташлый. Ә тарак була кара урман урталыкта. Алар кара урманны чыкканчы, бу бик күп җир ала, Абдулла. Тагын куып җиттеләр бит. Хәзер теге полотенцене ыргыта. Урталыкта диңгез була. Шулай итеп, Абдулла котылып кайта. Фатыйма янына. Кайта, икенче көнне охотага чыгып китә тагын. Көзгене куя да. Чыккач та теге патша очрый Абдуллага. Патша кайта да, хатынына әйтә. Теге егет, ди, күп вакытлар югалып торган иде, ди. Тагын килеп чыкты, ди. Патша хатыны теге колдовканы чакырта тагын. Әби, теге балалар тагын чыкты дөньяга, ди. Ну, тагын бер эш бар, ди. Аннан котылса, син дә бетәсең, мин дә бетәм, ди. Икенче көнне теге әби Фатыймага килә тагын. Фатыйма моны шул хәтле куанып, якын итеп каршы ала. Менә, ди, нинди матур көзге алып кайтты, ди. Хәзер үзеңне үзең карап утырасың, ди. Дөнья йөзендә

тутый дигән кош бар, ди. 70 төрле тел белә, ди. Менә шуны алып кайтсаң, әйбәт булыр иде, ди. Әби килде, әби әйтте дип әйтмә, ди. Төшемдә күрдем дип әйт, ди. Шулай итеп, әбине озата, әби кайтып китә. Абдулла кайта, ашыйлар-эчәләр. Их абый, ди, бүген төшемдә, ди, бер кош күрдем, ди, тутый кош исемле ди. 70 төрле тел белә икән, ди. Шуны алып кайтып бирсәң, миңа бер нәрсә дә кирәкмәс иде, ди. Ярар, ди, арада төн бар, ди. Таң атсын әле, ди. Иртән тордылар, ашыйлар, эчәләр. Абдулла патшага ике кабырчык куя, каз канаты икене. Син шуннан гына карап тор, ди, Фатыймага. Мин үлсәм кан тамар, ди. Тере булсам сөт тамар, ди. Кара айгырны иярли дә юлга чыга. Күп вакытлардан соң барып җитә бер урманга. Урман эченә барып керә бер йортка. Анда була бер колдовка, бер карчык. Абдулла сөйләп бирә кая барганын. Абдулланы кире кайтырга куша. Анда киткән патша малайлары берсе дә кире кайтмый, ди. Борыл, ди. Фәлән урманны чыккач, урман бик зур, ди, тау, ди. Шул таудагы ташлар барысы да патша егетләре, ди. Әле тегендә барып җитә. Дөрес, чуп-чуар таш. Аттан төшә. Менә үзе тауның башына. И тутый кош син шушындамы, ди. Шулай дигәч тә, теге егет тиздән таш була бу. Тутый кошның хикмәте шушы икән, ди. Егет таш булып ката. Теге каурыеннан хәзер кан тама. Кыз карап утыра хәзер. Фатыйма чыгып хәзер күк атны иярли. Атның колагына әйтә. Абдулланы тап, ди, киттек чыгып, ди. Шул көенә хәзер чыгып китә кыз атка атланып. Атның поводын тотмый, ат бүре була, кая тели шул якка китә. Ничәмә көн, ничәмә төн дигәндә, ат барып җитә теге тауга. Атны куалап карый, ат кузгалмый. Кыз әйтә, и тутый кош, бар микән, ди, юкмы икән, ди. Бу шулай дигәч, күзенә күренә бер кош, кызның. Әллә шушы тутый кош микән, ди. Кыз әйтә. Тутый кош телгә килә. Нинди тутый кош, ди. Нигә елыйсың, ди тутый кош. Монда абыем килеп үлде, ди. Шул ташларны сыпыр, ди, канатың белән. Сыпыра бара, теге ташлар терелә бара. Абзыйсына җиткәнче сыпыра бу. Шуннан абыйсын таба. Монда хәзер тавыш китә. Берсе әйтә мин алдым, ди, берсе әйтә мин алдым, ди, теге тутый кошны. Тутый кош әйтә Фатыймага, уң канатымны ал, ди. И бөтенесен дә сыпыр, ди. Шулай итеп, ташларны сыпырып бетә. Болар кай-

тырга юлга чыгалар, өчәүләп. Абдулла, Фатыйма, тутый кош. Шулай итеп, кайтып җитәләр. Кайта да икенче көнне охотага чыгып китә. Охотага чыкса, патша тагын очрый моңа. Патша хатынына әйтә. Теге егет тагын дөньяга чыкты, ничек күреп сөйләшергә икән бер, ди. Патша хатыны әйтә. Мин, ди, аны, ди, туктатып чакырам, ди. Беләм ди. Патша икенче көнне чыга тагын охотага. Теге Абдулла да чыга. Болар икесе встречать итәләр, патша белән Абдулла. Исәнләшәләр, күрешәләр. Атларыннан төшәләр. Син кайдагы егет, ди патша. Мин, ди, дию нәселеннән, ди. Монда охотада ятам, ди. Ни көнгә вакыт бирерсең икән, мин синең белән рәхәтләнеп бер утырасым, кунакка чакырасым килә, вәзирләргә күрсәтәсем. Ни көнне телисең, шул көнне мин әзермен, ди. Кемең бар, ди, патша әйтә Абдуллага. Бер сеңлем бар, ди. Ат кайда җибәрим, ди. Мин фәлән күпер төбендә булам, ди. Шулай итеп, болар исәнләшеп аерылалар. Сәгать 12 дә ашта бул, дип. Патша кайта, хатынына әйтә хәзер. Шулай-шулай кунакка чакырдым, дию нәселе икән. Монда охотада ята икән. Патша әйтә аның кебек баланы дөнья йөзендә дә күргәнем юк, ди. Патша хатыны теге карчыкны чакырта тагын. Теге балалар кунакка киләләр тагын, ди, нәрсә кылабыз, ди. Түлке бер җай бар, ди. Ашарга агу салып бөтен гаскәрне бетерергә туры килә, ди. Бүтәнчә җай юк, ди. Патша бөтен вәзирләренә хәбәр итте. Шундый-шундый кунак килә, иртәгә дип.

Абдулла кайтты хәзер. Фәлән патша кунакка чакырды иртәгә, ди. Тутый кош әйтә, миннән башка беркая да барма. Бер әйбер капма. Аша, эч, ят, йокла, ди. Иртәнчек торалар, ашыйлар, эчәләр. Хәзер китәләр, кунакка, патшага. Җигәләр пар атны. Тутый кош була кучер. Шулай итеп, өчәүләп китәләр кунакка. Чыгалар күпер төбенә. Күпер төбенә чыксалар, патшаның атлары килгән, пар ат алырга. Тутый кош әйтә патшаның кучерына. Син ди, кайт, ди. Без фәлән җирдән урап барабыз. Шулай итеп, болар китәләр хәзер базарга. Абдулла алдырта бер чирек каймак. Тутый кош Абдулладан 3 буханка күмәч алдырта. Теге эт балалары белән яшәгән хатынга бирәләр бу икмәк белән каймакны. Анда охран бар, ул хатын янында. Патша әйтә, теге охранга шундый-шундый кеше

туктадымы, ди. Теге этләргә туктап күмәчләр, коймаклар бирделәр, ди. Бик каты сүктеләр, ди. Шулай итеп, хәзер китәләр патшага. Бик зур итеп каршы алалар моны, бөтен публик. Хәзер боларны алып керәләр. Халык бөтен җир тулы, йорт, ишек алды, ничәмә меңләгән. Тутый кош керә дә сәгать башына утыра, чебен булып, тегеләр кергәнче. Хәзер аш-суны әзерлиләр утыртырга. Абдулла сорый патшадан. Минем ди, бер кошым бар, ди. Шул кошка вопрос бирер идең, ди. Шул кошка, ди. Бөтен публик моңа аптырый. Нинди кош бу, ничек сөйли? Абдулла әйтә тутый кошка, ну ди, нәрсә белсәң, давай, ди, сөйлә, ди. Мин, ди, сөйлим, ди. Менә шушы патша турында ди. Менә бу патшаның, ди, олы хатыныннан бала булмады, ди тутый кош. Шуннан, ди, яшь хатын алды, ди. Алды да, ди, үзе чыгып китте обход ясарга ди. Яшь хатын калды йөкле булып, ди. Шуннан яшь хатын чирли хәзер бала тудырырга. Патшаның хатыны чакырта бер колдовканы. Вот, әби, нишлибез ул туса, мине кага, ул балалы була, мин баласыз. Бу ике баланы алалар и ике эт баласы алалар. Яңа туган. Бу балаларны суга салалар, ящик ясап. Ә хатынны 7 юл чатлыгына бер бәләкәй генә өй салып, ике этне, бер бәләкәй тишек, шуннан ашарга биреп. Бу балалар исән-сау үсеп, болар охотага йөри башлый. Охотада бу патшага очрап, патша белән танышалар. Бүгенге көндә алар патшада кунакта. Менә шушы бүгенге пешкән аш, кем пешергән, шушы публик арасында шуны ашасын. Ул ашлар барысы да агу белән пешкән. Вич шушында утырган публиканы үтерергә. Патшаның хатыны ашны чыгарып утырта да, кабам дип изүенә салып җибәрә. Агу бөтен түшен яндырып төшеп китә. Вот, менә бөтен публик, күрдегезме, ди, Абдулла әйтә. Мин дүртенче үлемнән калдым, ди. Тутый кош әйтә, менә шушы Абдулла, ди, патшаның улы, ди, менә кызы, ди. Аларның имәсе сөтләрен этләр имде, ди. Нинди хөкем? ди. Нәрсә теләсә ихтыяр Абдуллада, ди бөтен гаскәр. Атаргамы, асаргамы, яндырыргамы? Абдулла теге этләр белән әнкәсенә кайта, халык арасына. Патшаның олы хатынын шул этләр арасына илттерә, әнкәсен алып кайта. Теге колдовка карчыкны астырып яндыралар. Бу патша. Хәзер яңадан 60 дөя суйдыра. Бу эт белән тор-

ган хатынны яңадан хатын итеп ала. Абдулла да кайта, теге кыз Фатыйма да кайта.

*Хәлекәй авылында*
*Йосыпов Гайфулла Вәли улыннан (63 яшь)*
*Р. Халикова язып алган*

**Тапкыр егет**

Борын-борын заманда бер бабай ниндидер уй белән сәфәр чыккан, ди. Күпмедер юл киткәч, аның юл оңгаена баручы бер егет очраган, ди. Бабайдан егет: «Әй, бабай, синме йоклыйсың, әллә минме!» – дип сораган. Бабай егеткә аптырап: «Әй, юләр егеткәй, ат өстендә барганда йоклап була мыни?» – дигән. Шул көе болар бер-берсенә дәшмичә хәтсез юл киткәннәр, ди. Бераз баргач, юл буенча яңа баш кысып килгән бодай басуы очраган, ди. Егет бабайдан: «Әй, бабай, бу бодайны ашадылар микән, ашамадылар микән?» – диеп сораган ди. Бабай аптырап егеткә: «Менә юләр егет, әле бу бодайны ашаганчы, башында мөлләте бик күп, әле бит яңа гына баш кысып килә», – дип җавап биргән ди. Тагын бераз юл киткәч, ниндидер кешеләр мәет җеназасын күтәреп китеп барганнары күренгән, ди. Егет бабайдан: «Әй, бабай, бу җеназадагы кеше үле микән, әллә тере микән?» – дип сораган ди. Ә бабай егеткә тагын аптырап карап: «Әй юләр егет, тере кешене җеназа белән зыяратка күтәреп ни эшләп алып барсыннар инде, юк сөйләп барма», – дигән.

Шулай сөйләшеп килә торгач, бабайның авылына кайтып җиткәннәр. Бабай егеткә: «Әйдә, улым, безгә кереп чәй эчеп ял итеп китәрсең», – дип әйткән. Өйгә килеп кергәч, егет өйдә әбине һәм 16–17 яшьлек кызын күргән. Бабай әбигә: «Кая карчык утырт әле, менә мин сиңа кунак алып килдем», – дигән. Чәй янына утыргач, бабай әбигә: «Менә егет юләр ахры, юл буена теләсә нинди сорау биреп аптыратып бетерде», – дигән. Һәм сөйләп биргән, ди. Бу сүзләрне ихлас итеп тыңлап утырган кыз. «Әй әтием, бу егет бер дә юләр түгел. Ул сиңа синме, әллә мин йоклаганмы, дию. Бабай синме тәү сүз башлыйсың, әллә минме, дию булгандыр. Ә үсеп килгән игенне ашадылар микән, әллә

ашамадылар микән, диюе. Бу игеннең гомерен бирделәрме икән, әллә юкмы икән, диюе булгандыр. Өченче соравы. Бу җеназадагы кеше үле микән, әллә тере микән, диюе. Бу кешенең үлгәч ипкә төшерергә варислары бармы икән, дип әйтүе булгандыр», – дигән. Егет бу кызның шулай бик дөрес җавап бирүенә бик сокланып, эченнән болай уйлаган: «Бу кыз бик зирәккә ошый. Әллә мин эзләгән кыз шушы микән?» Егет күп уйлап тормаган, бабайга: «Кадерле бабакаем, синең кызың миңа бик ошый, ризалыгың белән безне кавыштырсаңчы», – дигән. Бабай аптырап әбигә караган. Ә әби егеткә бик сокланып карап тора икән. Шулай итеп, егет әби белән бабайга бик ошаган. Ике яшькә матур итеп туй ясаганнар. Туйларында мин дә булдым. Ике телем икмәк ашадым, ике чынаяк чәй эчтем.

## Патша кызы Зөлхәбирә

Бер патшаның Зөлхәбирә исемле бик матур кызы булган ди. Бу кыз үсеп буйга җиткәч, бер генә бай егетен дә үзенә буйсынмаган, тиңсенмәгән. Ә зыярат каравылчысын – бер егетне яраткан, ди. Егет бик ярлы булган. Кыз әтисенең барыбер үзен егеткә бирмәсен сизгән, белгән, ди. Көннән бер көнне бу кыз чиргә сабышкан һәм үлеп тә киткән, ди. Кызны бик елап бик кайгырып илтеп күмгәннәр. Кабер каравылчысы Әзһәм исемле егет каберләр арасында йөргәндә бер тавыш ишетә ди. Ул патша кызының кабаренә килеп җитә һәм тавышының шуннан чыкканын аңлый. Зөлхәбирә моңа «мин тере, каберемне ач, минем кулларым кәфенгә төрүле, күтәреп чыгар», – дигән ди. Егет бу кушканны эшләгән. «Хәзер мине үзегезгә алып кайт», дигән кыз моңа. Болар кайтканнар һәм бергә тормыш кора башлаганнар. Боларның кызлары дөньяга килгән. Бер заман патшаның кызы Зөлхәбирәне багып үстергән хезмәтче хатын болар торган йорт яныннан үтеп барганда, җиде яшьлек кызның уйнап йөргәнен күргән. Ул шултиклем Зөлхәбирәгә охшаган, ди. Бу карчык аны кочаклап сөйгән, акча, икмәк биреп киткән һәм еш кына бу йорт янына килеп йөрергә булган. Моны кешеләр күреп алганнар һәм патшага җиткергәннәр, ди. Патша бик ачуланган, нигә ми-

нем байлыкны тарата, дигән. Әбине чакыртып алган. Әби моңа: «И падишаһ, әгәр син ул сабыйны күрсәң, үзең күрсәң, үзең дә яратыр идең, ул шул тиклем синең үлгән кызыңа охшаган», – дигән. Патша бу сабыйны һәм аның әнисен алырга кешеләр җибәргән. Кәнизәкләрне Зөлхәбирә кире борган. «Әле эшем күп, вакытым юк», – дигән. Кәнизәкләр патшага барып әйткәннәр: «Әй, солтаныбыз, ул бик фәкыйрьдер, бик сәләмә киенгән, сезнең янга килергә тартынадыр», – дигән. Патша моңа бик күп асыл киемнәр җибәргән. Кәнизәкләр Зөлхәбирәне көчләп патшага китергәннәр. Патша үзенең кызын таныган, әй елашканнар, әй куанышканнар. Шуннан патша Әзһәмне тирги башлаган. «Син нигә минем кызымны миңа алып килмәдең, шуның өчен мин синең башыңны чабам», – дигән. Шуннан Зөлхәбирә әтисенә: «Я, атам! Әгәр ул мине казып алгач та сиңа китереп бирсә, син мине беркайчан да Әзһәмгә кияүгә бирмәс идең, чөнки син байсың, ә байлык һәрвакыт мәхәббәтне кире кага», – дигән. «Син аны гафу ит, ул гаепсез, – дигән». Шуннан соң патша байларга үзенең ярты патшалыгын биргән. Бик тату, бик шат яши башлаганнар, ди. Шулай итеп, батыр кыз Зөлхәбирә мәхәббәтен бернинди байлыкка да алыштырмаган, күп михнәтләр, фәкыйрьлек күрсә дә ирен ташлап бай атасына кайтмаган, ди. Шуның белән әкият тә тәмам.

*Гали-Бузат авылында*
*Миннебаева Зөлхәбирә Камалетдин кызыннан (74 яшь)*
*язып алынган*

ИНФОРМАНТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

Абдуллина Сәрбиямал (60 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Актуганова Заһидә (57 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Арсланов Шамил (72 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Әминева Гөлзәлинә Миңнеәхмәт кызы. Хәлекәй авылы
Әсәдуллина Мәрфуга Газизулла кызы (77 яшь). Бузат авылы
Әсфәндиярова Әминә (1903 елгы). Бузат авылы
Әсфәндиярова Мәдинә Муллагали кызы (68 яшь). Бузат авылы
Батыршина Гөлҗиһан (55 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Батыршина Миңниса (56 яшь). Яңгырчы авылы
Галиева Зөбәрҗәт (1911 елгы). Тәтер-Арслан авылы

Галиева Зөләйха (1895 елгы). Тәтер-Арслан авылы
Галиева Оркыя (63 яшь). Айтуган авылы
Галиева Оркыя (67 яшь). Кызылъяр авылы
Ганиева Рәйхан Абдулла кызы (78 яшь). Бузат авылы
Ганиева Тәкыя Нигъмәт кызы (40 яшь). Бузат авылы
Гыйззәтуллина Газимә Хәлиулла кызы (81 яшь). Бузат авылы
Гыйлемҗанова Фәхриямал (66 яшь). Бузат авылы
Гыйльманова Хәдичә Ибраһим кызы (67 яшь). Карамалы-Бузат авылы
Идиятуллина Хәлимә (50 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Ишбулдина Сәлимә (63 яшь). Бузат авылы
Ишмөхәммәтов Мөхәмәдияр (1900 елгы). Тәтер-Арслан авылы
Ишмөхәммәтова Мәүсилә А (39 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Ишниязова Зөһрә (70 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Йосыпов Гайфулла Вәли улы (63 яшь). Хәлекәй авылы
Йосыпова Зәлифә Айдарәле кызы (71 яшь)
Камалова Сәрия (35 яшь). Айтуган авылы
Камалова Хөсниямал (55 яшь)
Кәримова Заһидә (58 яшь). Яңгырчы авылы
Кәримова Рабига (64 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Латыйпова Рәйханә Гатаулла кызы (58 яшь). Хәлекәй авылы
Латыйпова Фатыйма Абдулла кызы (61 яшь). Хәлекәй авылы
Локманова Гөлфирә (55 яшь). Айтуган авылы
Локманова Мөкәррәмә Гариф кызы (63 яшь). Хәлекәй авылы
Локманова Хәнифә. Кызылъяр авылы
Мингазова Бану (59 яшь). Яңгырчы авылы
Миңнебаева Зөлхәбирә Камалетдин кызы (74 яшь). Гали-Бузат авылы
Мирзаева Закирә (70 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Мирзаянова Рәмзия (73 яшь). Хәлекәй авылы
Мифтахова Насыйха Хәйбулла кызы (59 яшь). Хәлекәй авылы
Могаттарова Өммикамал Гомәр кызы (73 яшь). Хәлекәй авылы
Муллаянова Миңзифа (70 яшь)
Мусин Мәҗит Гыйният улы (70 яшь). Хәлекәй авылы
Мусина Газзә Ситдыйк кызы (78 яшь). Хәлекәй авылы
Мусина Зәйнәп (79 яшь)
Ногманова Гарифә (60 яшь)
Нугуманова Мәгъзифә Нигъмәтулла кызы. Өч-Әсән авылы
Пучкарев Гариф (70 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Рысаева Зарифа Лотфрахман кызы (76 яшь)

Рысаева Зәһибә (42 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Рысаева Сәгурә (67 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Сабитов Әхмәт Нигъмәтулла улы (82 яшь). Хәлекәй авылы
Садриева Маһикамал (54 яшь)
Садриева Хәмдидә. Яңгырчы авылы
Тимергазина Мәсрурә (80 яшь).
Үләева Рәшидә (1929 елгы). Бузат авылы
Үләева Шәмсениса (44 яшь). Кызылъяр авылы
Халикова Әсхәт (69 яшь). Бузат авылы
Халитова Хатирә Габдрахман кызы (75 яшь). Хәлекәй авылы
Ханнанова Фәкыя (69 яшь). Тәтер-Арслан авылы
Хәбибрахманова Зәйнәп (70 яшь)
Хәбибуллина Әминә (58 яшь)
Хәлимов Гариф Гомәр улы (72 яшь). Хәлекәй авылы
Хисмәтуллина Рабига (70 яшь). Яңгырчы авылы
Хөснетдинова Маһикамал Хафиз кызы (78 яшь). Хәлекәй авылы
Шаммасова Рауза Һидият кызы (64 яшь). Хәлекәй авылы
Шәрипова Гөлҗиян Ихсан кызы (69 яшь). Хәлекәй авылы
Шәрипова Мәрхәбә Әһлетдин кызы (59 яшь)
Шәрипова Мәхупҗамал Әһлетдин кызы (66 яшь)
Шәрипова Мөслимә Гатаулла кызы (56 яшь). Бузат авылы
Шәфиева Тәслимә Мәхмүт кызы (52 яшь). Тәтер-Арслан авылы

*Текстларны электрон форматка халык авыз иҗаты бүлегенең фәнни хезмәткәре Г.Р. Яхшисарова күчерде.*

# КУШЫМТА

## Стәрлебаш тарихы 1905–1917 еллар татар вакытлы матбугатында

Мәдрәсәләрдә яңача уку-укыту, тәрбия тәртипләрен кертү, Европа, рус югары уку йортлары дәрәҗәсендә белем бирүгә ирешү өчен яхшы һәм заман таләпләренә туры килә торган дәреслекләр язу һәм бастырудан тыш, Мөхәммәдшакир Тукаев, 1905–1917 еллардагы татар һәм рус вакытлы матбугатының мөһимлеген аңлап, киң таралыш алган, шәкертләрне күп укылган газеталар белән таныштыруны да кирәк тапкан.

Бу чорда татар халкына хезмәт итү, милләтнең бүгенгесен, киләчәген кайгырту, аны сәяси, милли һәм икътисади яктан дөньядагы башка халыклар дәрәҗәсенә күтәрү, халыкара мәйданга чыгару максаты белән Әстерхан, Мәскәү, Минзәлә, Оренбург, Санкт-Петербург, Самара, Саратов, Сембер, Ташкент, Троицк, Уфа һ.б. шәһәрләрдә татар телендә күп кенә вакытлы матбугат басмалары нәшер ителгән. Алар 1917 елга кадәр тулаем татар байлары һәм сәүдәгәрләренең акчаларына чыгарылган.

Шундый басмаларның берсе – Шакир һәм Закир Рәмиевләр (Дәрдемәнд) тарафыннан 1906–1918 елларда Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасы. Ул XX гасыр башы татар матбугатында күренекле урын били һәм татар газеталары арасында иң алдынгыларның берсе булып санала.

Уку-укыту эшен, тел һәм әдәбият, мәдәният мәсьәләләренә киң урын биргән, милли театр, музыка сәнгатен җәелдерүгә

теләктәшлек күрсәткән, дәүләт мәктәпләренә кереп укуны эзлекле яклаган «Вакыт» газетасы, «Шура» журналы битләрендә Стәрлебаш авылы, аның мәдрәсәләре, шәхесләр турында да мәкаләләр басылган. Әйтик, «Вакыт» газетасынең 1913 ел 9 июнь санында (№ 1220) академик В.В. Бартольдның Оренбургтан Уфага сәяхәте вакытында Стәрлебашта туктaлуы турында хәбәр бар. Ул иске татар имлясыннан бүгенге графикага күчерелеп укучылар игътибарына тәкъдим ителә.


٤ «وقت» نومر ۱۲۲۰

چن تأسف لر ایله بیان ایتب بکلر نیه بارچه لر گزه عرض ایدوب سوزمنی تمام ایدیم.

تأسف بیان ایدوچی:

طوغان آتاسی ماه پرواز شیخ علی.

اوفا ۱۹۱۳ نچی یلده ٤ ایبونده.

مخابرلردن:

استرلی باشده پروفیسور بارتولد

پروفیسور بارتولد جنابلرینك اورنبور-
غدن استرلی باشغه کیتدیگی غزته مزده یا-
زلغان ایدی. حاضرنده استرلی باشدن اداره
مزگه کیلگان بر مکتوبده بیان اولندیغنه کوره:
پروفیسور جنابلری ۳۱ مایده جمعه کون شونده
باروب سابق دوما اعضاسی شاکر مخدوم طو-
قایفغه توشکان. شاکر مخدوم روسچه و مسلما-
نچه معرفتلی و کشی طانوچی معتبر بر ذات
اولدیغندن پروفیسورنی مع الممنونیه قارشی
آلغان و ایونده قوناق ایتکاننك صوکنده آنی
جمعه غه مسجدگه آلوب بارغان. جمعه دن صوك
مدرسه گه آلوب باروب درسخانه و کتبخانه لرنی
کورسه تکان. پروفیسور جنابلری ایسکیدن
بیرلی مشهور بولوب کیلگان بو استرلی باش
مدرسه لرن بیك لذت ایله قاراب هر جهتدن
تماشا ایتکان. مدرسه نك کتبخانه سن آقتاروب
۲۰۰-۳۰۰ حتی ۵۰۰ یل الوك یازلغان قول یازمه
کتابلرنی دقت و لذت ایله قاراغان. اصول صوتیه
برلن اوقولا طورغان ابتدائی مکتبگه کروب
بالالرنك اوقی طورغان کتابلرن و یازا طورغان
دفترلرن قاراغان. خلاصه: مدرسه و مکتب تیره
سنده اوچ ساعت قدر یوروب قاراب چققان.
شاکر مخدوم هر خصوصده ایضاحات و معلومات
بیروب پروفیسورنی بیك ممنون ایتکان.
صوکره، شاکر مخدومنك مرحوم انکالری
و بابالری طرفندن اوطورتلغان الوغ باقچه غه
باروب استراحت ایتکانلر و آنلرنك طورغان
یرلرن قاراب یورگانلر. بونك صوکنده حبیب الله
افندی و علی خلفه لرنك ایولرینه کروب آنلر
نك کتبخانه لرنده گی ایسکی کتابلرنی قاراغان.
بو کتبخانه لرده شایان دقت مهم کتابلر و اثرلر
بار ایکان. آندن مرحوم استرلی باش حضرتلر
نك زیارتلرینه باروب، طاشلرده غی یازولرنی
اوقوغان. بعض بر طاشلرده حاضرگه قدر آچق
اوقلوب یتمی طورغان فارسیچه یازولرنی پرو-
فیسور جنابلری درست لب اوقوغان.
شاکر مخدوم پروفیسورگه ختفه برلن
طشلاغان ایسکی قول یازمه «استرلی باش
تاریخی» هدیه ایتکان. بونلردن باشقه، دخی
شاکر مخدوم پروفیسورغه استرلی باشنك شا-
یان دقت یرلرن کورسه تکان و اوز ایونده بیك
حرمت ایله قوناق ایتکان. پروفیسور ۳۱ مایده
اوفاغه کیتکان.

«Вакыт». 1913 ел, 9 июнь. № 1220. 4 б.

## مخابرلردن
## استرلی باش ده پروفیسور بارتولد

پروفیسور بارتولد جنابلرینڬ اورنبورغدن استرلی باش غا کیتدیگی غزته مزده یازلغان ایدی. حاضرنده استرلی باش دان اداره مزگه کیلگان بر مکتوبده بیان اولندیغنه کوره: پروفیسور بارتولد جنابلری ۳۱ مایده جمعه کون شونده باروب سابق دوما اعضاسی شاکر مخدوم طوقایف غه توشکان. شاکر مخدوم روسچه و مسلمانچه معرفتلی و کشی طانوچی معتبر بر ذات اولدیغندان پروفیسور نی مع الممنونیه قارشی آلغان و ایونده قوناق ایتکاننڬ صوکنده آنی جمعه غه مسجدگه آلوب بارغان. جمعه دن صوڬ مدرسه گه آلوب باروب درسخانه و کتبخانه لرنی کورسه تکان. پروفیسور جنابلری ایسکیدن بیرلی مشهور بولوب کیلگان بو استرلی باش مدرسه لرن بیك لذت ایله قاراب هر جهتدن تماشا ایتکان. مدرسه نڬ کتبخانه سن آقتاروب ۲۰۰-۳۰۰ حتی ۵۰۰ یل الوك یازلغان قول یازمه

کتابلرنی دقت و لذت ایله قاراغان. اصول صوتیه برلن اوقولا طورغان ابتدائی مکتب گه کروب بالالرنڭ اوقی طورغان کتابلرن و یازا طورغان دفترلرن قاراغان. خلاصه: مدرسه و مکتب تیره سنده اوچ ساعت قدر یوروب قاراب چققان. شاکر مخدوم هر خصوصده ایضاحات و معلومات بیروب پروفیسور نی بیك ممنون ایتکان.

صوڭره، شاکر مخدومنڭ مرحوم اتکالری و بابالری طرفندان اوطورتلغان الوغ باقچه غه باروب استراحت ایتکانلر و آنلرنڭ طورغان یرلرن قاراب یورگانلر. بونڭ صوڭنده حبیب الله افندی و علی خلفه لرنڭ ایرلرینه کروب آنلرنڭ کتبخانه لرنده گی ایسکی کتابلرنی قاراغان. بو کتابخانه لرده شایان دقت مهم کتابلر و اثرلر بار ایکان. آندن مرحوم استرلی باش حضرتلرنڭ زیارتلرینه باروب ، طاشلرده غی یازولرنی اوقوغان. بعض بر طاشلرده حاضرگه قدر آچق اوقلوب یتمی طورغان فارسیچه یازولرنی پروفیسور جنابلری درست لب اوقوغان.

شاکر مخدوم پروفیسور گه ختفه برلن طشلاغان ایسکی قول یازمه «استرلی باش تاریخی» هدیه ایتکان بونلردن باشقه، دخی شاکر مخدوم پروفیسور غه استرلی باش نڭ شایان دقت یرلرن کورسه تکان و اوز ایونده بیك حرمت ایله قوناق ایتکان. پروفیسور ۳۱ مایده اوفاغه کیتکان.

## Мохабирләрдән[1]

Профессор Бартольд җәнабләренең Оренбургтан Эстәрлебашка китдеге газитәмездә язылган иде. Хазирендә[2] Эстәрлебашдан идарәмезгә килгән бер мәктүбдә[3] бәян улындыгына күрә: профессор җәнабләре 31 нче майда җомга көн шунда барыб сабикъ[4] дума әгъзасы Шакир мәхдүм[5] Тукаевка төшкән. Шакир мәхдүм русча вә мөселманча мәгърифәтле вә кеше танучы мөхтәрәм бер зат улдыгында профессорны мәгаль-мәмнүния[6] каршы алган вә өендә кунак иткәннең соңында аны җомгага мәсҗедгә алыб барган. Җомгадан соң мәдрәсәгә алыб барыб, дәресханә вә китабханәләрне күрсәткән. Профессор җәнабләре искедән бирле мәшһүр булыб килгән бу Эстәрлебаш мәдрәсәләрен бик ләззәт илә караб һәр җәһәтдән тамаша иткән. Мәдрәсәнең китабханәсен актарыб, 200–300, хәтта 500 ел элек язылган кульязма китабларны дикъкать вә

---

[1] *Мохабирләрдән* – хәбәрчеләрдән.
[2] *Хазирендә* – хәзер, бу вакытта, шушы вакытта.
[3] *Мәктүбдә* – язылган нәрсәдә.
[4] *Сабикъ* – узучы, үтүче.
[5] *Мәхдүм* – дин башлыкларының ир балаларына бирелгән исем.
[6] *Мәгаль-мәмнүния* – разый булып, шатланып.

ләззәт илә караган. Осуле саутия[1] берлән укыла торган ибтидаи мәктәбгә[2] кереб, балаларның укый торган китабларын вә яза торган дәфтәрләрен караган. Хөласа[3]: мәдрәсә вә мәктәб тирәсендә өч сәгать кадәр йөреб караб чыккан. Шакир мәхдүм һәр хосусда[4] изахат[5] вә мәгълүмат биреб, профессорны бик мәмнүн иткән[6].

Соңра, Шакир мәхдүмнең мәрхүм әткәләре вә бабалары тарафындан утыртылган олуг бакчага барыб истирахәт иткәнләр[7] вә анларның торган йирләрен караб йөргәнләр. Буның соңында Хәбибулла әфәнде вә Гали хәлфәләрнең өйләренә кереб, анларның китабханәләрендәге иске китабларны караган. Бу китабханәләрдә шаян дикъкать[8] мөһим китаблар вә әсәрләр бар икән. Андан мәрхүм Эстәрлебаш хәзрәтләренең зыяратларына барыб, ташлардагы язуларны укыган. Бәгъзы бер ташларда хазыйргә кадәр ачык укылыб йетми торган фарсыча язуларны профессор җәнабләре дөресләб укыган.

Шакир мәхдүм профессоргә хәтфә[9] берлән тышлаган иске кулъязма «Эстәрлебаш тарихы» һәдия иткән[10]. Бунлардан башка, дәхый[11] Шакир мәхдүм профессорга Эстәрлебашның шаян дикъкать йерләрен күрсәткән вә үз өендә бик хөрмәт илә кунак иткән. Профессор 31 майда Уфага киткән.

*Текстларны гарәп графикасынннан гамәлдәге язуга күчереп, басмага ТР ФА Г. Ибрагимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Нуридә Насыйбуллина әзерләде*

---

[1] *Осуле саутия* – балаларны укырга-язарга өйрәтүдә кулланыла торган аваз методы.

[2] *Ибтидаи мәктәбгә* – башлангыч мәктәпкә.

[3] *Хөласа* – сөйләгәнне җыеп кына әйткәндә («озын сүзнең кыскасы»).

[4] *Хосус* – очрак, мөнәсәбәт.

[5] *Изахат* –ачык итеп аңлатып.

[6] *Мәмнүн иткән* – разый, шат иткән.

[7] *Истирахәт иткәнләр* – ял иткәннәр.

[8] *Шаян дикъкать* – игътибарга лаек, нечкәләп тирәнтен тикшерерлек.

[9] *Хәтфә* – өс ягы кыска калдырып кыркылган куе йомшак төкле, гадәттә өлешчә яки бөтенләй ефәктән эшләнгән тыгыз тукыма; бәрхет.

[10] *Һәдия иткән* – бүләк иткән.

[11] *Дәхый – тагы.*

## Авторлар турында кыскача белешмә

*Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре.

*Галимова Эльмира Мөнир кызы* – сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире.

*Насыйбуллина Нуридә Шәйдулла кызы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Салахов Абдулла Мөнир улы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Усманов Венер Мөдәррис улы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре.

*Шкляева Людмила Михайловна* – сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Ямалтдинов Ильмир Илдар улы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире.

*Яхин Фәрит Зәкиҗан улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

## ЭЧТӘЛЕК

БЕР-ИКЕ СҮЗ...
5
ТАРИХЫ ЭСТӘРЛЕБАШ
*Мөхәммәтшакир Тукаев*
7
ОПИСАНИЕ ДЕРЕВНИ СТЕРЛИБАША
И СТЕРЛИБАШЕВСКОГО МЕДРЕСЕ
действительного члена Уфимского губернского
статистического комитета, магзума Шакира Харисовича Тукаева
24
ИСТОРИЯ ХРАНИТЕЛЕЙ РУКОПИСНОГО НАСЛЕДИЯ
В СТЕРЛИБАШЕВО
*Нурида Насибуллина*
46
АРАБОЯЗЫЧНАЯ РУКОПИСЬ ИЗ СТЕРЛИБАШЕВО
*Абдулла Салахов*
57
БАШКОРТСТАННЫҢ СТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫНДА
ТАБЫЛГАН КУЛЪЯЗМАЛАРНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ
*Фәрит Яхин*
72
СТӘРЛЕБАШНЫҢ ЗАТЛЫ КИТАПЛАРЫННАН –
«ДӨРРЕЛ-КӘЛАМ»
*Фәрит Яхин*
100
СТӘРЛЕБАШ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ ӘСӘРЛӘРЕ
*Марсель Әхмәтҗанов*
134

ЗАТЛЫ НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫЛАРЫ
*Нуридә Насыйбуллинаның Нил Рәмиев белән әңгәмәсе*
148

ХӘЛЕКӘЙ АВЫЛЫ ТАРИХЫНА
КАГЫЛЫШЛЫ МӘГЪЛҮМАТЛАР
*Венер Усманов*
158

ТРАДИЦИОННАЯ МУЗЫКАЛЬНАЯ КУЛЬТУРА
ТАТАР СТЕРЛИБАШЕВСКОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ БАШКОРТОСТАН
*Эльмира Галимова*
203

ТКАЧЕСТВО И ПУХОВЯЗАНИЕ У ТАТАР
СТЕРЛИБАШЕВСКОГО РАЙОНА БАШКОРТОСТАНА
*Людмила Шкляева*
233

ЕРАК ЮЛЛАР КАЙТАВАЗЫ
*Ильмир Ямалтдинов*
252

КУШЫМТА
Стәрлебаш тарихы 1905–1917 еллар
татар вакытлы матбугатында
440

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

**Национально-культурное наследие**

**ТАТАРЫ БАШКОРТОСТАНА. СТЕРЛИБАШ**
**2 часть**

2-е издание

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

**Милли-мәдәни мирасыбыз**

**БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫ. СТӘРЛЕБАШ**
**2 нче кисәк**

2 нче басма

Редактор: *Л.Г. Шәрифуллина*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*

Китапта *Л.М. Шкляева, Н.Ш. Насыйбуллина*
фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 20.01.2021.
Форматы 60×84 $^1/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 20. Шартлы басма табагы 26.
Тиражы 500 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан, Бауман ур., 20